Энҗе чәчтем — энҗе җыям

# ӘЙТЕМ – ЧӘЧӘК,
# МӘКАЛЬ – ҖИЛӘК

Халык афоризмнары

Икенче китап

Казан «МӘГАРИФ» Нәшрияты 2002

УДК 398
ББК 82.3 (2Рос=Тат)-6
Ә-33

Редколлегия:
*К. М. Миңнуллин* (сериянең баш редакторы), *Җ. Х. Кәлимуллин, Ф. И. Урманче*

Төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы
*Х. Ш. Мәхмүтов*

Рәссамы *Л. С. Золондинова*

**Әйтем** — чәчәк, мәкаль — җиләк: Халык афоризмнары. Икенче китап.— Казан: Мәгариф, 2002.— 191 б.
ISBN 5-7761-1120-X

«Мәгариф» нәшрияты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге белән берлектә, «Энҗе чәчтем — энҗе җыям» дигән гомуми исем астында, татар фольклорының иң гүзәл җәүһәрләрен туплап, мәктәпләр һәм гимназияләр өчен уку ярдәмлеге сыйфатында китаплар чыгаруга кереште.

Бу китапта мәкальләр, канатлы сүзләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр тупланды.

ISBN 5-7761-1120-X

© «Мәгариф» нәшрияты, 2002

## Кереш

Халык афоризмнары арасында әдәби-эстетик кыйммәте буенча да, сан ягыннан да төп урынны, һичшиксез, мәкальләр алып тора. Татар фольклоры җыентыкларында басылган һәм кулъязма фондларда тупланган мәкальләр саны, төрле вариантларын кушып исәпләгәндә, 50 мең чамасына җитә.

«Мәкаль» атамасы безгә гарәп теленнән кергән. Аның мәгънәсе «сөйләү», «әйтеп бирү», «урынлы әйтелгән сүз» дигәнгә туры килә. Җанр исеме буларак, бу сүз татар фольклористикасы тарихында беренче мәртәбә Мартиньян Ивановның «Татарская хрестоматия» дәреслегендә очрый (1842). XIX йөздә һәм XX гасыр башында басылып чыккан күп санлы фольклор җыентыкларында, дәреслекләрдә, сүзлекләрдә шулай ук гарәп сүзләреннән ясалган «мәсәл», «зарбе мәсәл», «әмсал», «тәмсил» кебек атамаларны да еш күрергә мөмкин. Аларның эчтәлеге «мисал итеп, үрнәк өчен сөйләү» дигәнгә кайтып кала.

Шулай итеп, бүгенге көндә җанрның фольклор фәнендә дә, халык телендә дә төп атамасы булып әверелгән «мәкаль» исеменең кулланылышка керүенә 160 елга якын вакыт үткән булып чыга. Ә элеккерәк заманнарда мәкальләр ничек аталганнар соң? Бу сорауга җавапны өлешчә борынгы кулъязма чыганаклардан табарга мөмкин. Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә (1072–1074) мәкаль «сав» (сүз, хәбәр) дип йөртелә. Ул заманнарда җанрның «абышка сөзе» (картлар сүзе) дигән атамасы да булуы билгеле. Мәсәлән, атаклы шагыйрь Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек», ягъни «Бәхетле булу белеме» поэмасында (1069–1070) «Негү тер эшит бу абышка сөзи» (Нәрсә ди, ишет бу картлар сүзе) «Абышка сөзин тут, унутма» (Картлар сүзен тот, онытма) кебек юллар очрый.

Инде татарларга килсәк, безнең халыкта да XX йөзнең кырыгынчы елларына кадәр җанлы сөйләмдә дә, басма чыганакларда да, «мәкаль» һәм башка гарәпчә атамалар белән рәттән, «борынгылар сүзе», «ата-баба сүзе», «картлар сүзе», «халык сүзе», «гыйбрәтле сүзләр» кебек исемнәр еш кулланыла иде. Мондый атамалар мәкаль текстларының үзләрендә дә беркетелгән: «Борынгылар сүзен тыңламасаң, борының сынар», «Амбар

төбендә икмәк бар, картлар сүзендә хикмәт бар», «Аталар сүзе — акылның үзе» һ. б. Күренә ки, бу мисаллар мәкальнең исеме генә түгел, бәлки җисеме турында да әһәмиятле төшенчә бирәләр.

Мәкальләрне өйрәнүчеләр барысы да бу төр әсәрләрнең төгәлләнгән җөмләдән торуын, образлы булуын, тормыш тәҗрибәсен гомумиләштереп, билгеле бер нәтиҗә, хөкем чыгаруын, гыйбрәт, үгет-нәсыйхәт өчен, ягъни дидактик максатта әйтелүен, еш кына шигъри формада төзелүен һәм сөйләмгә матурлык, тәэсирлелек бирүен күрсәтәләр.

Әлбәттә, мәкальнең әһәмиятен, аның тормыштагы вазифаларын кыска билгеләмә эченә генә сыйдыру мөмкин түгел. Барыннан да элек, шуны истә тотарга кирәк: мәкальнең табигый башкарылуы, ягъни халыкның җанлы сөйләмендә кулланылышы һәрвакыт тормыш-көнкүрештәге конкрет вакыйгалар белән бәйләнгән була. Мәкаль теге яки бу вакыйгага, вазгыятькә, күренешкә, очракка бәя бирү, аңа карата мөнәсәбәт белдерү өчен әйтелә. Мәкаль өйрәтә, киңәш бирә, аңа күрәзәлек кылу, алдан хәбәр биреп, кисәтеп кую сыйфатлары да хас. Мәкальләр үз эчләренә халык акылын, аның мең еллар буена тупланып килгән бай тормыш тәҗрибәсен сыйдырганнар. Аларда халыкның тормышка, хезмәткә, җәмгыятькә, гаиләгә, әхлак мәсьәләләренә абруйлы карашы һәм мөнәсәбәте белдерелә. Шуңа күрә дә халык үзенең мәкальләре аша элек-электән үк кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында туган җиргә, Ватанга мәхәббәт һәм бирелгәнлек, ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт-итагать, хезмәт сөю, һөнәргә, белемгә омтылу, батырлык, гаделлек, сабырлык, тыйнаклык, юмартлык, пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләп килгән.

Туган илне сөю, ватанчылык хисе — кеше күңелендәге иң изге, иң нечкә һәм иң олы хис. Халык аны әхлакый сыйфатларның иң югарысы итеп саный. Туган илнең якынлыгы, газизлеге турында сөйләүче мәкальләргә хис-тойгы тирәнлеге, самимилек хас:

Ватансыз кеше — бакчасыз сандугач.
Туган җирдәй җир булмас, туган илдәй ил булмас.
Үз илең — гөлстан, кеше иле — гүрстан.
Үз илең — үз анаң, үзгә ил — үги анаң.

Туган илдән аерылу, чит җирләрдә яшәргә мәҗбүр булу, халык карашынча, кеше башына килә торган бик зур бәхетсезлек булып санала. Мондый эчтәлектәге мәкальләр шушы фаҗигале язмышны үзе дә кичергән татар халкының ачы тәҗрибә авазы кебек кабул ителәләр:

Иң зур сагыш — Ватан сагышы.
Читтә йөргән тарыгыр, туган илен сагыныр.
Ачтан үлсәң дә, туган илеңне ташлама.
Илгә сыймаган баш — Иделгә баткан таш.

Ватанга мәхәббәт хисен халык ниндидер абстракт төшенчә итеп аңламый. Бу мәхәббәт кешенең эшгамәлендә төгәл гәүдәләнеш табарга тиеш. Ватан шәхес турында кайгыртучанлык күрсәткән кебек, шәхес тә үз Ватанының иминлеге, байлыгы һәм көчле булуы турында кайгыртырга бурычлы. Менә шушы идея халыкның күп кенә мәкальләре буенча кызыл җеп булып үтә:

Ил көенгәндә көен, ил сөенгәндә сөен.
Ир-егетнең яхшысы ил белән.
Ил өметен ир аклар, ирнең данын ил саклар.
Ирнең даны — иленнән, халкы белән җиреннән.
Ил гамен җыйган ир ил агасы булыр.
Ил барда ир хур булмас, ир барда ил хур булмас.

Татар халык мәкальләрендә шулай ук бик борынгыдан бирле һәм тирән яктыртылып килүче янә бер тема — ул гыйлем, белем алу темасы. Әлбәттә, моның киң тарихи җирлеге бар. Идел Болгарстаны турындагы борынгы язмаларның һәркайсында диярлек бу илдә фәннең, мәдәниятнең нык үскән булуы, мәгариф эшенең киң җәелгәнлеге әйтеп үтелә. X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе Ибне Рустә инде ул заманнарда ук болгар шәһәрләре һәм авылларының барысында да башлангыч мәктәпләр булганлыгын язып калдырган. Болгар, Биләр кебек зур шәһәрләрдә исә югары уку йортлары — атаклы мәдрәсәләр эшләгән. Шәһре Болгар мәдрәсәсенә белем алу өчен чит илләрдән дә күп килгәннәр.

Мондый фактлар татар халкының аң-белемгә, мәгърифәткә булган омтылышының бик ерактан килүе һәм ифрат дәрәҗәдә көчле булуы хакында сөйли. Моны без күп санлы мәкаль-әйтемнәрдә дә ачык күрәбез:

Дөньяда иң зур байлык — белем.
Белем — бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы.
Патша үз илендә генә патша, галим — һәркайда галим.

Акча, мал — бер көнлек, гыйлем, һөнәр — гомерлек.
Мәктәп юлы — җәннәт юлы.

Халыкның фән-белемгә булган мондый зур хөрмәтен ике яктан карап аңлатып булыр иде. Беренчедән, ул белемгә олы рухи хәзинә, күңел нуры, акыл-хикмәт чыганагы итеп карый:

Тән рәхәте — сәламәтлек, җан рәхәте — гыйлем.
Кояш җирне яктырта, уку — мине яктырта.
Гадел яшә, рәхәте зур булыр.
Гыйлем өйрән — күңелең нур булыр.
Тән зиннәте — кием, акыл зиннәте — гыйлем.

Икенчедән, халык белемнең гамәли файдасына да гаять зур әһәмият бирә, аның тормышны алга җибәрү, тәрәккыяткә ирешү юлында көчле корал булуына басым ясый. Шунысы да игътибарга лаек: бу хактагы мәкальләрдә аерым шәхес кенә түгел, бәлки бөтен ил, халык, җымгыять мәнфәгатьләре күздә тотыла.

Укыган ил узар, укымаган ил тузар.
Укымыйча гыйлем юк, гыйлемсез көнең юк.
Гыйлем белән аз гамәл дә файдалы.
Белемсез эшләүче юлсыз җирдән баручы белән бер.

Халыкта: «Кәгазьгә язылмаган гыйлем әрәмгә югала»,— дигән мәкаль бар. Инде безнең болгар бабаларыбыз ук бу хакыйкатьне яхшы аңлаганнар. Мәгълүм булганча, Идел Болгарстанында кульязма китаплар киң таралыш тапкан. Биредә, китапка ихтыяҗ зур булу сәбәпле, китап күчереп язу белән шөгыльләнүче махсус остаханәләр эшләп килгән. Безнең китапка багышланган мәкальләребез әнә шул чорлардан ук киләләр:

Алтын җирдән табыла, белем — китаптан.
Китап — бер нәселнең икенче нәселгә калдырган мирасы.
Кулында китап булганның башында гыйлем булыр.
Кояш чыкса, табигать яңара, китап укысаң — күңел агара.

Без биредә татар халык мәкальләрендә яктыртылган ике теманы гына махсус күздән кичердек. Менә шундый күпкырлы бай эчтәлек, М. Горький әйткәнчә, «бик күп китапларга җитәрлек тирән акыллылык» мәкальдә гаҗәп кыска, җыйнак формада бирелә. Мәкальләрнең бер ишеләре шигъри калыпка салынганнар һәм ритм, рифма ягыннан камил бер дәрәҗәгә җиткерелгәннәр. Мәсәлән:

Эшчән бәхетне эшендә күрер,
Ялкау бәхетне төшендә күрер.
Күп төкерсә — күл булыр,
Күп бирексә — ил булыр.

Кайбер мәкальләрне чын мәгънәсендә тезмә әсәр дип әйтеп булмаса да, аларда шигъри сөйләмнең байтак элементларын (сүзләр, авазлар кабатланышы, эчке рифма һ. б.) табарга мөмкин. Мәсәлән: «Каены бар кайгырмас», «Биткә әйткәннән читтә әйткән яман» һ. б.

Инде менә мондый мәкальләргә игътибар итик: «Алма агачыннан ерак төшмәс», «Бер күктә ике ай булмас», «Төлке бүредән туграк тора», «Агач та җиргә төпләнә»... Болар, әлбәттә, чәчмә әсәрләр. Әмма меңнәрчә шундый мәкальләрне без фольклор җыентыкларында очратабыз, халык телендә ишетәбез. Ни өчен? Хикмәт шунда: мондый әсәрләрдә сурәтле фикер йөртүнең гаҗәп отышлы бер алымы — текстның күчерелмә мәгънәсе файдаланылган. «Тирән елга тын агар» мәкален алсак, ул: «сәләтле, булдыклы кеше үз эшен мактанмый, шапырынмый гына эшли» дигән күчерелмә мәгънә аңлату өчен кулланыла. Әмма бу фикер инде тыңлаучы аңына картиналы төстә, һәркем аңларлык һәм ышанырлык булып барып җитә. Күчерелмә мәгънә аңлатучы шигъри мисаллар күбрәк табигать дөньясыннан, бар кешегә дә яхшы таныш, дөреслеге шик-шөбһә уятмый торган күренешләр арасыннан сайлап алыналар. Бу хәл мәкальгә сәнгатьчә матурлык биреп кенә калмый, бәлки әсәрнең ышандыру көчен дә нык арттыра. «Узган болытны тотып булмый» — үткән эшне кире кайтару мөмкин түгел; «Яңгырга чыланган тамчыдан курыкмас» — зур бәла кичергән кешенең вак-төяк кайгыга исе китмәс; «Йомшак агачны корт басар» — юаш кешенең көченнән файдаланучы күп булыр; «Талны чыбык чагында бөгеп кал» — баланы яшьтән тәр-бияләү һ.б.

Еш кына мондый мәкальләр күчерелмә мәгънәдә генә түгел, ә үзләренең туры мәгънәләрендә дә кулланыш табалар. «Ни чәчсәң, шуны урырсың» дигән мәкаль, «Кылган эшеңә карап нәтиҗәсен күрерсең» мәгънәсендә

бик борынгы язма чыганакларда ук файдаланылып килә: «Котадгу белек» поэмасында — «Нигү йиргә иксә — йәнә ул урыр», «Җөмҗөмә солтан» поэмасында (1370) — «Һәркемисә нә иксә ургай ани» һ. б. Игенчеләр телендә исә ул үзенең туры мәгънәсендә дә әйтелеп йөри: яхшы орлык чәчсәң, әйбәт уңыш җыярсың, начар орлык чәчсәң, игенең уңмас.

Кайчакта мәкаль ике өлештән: шигъри мисалдан һәм аның күчерелмә мәгънәсен аңлаткан тезмәдән тора. Мәсәлән, әле генә тикшереп үткән мәкальнең тулы варианты да бар:

Чәчкәнне урырсың,
Кылганны күрерсең.

Мондый янәшәлек алымы мәкальдә ике төрле вазифа үти: беренчедән, һәм сурәт аша, һәм турыдан-туры бер үк мәгънә аңлатылгач, әсәргә йөкләнгән фикер, хикмәт тулырак, төгәлрәк булып ачыла. Икенчедән, янәшәлек хасил итә торган җөмләләр синтаксик төзелешләре белән дә, сүзлек составлары ягыннан да бердәй булалар. Монысы инде мәкальнең шигъри яңгырашын нык көчәйтә, строфаны төрле кабатлаулар, юл башы һәм юл азагы рифмалары белән бизәп, нәфисләп җибәрә. Мәсәлән:

Агач нәселе җир үтә кирә,
Адәм нәселе ил үтә кирә.

Бу мисалда, күргәнебезчә, янәшәлекнең беренче өлеше — шигъри мисал, икенчесе — шуның күчерелмә мәгънәсе. Ләкин синтаксик янәшәлектә икесе дә күчерелмә мәгънәдәге яисә икесе дә туры мәгънәдәге тезмәләр дә бер строфага берләштерелергә мөмкин. Моннан, әлбәттә, эчтәлек тә, форма да ота гына:

Аю да баласына «аппагым» дияр,
Керпе дә баласына «йомшагым» дияр.
Оста барда кулың тый,
Галим барда телең тый.

Афористик иҗатта синтаксик янәшәлек еш кына антитеза белән бергә үрелә. Башкача әйтсәк, янәшәлек төзүче кисәкләр грамматик яктан бердәй, ә мәгънә ягыннан капма-каршы булалар. Бу хәл мәкаль өчен бик кулай. Чөнки аңа социаль каршылыкларны да, кешенең рухи сыйфатларына кагылышлы каршылыкларны да яхшысын яхшыга, яманын яманга аерып бәяләп бирергә кирәк. Капма-каршы нәрсәләрне янәшә куеп чагыштырып күрсәткәндә, һичшиксез, аларның сыйфат-хасиятләре җиңелрәк танылa, сурәттәге буяулар, штрихлар ачыграк булып күренә.

Татар мәкальләрендә антитезалы тасвир өчен файдаланыла торган «би — кол», «бай — ярлы», «иске — яңа», «эч — тыш», «эшчән — ялкау», «батыр — куркак», «галим — надан», «юмарт — саран» кебек йөзләрчә антонимнар бар: «Байның малы йөрер, ярлының җаны йөрер», «Батыр ут булыр, куркак юк булыр», «Галим кеше үлсә дә терек, надан кеше тере булса да үлек» һ. б.

Мәкальләрне сурәтле, сәнгатьчә нәфис итүдә төрле тел бизәкләре (чагыштыру, метафора, җанландыру һ. б.) зур роль уйный: «Татлы булсаң, балдай бул, ачы булсаң, тоздай бул», «Ир-егет — ил күзгесе», «Дөнья — йозак, ачкычы — белем», «Урман колаксыз, кыр күзсез булмый» һ. б. Теге яки бу сыйфатка аеруча нык игътибар юнәлтү кирәк булганда, халык гиперболадан да оста файдалана: «Беләге юан берне егар, белеме юан меңне егар», «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз»...

Афористик җанрлардан мәкальгә аеруча якын торганы — әйтем. Аларны еш кына, бер-берсеннән аермыйча, мәкальләр һәм әйтемнәр дип, бер тигез дәрәҗәдәге гыйбарәләр рәвешендә атап йөртәләр. Мәкаль шикелле үк, әйтемгә дә текстның тотрыклы булуы хас, ул да сөйләмне сәнгатьчә бизәү, аның эмоциональ көчен арттыру өчен хезмәт итә. Әмма әйтемнең мәкальдә булган дидактик гомумиләштерү, хөкем-нәтиҗә ясау сыйфаты юк. «Әйтем — сүзнең чәчәге, мәкаль — сүзнең җиләге» дигән гыйбарә нәкъ әнә шуңа басым ясый шикелле. Мәкаль-әйтем мөнәсәбәтләрен җентекләп өйрәнгән күренекле фольклорчы Н. Исәнбәт язганча: «Мәкаль булса, иң элек, ул гомуми бер хөкем, уртак төшенчә була, әйтем булса, хосусый бер нәрсәнең билгеле бер ягын әйтү генә була». Мәсәлән, юк кына нәрсәне дә зур итеп, күпертеп сөйләүне «Энәдән дөя ясау» диләр. Тәкәббер, мин-минлекле кешене: «Алланың кашка тәкәсе булдың мәллә?» — дип әрлиләр. «Бик ябык, кечкенә» диясе урында «Бер карга туярлык ите юк» дияргә мөмкин. Берәүнең эше бик алга бара башласа, «Аның мәчесе дә куян тота» яки «Аның әтәче дә йомырка сала» диләр. Күрәсез, бу мисалларның берсендә дә гомумиләштереп әйтелгән хөкем юк, аларда теге яки бу хосусый сыйфатлар гына кинаяле төстә, сурәтле-бизәкле рәвештә тасвир кылына. Ә менә «Байның мәчесе дә куян тота» дисәк, бу гыйбарә инде гомумиләштерү көче алыр, ягъни мәкальгә әверелер иде. Чөнки адым саен, хәтта бөтенләй көтелмәгән урында уңышка ирешеп тору байлар өчен табигый хәл.

Мәкаль белән әйтемне аерганда еш кына «мәкаль тулы җөмләле була, әйтем исә тәмамланган җөмлә хасил итми» дип тә әйтәләр. Күп кенә очракларда бу чыннан да шулай. Әйтик: «Теле булмаса, карга күтәреп китәр

иде», «Кулыннан гөлләр тама», «Тавык мие эчкән» һ. б. Ләкин мондый тәгъбирләр сөйләмдә кулланылганда тулыланалар, конкрет кешеләргә яки әйберләргә нисбәтләнәләр. Аннан тулы җөмләгә охшаш әйтемнәр дә юк түгел. Мәсәлән: «Ат юк, арба юк, аннан кала бар да юк», «Әлеге дә баягы, Биби түти таягы», «Ата улны белми, ана кызны белми» һ. б. Мондый төзелештәге әйтемнәрне мәкальдән аеруның бер җиңел юлы бар: аларның һәркайсының мәгънәсен бер синоним сүз белән алыштырып була. Әле генә китерелгән «Ата улны белми, ана кызны белми» гыйбарәсе, шик тә юк, мәкаль түгел, ә әйтем һәм ул «ыгы-зыгы» дигәнне аңлата. Яки: «Аның чәённән Ослан тавы күренә» —сыек чәй һ. б.

Хәзер карап үтелгән мисаллардан да күренгәнчә, әйтемнәрнең күбесенә ирония, шаярту, юмор хас. Афористик жанрлар арасында әле махсус рәвештә шаян сүз итеп, кешеләрне көлдерү, күңел ачу хакына гына әйтелеп йөри торган гыйбарәләр дә бар. Аларның исеме дә җор сүз дип атала. Менә фольклор җыентыкларында еш очрый торган кайбер үрнәкләр: «Уз түрдән, утыр ишек төбеннән», «Нигә китмисең, утыр әле», «Рәхмәт, сыйладыгыз, баегыз, тегермән салыгыз, онны сатып алыгыз» һ. б. Болардан күренгәнчә, җор сүзләр өчен уенын-чынын бергә кушыбрак сөйләү, беренче тыңлауга яхшы теләк әйткәндәй булып та, чынлыкта бераз «чеметеп», төрттереп алу, «йомшак җәеп катыга утырту» кебек сыйфатлар хас. Ләкин җор сүзләр күбрәк шаярышу, көлешү максатында әйтелгәнгә, алар үпкә һәм ачу белән кабул ителми. Хәзер китереп үтелгән мисаллар барысы да диярлек кунак каршылау һәм сыйлау вакытында, мәҗлестәгеләрнең күңелен табу хакына кулланылалар.

Без күзәтеп үткән афоризмнарга, жанрлары, функция-вазифалары төрле-төрле булуга карамастан, бер уртаклык хас: алар барысы да фольклор әсәрләре, халыкның күмәк иҗаты җимешләре. Шул ук вакытта без мәкаль-әйтем җыентыкларында килеп чыгышлары буенча язма әдәбиятка караган текстларга да юлыгабыз. Мәсәлән, «Йимәс эт саркытын килеп арыслан», «Елан башын дошман әле белән яньчегел» («Эттән калганны арыслан ашамас», «Елан башын дошман кулы белән яньче») кебек гыйбарәләр XVI йөз шагыйре Сәйф Сараи шигъриятеннән үк киләләр. Безнең чорда Г. Тукай, М. Гафури, Һ. Такташ, Х. Туфан, Ф. Кәрим, М. Җәлил кебек күренекле шагыйрьләрнең күп санлы афоризмнары халык телендә мәкальләр белән рәттән әйтелеп йөри- ләр. Фольклорга әдәби чыганаклардан күчкән, димәк ки, авторлары билгеле булган мондый өзек-цитаталарны канатлы сүзләр (әйтелмәләр) дип атыйлар. Шулай ук атаклы тарихи шәхесләрнең, популяр әдәби геройларның хикмәтле сүзләре канатлы әйтелмә булып телгә кереп киткән очраклар байтак. Алар да, нигездә, халык мәкальләре башкарган функцияләрне үтиләр. Әлбәттә, стилистик яктан канатлы сүзләр фольклор текстларыннан беркадәр аерылалар, әмма кайчакта, халык телендә озак йөри-йөри, мондый аерымлыклар да сизелмәслек хәлгә килгән булырга мөмкин.

Халык афоризмнарының бу икенче китабына югарыда карап үтелгән дүрт жанр үрнәкләре — мәкальләр, канатлы сүзләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр тупланды. Алар 19 тематик бүлеккә аерылды. Һәр тема үз эчендә ваграк темаларга бүленгән. Әйтик, «Хайваннар» бүлеге. Ул үзе кыргый хайваннар һәм йорт хайваннары бүлекчәләреннән тора. Алары, үз нәүбәтендә, Арыслан, Аю, Бүре, Төлке, Ат, Сыер, Сарык, Кәҗә һ. б. тагын да кечкенәрәк бүлекчәләргә аерылалар. Һәр шундый бүлекчәдә башта әлифба тәртибендә мәкальләр һәм канатлы сүзләр, аннары — өч йолдызчык (***) билгесеннән соң — әйтемнәр һәм җор сүзләр бирелә.

Күп кенә афоризмнарның эчтәлеге текстлардагы сүзләрнең туры мәгънәләре аша белдерелә. Инде табигать дөньясыннан алынган сурәт-мисалларга килсәк, алар башлыча күчерелмә мәгънәдә — кешеләрне, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне кинаяләп сыйфатлау өчен кулланылалар. Бу хакта алдарак сүз булган иде. Менә бер-ике мисал: «Ай белән кояш берәр генә була» (ата-ана бер генә була), «Төлке тиресе ябыну» (хәйлә, алдауга салыну), «Буш башак башын югары тота» (буш кеше тәкәббер була) һ. б.

Мәгънәләрен махсус аңлату соралган сүзләр-атамаларга һәм гыйбарәләргә текстта йолдызчык (*) билгесе куеп барылды. Алар барысы да китап ахырындагы «Искәрмәләр һәм сүзлек» бүлегендә шәрехләнде.

# МӘКАЛЬЛӘР, КАНАТЛЫ СҮЗЛӘР,
# ҖОР СҮЗЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

## *Күк һәм җир*

### Күк йөзе, кояш, ай, йолдызлар

 Авызыңны ач та айны әйт, күзеңне ач та көнне* әйт.
Ай белән кояш берәр генә була.
Ай бер тулышканнан соң кире кайтыр.
Ай гел болыт артында гына тормый.
Ай — тулгач кителә.
Ай якты да, җылытмый.
Ай яктыртканда, йолдыз күренми.
Айга карап адашсаң, атыңны Тимерказыкка* бәйлә.

Айны итәк белән каплап булмый.
Акбүзат йолдыз*, Күкбүзат йолдыз*, Тимерказык бер ялгыз.

- Батып барган кояш туып килгән айга кырын карый, имеш.

- Җидегән йолдыз җиде әйләнә, Тимерказык урынында.
Җыен йолдыз җыелса да, яктылыгы айдай юк.

- Йолдызны күз бик күрә дә, кул җитми.

- Кая барсаң да, бер кояш.
Кое төбеннән караучыга күк бәләкәй, энә тишегеннән караучыга дөнья бәләкәй.
Кояш барда йолдыз күренми.
Кояш бик зур да, аны капларга кечкенә болыт та җитә.
Кояш кермәгән өйгә врач керер.
Кояш та тапсыз булмый.
Кояш югында ай да яктырта.
Кояш юк — көн юк, көн юк — тереклек юк.
Кояшка балчык атма, пычрагы үзеңә төшәр.
Кояшны култыгыңа яшерә алмассың.
Кояшның кадере баегач сизелә.
Кызарып чыккан кояшны болыт каплый.
Күк үзенең яхшылыгын җиргә төшерә.
Күк җиргә яхшылык яудырса, җир күккә тузан туздыра.
Күккә төкерсәң, битеңә төшәр.
Күләгәдә таш та мүкләнә.

- Тулган ай — тураган ит.
Түбәң күктә булса да, аягың җирдә булыр.

- Чыкмаган кояшка кызынма.

- Ярканат яратмый дип, кояш чыкмый тормый.
Яхшыга да бер кояш, яманга да бер кояш.
Яшь ай кимүдән курыкмас.

* * *

- Ай бирде, кояш күпсенде.
Ай кебек калыкты, кояш кебек балкыды.
Ай кояш булса, кеше өстенә чыгып карамас иде.
Ай күргән, кояш алган, җил очырып киткән.
Айның ундүртенче кичәсе кебек.

- Бер кояшта киндер киптергәннәр.

- Кояш куянга атланган чак.
Күк бер синең баш турында гына түгел.
Күккә баксам — күк ерак, җиргә баксам — җир каты.
Күккә менсәң — аягыңнан тартыр, җиргә керсәң — колагыңнан тартыр.
Күктән көткән, җирдән тапкан.

- Мин карыймын кояшка, кояш карый Кодашка.

- Өстенә кояш чыгармый.

## Җир өсте: ком, балчык, таш, тау, дала һ. б.

- Авыр таш, кузгатсаң, җиңеләя.
Арттан атылган таш тубыкка тия.
Ашусыз булса — таудан биз, үткелсез булса — судан биз.

- Баткак бакага килешер.
Башыңа төшсә, түмгәккә дә сәлам бирерсең.
Биек тауның башы — якын, төбе ерак күренә.
Биек тауның түбәсен күр дә төбенә барма.

- Җир астыннан йөргән еланны да сизәләр.
Җир бастырыгы — тау, тау бастырыгы — таш.
Җир чокырсыз булмас, урман киексез булмас.
Җире байның иле бай.

Җирле — җирендә, җикән — күлендә.

- Искә алмаган түмгәк чана аудара.
  Йөргән таш шомарыр, яткан таш мүкләнер.
- Кара җир астында кара елан да туйган.
  Каты җиргә казык кермәс.
  Коры җирдә чана да шумый.
- Кешегә баз казыма, үзең төшәрсең; казысаң, тирәнрәк казы — чыга алмассың.
  Кешегә таш атсаң, үз маңгаеңа тияр.
  Ком җыелса — чүл була, су җыелса — күл була.
  Кырык ел яңгыр яуса да, мәрмәр ташка су үтмәс.
  Күренгән тау ерак булмас.
  Күренмәс түмгәк ат өркетә.
- Олы ташны кече таш белән оралар.
- Сазлык җир — җәйләүгә, кыска җеп бәйләүгә ярамый.
- Тау билгесе таш булыр.
  Тау булгач, чокыры булыр.
  Тау нихәтле биек булса да, кичүе булыр.
  Тауга карап, тау булмассың, түмгәккә карап, уба булмассың.
  Тауга менүе кыен, төшүе ансат.
  Тауны тәкә сөзеп җимерә алмый.
  Таш белән атканга аш белән ат.
  Таш чүлмәккә бәрелсә дә, чүлмәк ватыла; чүлмәк ташка бәрелсә дә, чүлмәк ватыла.
  Ташны таш белән ваталар, тимерне тимер белән игиләр.
  Ташны ташлыйсы җиңел, күтәрәсе авыр.
  Тишекле таш җирдә ятмас.
  Тын сазда корт күп була.
- Урал таудай тау булмас, Урал аша су булмас.
  Уралның бер ташы тимер, бер ташы алтын.
- Ышанган тауда киек юк.
- Чокырны икене казы, үзеңә дигәнен — тирәнрәк.
- Ялгыз таш — кала булмас.
  Япанга чыксаң, япанча ал.
  Яткан таш астыннан су да акмый.

* * *

- Аңа әйткәнче бер ташка әйтсәң, таш җанланыр иде.
- Җиде кат җир астына керсә дә эзләп табар.
  Җир безне басканчы, без җиргә басып калыйк.
- Канатлы очып җитмәс җир, кайгаклы* җитеп басмас җир.
  Комнан аркан ишү.
  Куеныңда таш саклау.
- Муенга тагылган таш булдың.
- Ослан тавы күренә.
- Тузандайны тубалдай итү.
  Тауга каршы сикерү.
  Тауны талкан итү.
  Таш астында көн күрер.
  Таш астыннан чыккан.
  Таш өстендә таш калмау.
  Ташка тамга салган.
  Тәбәнәк булса да, тавым бар.
  Төтен тавы тоттыру.

**Казылма байлыклар, аларны үзләштерү**

- Алмазны алмаз белән кисәләр.
  Алмазны балчык арасына ташласаң да, алмаз булыр.

Алтын саз төбендә дә ялтырый.
Алтын туфракка аралаш чыгар.
Алтын чермәс, тимер тузмас.
Алтынны коя белмәгән эретер, тирене или белмәгән черетер.
Алтынчының бер органы — тимерченең мең органы.
Асыл таш зур булмас.

- Бакыр зур булса да, комган төбе ямыйлар, алтын кечкенә булса да, күкрәккә кадыйлар.
Бакырны никадәр юсаң да, алтын булмас.
Бармаган җирдә бакыр бар, күрмәгән җирдә көмеш бар, алмаган җирдә алтын бар.
Бриллиант кара таштан чыгар*.
Булат булатны тишми.

- Ватык гәрәбәдән туфрак яхшы.

- Гәүһәр кечкенә булса да, бәясе зур.

- Дәрья төбендәге энҗедән тау башындагы таш артык.

- Җәүһәр кадерен җәүһәрче белер.

- Иске тимерне сакласаң, алтын булыр.

- Калайны күпме шомартсаң да, көмеш булмас.
Калын сандал чүкечтән курыкмас.
Кара алтын — җир мае, аның белән ил байый.
Кургашны көмеш дигәннәр, эрегән дә төшкән.
Күк тимер кайрау белән алмаз булмас*.

- Тимер булса, алтын да табыла.
Тимере бар тилмермәс, каены бар кайгырмас.
Тимерне кызуында сук, балыкны уйнаганда тот.
Тимерче кулында тимер балавыз кебек эрер.
Тимерче тимерне бөксә дә ирке, сукса да ирке.
Тимерчегә күмерче юлдаш.

- Ышкылмыйча асылташ та ялтырамый.

- Энҗене эт муенына такмыйлар.
Энҗенең эт муенында кадере юк.
Эшләгән тимер ялт итәр, эшләмәгәнен тут басар.

* * *

- Алтын эчендә йөзү.

- Коеп куйган кургашын.

- Типсә тимер өзәрлек, басса бакыр өзәрлек.

- Чүкеч белән сандал арасы.

- Эш күп — күмер аз, оста күп — тимер аз.

## Сулар: чишмә, кое, елга, күл, диңгез һ. б.

- Агыйделнең аръягында — бер энәгә бер сыер, барып карасаң — чүп тә юк.
Агымга каршы йөзеп булмый.
Аккан су кире кайтмас.
Аккан суга монтар* юк.
Аулак күлгә бака хуҗа.
Ашыккан су диңгезгә җитмәс.

- Бата торган — еланга да тотына.
Батсаң, таза суга бат.
Бер су белән генә торып булса, балык кармакка капмас иде.
Бер тамчыдан диңгез булмый.
Бик шәп аккан чишмәнең башы якын була, имеш.
Болганган су тирән күренер.
Болганчык суда балык тотарга яхшы.
Бәкедән күпме бу чыкса да, казан булмас.

- Дәрьядагы балык сатылмас.

Диңгез янында кое казымыйлар.
Диңгездә су кыйбат.
Диңгезне шырпы белән болгатып булмый.
Диңгезнең дә чиге бар, елганың да яры бар.

- Елга күпме боргаланса да, диңгезгә төшәр.
  Елганың башы комлы булса, тамагы да комлы була.
  Ерактагы су белән сусын канмый*.

- Идел кичмичә аягыңны киптермә.
  Идел күрми итек чишмиләр.
  Ишегалдыннан аккан суның кадере юк.

- Кайда су чыкса, коены шунда казыйлар.
  Кечкенә елга ташыса, кичү бирмәс.
  Кешегә кое казысаң, үзең буе казы.
  Килегә салып су төймиләр.
  Коега таш ташлау җиңел, алуы авыр.
  Коега төкермә, кайтып су эчәрсең.
  Күл булса, бака борынын тыгар.
  Күл тамчыдан җыела.
  Күл тирән булган саен балыгы күп.
  Күл шайтансыз булмый.

- Нократның* бер ташы көмеш, берсе бакыр.

- Сай елга шалтырап ага, тирән елга — тавышсыз.
  Су башыннан болгана.
  Су чокыр җиргә җыелыр.
  Су язып май төшмәс.
  Су һәр нәрсәне агарта, йөз карасын агарта алмый.
  Суга баткан — саламга ябышкан.
  Суда балык адашмас.
  Суда көймә эзе беленми.
  Суны ут алмас, алтынны тут алмас.
  Суның кадере чишмә корыгач беленә.
  Сусыз җиргә йорт корма, утсыз* җиргә ил корма.

- Ташкыны кайтса да, юшкыны калыр.
  Ташыган диңгез дә кайта.
  Тонык күлдә корт була, корт булмаса, чурт була.

- Черек бау белән коега төшмә.
  Чулманны* чуманга утырып кичмиләр.

- Эчмәм диган коедан өч әйләнеп су эчәрсең.
  Эчмәс җирдә су бар, якмас җирдә ут бар.

- Яхшы суны ерак түкмиләр.

* * *

- Аның күле тирән.
  Араларыннан су да үтми.
  Аңа диңгез тубыктан.

- Баскан эздән су чыгара.
  Бер кашык су белән йотарлык.

- Диңгездән чыктым, коега баттым.

- Идел күреп сусыз үлгән.
  Идел чыкканчы балтасын бирә, Идел чыккач сабын да тоттырмый.
  Ике тамчы су кебек.

- Салкын су белән майлау.
  Су күрмичә чабуын күтәргән.

***Табигатьнең сыйфатламалары***

**Әйбер (нәрсә), аның асылы, төсе, формасы, микъдары һ. б. билгеләре**

 Авыр басканчы, җиңел калкадыр.
Аз булса җитәр, күп булса бетәр.
Аз булсын, яхшы булсын.
Аздан күп була, күптән юк була.
Ак булмаса да, пакь булсын.
Ак нәрсә кер күтәрми.
Акка кара тиз йога.
Акны күп таушалдырсаң, карага әйләнер.
Асыл нәрсә зур булмый.
Аты бер булса да, заты башка.

 Буяучыдан: «Кайсы төсне бигрәк сөясең?» — дигәнгә,—«Алтын сарысы белән көмеш агын»,— дигән.

 Вактан эре җыела.

 Җиңелне җил күтәрер, авыр урынында калыр.
Җиңелне эзләгән авырга каба.

 Зур нәрсәне кечкенә белән үлчиләр.

 Ике бер урынында, бер юк урынында.
Иске яңага урын бирер.
Искегә тисәң, исең китәр.
Искесез яңа булмас, ямансыз яхшы булмас.
Иңе барның буе бар, буе барның сыны бар.

 Кече булсаң — зур булырсың, зур булсаң — хур булырсың.
Кимнең ташуы бар, ташуның кайтуы бар.
Киң булсаң, ким булмыйсың.
Киң җирдә тар утырсаң, тар җирдә киң утырырсың.
Кәкре белән бөкере — икесе дә бер.
Кәкренең шәүләсе дә кәкре.
Күпне көткән аздан коры калыр.
Күпне күр дә фикер ит, юкны күр дә шөкер ит.

 Начарны күрмәс борын яхшының кадере юк.
Нәрсә белән нәрсә арасы — җир белән күк арасы.

 Озын янында кыска беленер.

 Тар җирдә тәгам* ашаганчы, киң җирдә таяк ашаганың яхшы.
Тышын күреп, эченнән бизмә.

 Һәрбер кара нәрсә шакшы булмас, һәрбер ялтыраган яхшы булмас.

 Чүп булып күп булганчы, аз булып үз булсын.

 Эче барның тышы бар, тышы барның төсе бар.
Эченә салмасаң, тышына чыкмас.

 Юан сузылганчы, нечкә өзелер.

 Яңа булды дип, искене ташлама.

 Җете кызыл тиз уңа.

* * *

 Ак белән караны аера белмәү.
Акка кара белән язылган.
Акны кара дип әйтү.

 Кечкенә булса да, эче төш кенә.
Кеше «ак» дисә, ул «кара» дияр.

 Сөттән ак, судан пакь.

 Тышы гөл кебек, эче көл кебек.
Тышы ефәк, эче кибәк.
Тышы мамык, эче кабык.

**Урын, ара, якын-ерак, ал-арт, ас-өс, уң-сул һ. б.**

- Адашканны артындагы белер, ялгышканны янындагы белер.
  Алга бар — артыңа кара.
  Алда барма, артта калма.
  Алдыңа бер карасаң, артыңа биш кара.
  Алдыңа кара — кая барганыңны белерсең, артыңа кара —каян чыкканыңны белерсең.
  Алдыңда — ышанычың, артыңда таянычың булсын.
  Алыска* салырсың — якыннан алырсың.
  Артыңда ни барын белмәсәң — тотылырсың, алдыңда ни барын күрмәсәң — егылырсың.
- Биек күтәрелгән егылудан курка.
  Бишкә урын табыла, бергә урын табылмый.
- Еракка куйсаң, якыннан алырсың.
  Ерактагы чап* була, килә-килә чак була.
  Ерактан арба белән китергәнче, якыннан капчык белән китер.
- Изге урын буш булмас.
- Күренгәннең алыслыгы юк, күтәргәннең авырлыгы юк.
- Түбәнгә карап шөкер ит, югарыга карап фикер ит.
  Түбәннән югарыга ун ел менәләр, югарыдан түбәнгә ун көн дә җитә.
- Үз урынын белмәгән урынсыз калыр.
  Югары менгәч, түбән карама.
  Югары менү — морат, аста калу — оят.
  Югары ятсаң — җил алыр, түбән ятсаң — сил* алыр.
  Югарыга карап куан, түбәнгә карап юан.
  Югарыга карап үрнәк ал, түбәнгә карап гыйбрәт ал.
  Югарыдан егылган сау калмый.
- Якындагын ерактан барып сора.

* * *

- Алдың — Казан өлгесе, артың — Мәскәү көзгесе.
  Алдыңда — ялтырый, артыңда — шалтырый.
  Алдыңнан артың матур.
  Арттан караганда алда, үзе һаман анда.
  Астан кереп, өстән чыккан.
  Астан уеп, өстән җую.
  Асты — тәпи, өсте — тәти.
  Астыннан кисеп, өстеннән ямый.
- Бер алдына, биш артына төшү.
  Берсе уңга ишә, берсе сулга ишә.
- Дүрт ягың — кыйбла.
- Еракта — кешнәшер, якында — тешләшер.
- Кырындагын кырык ел эзләгән.
- Ни ылтара, ни пылтара — калган ике уртада.
- Өскә куйсаң — аз, аска куйсаң — таз.
  Өстәгесен уя, астагысын суя.
- Сул ягы белән торган.
- Уңга да юк, сулга да юк.
- Югары булып күктә юк, түбән булып җирдә юк.

**Вакыт, заман, ел һәм ел фасыллары.  Ай, атна, көн-төн, иртә-кич һ. б.**

- Авыл башы — манара, акыл башы — замана.
  Азагын күрсәтмәсәң, башын башлама.
  Ай да килгәнгә аяк*, көн дә килгәнгә таяк.

Айлар да тигез түгел: берсе озын, берсе кыска.
Айның утыз көне бар, утыз төне бар.
Алдан барган алланган, соңга калган алданган.
Алдан килгән урын өчен, соңыннан килгән тамак өчен.
Алды барның арты бар, февральнең марты бар.
Апрель кергәч эт биеклеге кар ява.
Атна кичнең килеше чәршәмбедән билгеле.

Баткан көннең аткан таңы бар.
Башы барның соңы бар, әүвәле барның ахыры бар.
Бер елга куян тиресе дә чыдый.
Бер елда ике яз булмый.
Бер елны бүдәнә симерсә, икенче елны тартар симерә.
Бер карлыгач белән яз булмый.
Бер кичкә кер мичкә.
Бер кырпак* белән кыш булмас.
Бер көн артка калсаң, биш көн артка калырсың.
Борынгының борыны сынган, ди.
Бу чакта йомырка тавыктан күп белә.
Бу чакта бияләй эчендә бармак кыймылдатканны беләләр.
Булса унбер сентябрь, җәйдән инде бит сыпыр.
Былтыр кысканга быел кычкырмыйлар.
Былтыр үлгән күсе — быел чыккан исе.
Былтырны шүрәле дә эзләп тапмаган.
Бүген белән көн бетми.
Бүген үлгәнче таңда үл.
Бүгенге хисап иртәгә ярамый.

Вакыт акча түгел, югалтсаң таба алмассың.
Вакыт акчадан кадерлерәк.
Вакыт белән якут табып була, якут белән вакыт табып булмый.
Вакыт комны ташка, ташны комга әйләндерә.
Вакытлы эш вакытында яхшы.
Вакытның дилбегәсе юк.
Вакытың үтте — бәхетең китте.

Заман кош кебек: очып киткәч кире кайтмый.
Заман сиңа буен куймас, син заманга буең куй.
Заман үзе өйрәтә.
Замана — көчленеке.
Заманасына күрә дуңгызны җизни диярсең.
Заманны бернинди җәүһәргә дә алмашып булмый.
Заманның ялына ябыш.
Заманың ничек булса, бүркеңне шулай ки.
Заманың төлке булса, син тазы* бул.

Ел белән ел шай түгел, яз белән көз — җәй түгел.

Җәй көне чанаңны, кыш көне арбаңны әзерләп куй.
Җәй көне бияләй, кыш көне майка сатып ал.
Җәй көне йоклама, кыш көне өлгерерсең.
Җәй эшләсәң, кыш ашарсың.
Җәйгә чыккан җан үлмәс.
Җәйгә чыксаң кышны уйла, кышка керсәң җәйне уйла.

Иртә барсаң ит пешәр, соңга калсаң бит пешәр.
Иртә торган эшеннән куанган.
Иртә торганга ике өлеш.
Иртә торганның эше үрчи, төн йокламаганның юлы үрчи.
Иртә торсаң эш бетәр, соңга калсаң көч бетәр.
Иртә чыксаң — алдыңнан көн чыга, кич чыксаң — алдыңа төн чыга.
Иртә чәчкән уңар, буразнасы тулар.
Иртәгәге тавыктан бүгенге йомырка артык.
Иртәгәгә ышанып, бүгенге көнеңне кулдан ычкындырма.

Кавәс* тумый кыш булмый, җәүза* тумый җәй булмый.
Кантарда* калфак кимә, яз көне бүрек кимә.
Кара көзнең кары ятмас.
Караңгы төннән соң якты көн килә.
Караңгыда күз кыскан беленми.
Караңгыда ялтыраганчы, яктыда калтыра.
Кешегә калган көн — таң атмаган төн.
Кич булмыйча бүгенге көнне мактама.
Коралай* килми — кыш җитми, коралай китми — яз җитми.
Кунмыйм дигәнне караңгы кундырыр, адашмыйм дигәнне буран адаштырыр.
Кыш бетте дип тун сатма, янә кыш бар.
Кыш — кыямәт, яз — җәннәт.
Кыш көне җиде җилән кигәнче бер тун ки.
Кыш көне эт тә: «Җәйгә чыксам сөяктән сарай салыр идем»,— дип әйтер, ди.
Кыш рәхәт чанага, җәй рәхәт арбага.
Кыш җитсә, буран туздырыр; җәй җитсә, кояш кыздырыр.
Кыш — үги ана, яз — үз ана.
Кышка каршы тиен дә запас җыя.
Кышкы көннең җылынуына ышанма.
Кышкы көннәр җәйне әйтер, җәйге көннәр җайны әйтер.
Кышның күзе караңгы: ни кисәң дә ярый.
Көз бай булма, яз бай бул.
Көз кычкыра: «Уңдырам»,— дип, ә яз әйтә: «Тукта әле, мин нәрсә әйтермен»,— дип.
Көзге катык — көмеш кашык, язгы катык — ярты азык.
Көзге көн — арткы акыл, язгы көн — ярты акыл.
Көзге көн — кияү акылы, язгы көн — яшь килен йөзе.
Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле җылый.
Көзге көннән язгы төн яхшы.
Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал.
Көн белән төн бер булмый.
Көн дә килгән — көл чүмече, ай да килгән — ай табагы.
Көн көнгә охшап тумас, көн саен кояш булмас.
Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр.
Көн — эш өчен, төн — ял өчен.
Көндез таш ват, төнлә тыныч йокла.
Көндезге эш кичке эштән көлер.
Көннең киче иртәсеннән билгеле.
Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы*.

Март аенда урамда чыпчык эчәрлек су була.
Март ишектән бактырыр, сәнәк-көрәк яктырыр.
Март: «Хут* урынында булсам, сыерның мөгезен сындырыр идем»,— дип әйтә, ди.
Март әйтә, имеш: «Көндез-көндез көләрмен, иртә-кичен бөгәрмен».
Микула* җитми җәй булмый, Микула җитми кыш булмый.
Минутында тотмасаң, сәгатендә тоталмассың.

Октябрь — кара бия, ноябрь — ала бия.
Октябрь ни арба, ни чана.

Питраудан* соң сандугачның теле бетә, үләннең тәме бетә.
Покрау* үтте — кыш җитте.

Санаулы көн тиз үтә.
Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер, ай, май!
Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер, апрель аптырата.
Сентябрьдә эти дә бер, мин дә бер; мартта — эти алда, мин —артта.
Сентябрьнең ундүртендә чикмән төшә, тун менә.
Сәвердә* сулар сәер була.
Сәвердәге явым — савып торган савым.
Сөмбелә* туса, су суыныр.

Таңы атмаган төн булмас.
Теләмә озын җәй, телә җылы җәй.

Тәңре көне тарыдан да күп.
Төн кара булган саен йолдыз яктырак янар.
Төннең колагы йөз дә бер, йөз дә бере дә бик үткен була, ди.
Төннең тынычлыгы — көннең куанычы.

 Урак ае* — тавыкларның сусыз ае, балаларның үксез ае.

 Февральдә суык: «Сыерның мөгезен сындырыр идем дә, көнем кыска»,— дип әйтә, ди, имеш.
Февральдә сыер мөгезен сындырырлык суыклар була.

 Хут мартка: «Селәгәең җый, әй селәгәй»,— дип әйтә, ди.
Хутта ут итә, хәмәлдә* әмәлеңне корыта.
Хәмәлдә хәл китә.

 Һәр айның аты башка, һәр атнаның көне башка.
Һәр заманның үз гореф-гадәте.
Һәр нәрсәнең вакыты бар.

 Элҗен* көн суга бер кашык салкын кушыла икән.
Энем кырлач* «агам кырлачтан* уздырыйм» дип, тырыша, ди.
Энем кырлач әйткән: «Агам кырлачны уздырам, яшь киленнәрнең көянтәсен сындырам».

 Челләдә* туның ташлама, кыш үзең бел.
Челләдә черем итсәң, кыш рәхәт йокларсың.

 Яз башының чуагы* каты кыздыра.
Яз берәүне аздырыр, берәүне малдан яздырыр.
Яз кайгысын кыш кайгырт, кыш кайгысын яз кайгырт.
Яз киреләнсә кыштан яман.
Яз сөрсәң, көз урырсың.
Яз уңмаган көз уңмас.
Яз яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән.
Яз япанчаңны, кыш азыгыңны онытма.
Яз җитсә чебенгә дә җан керә.
Язгы көн ел туйдыра.
Язгы хезмәт — көзге хөрмәт.
Язның байлыгы — кояш, көзнең байлыгы — уңыш.
Язның пычрагы да ямьле була.
Январьнең көне кыска, февральнең ае кыска.
Яңа елда ярлы да бай була.

* * *

 Ак җәймәле көн туу.
Атнада җиде җомга.
Атнасына алты ял.

 Бүген бар, иртәгә юк.
Бүген болай, таңда әллә ничек.

 Дерен-дерен, дерендә, ике көннең берендә.

 Җәен өйдә боз киптереп, кышын суган саталар.
Җәй алмаска, кыш бирмәскә.
Җәй бар, кыш бар, ашыгып ни эш бар.
Җәй җәйләдем, кыш кышладым, мич башыннан төшмәдем.

 Кыш булганын колагы туңганнан белгән.
Кыш көне кулыннан кар ала алмассың.
Көн узсын, йон тузсын.
Көндез шырпы белән эзләү.
Көне ай кебек, ае ел кебек.
Көнен күрсен, көлдә аунасын.

 Мондый көндә яхшы кешенең эте дә йөрмәс.

 Нух пәйгамбәр заманыннан*.

 Раштуада* бер көрәк кар бирмәс.

 Сәгате ай, ае ел күк.

- Таң белән атып, көн белән батып.
  Төн чыкканчы йон чыкмас.
- Чиллә чагында катып үлгән.
- Яз җиткәнне җилкәсе җылынгач белгән.
  Яренгә* кем бар, кем юк.

**Һава торышы: җылы-суык, җил-давыл, явым-төшем һ. б.**

- Артка калган болыт яумый үтәр.
  Ачлыкка түзеп була, суыкка — юк.
  Аяз-аяз көннәрдә җиләк җыяр аппагым, болыт-болыт көннәрдә урак урыр аппагым.
  Аяз көннең яшененнән курык.
- Батканга яңгыр куркыныч түгел.
  Бер болыттан боз да явар, кар да, яңгыр да явар.
  Болытсыз яңгыр булмас.
- Вак яңгыр чылата.
- Давыл алды тын була.
  Давыллы болытның явымы аз.
  Дәрьяга яңгыр яуганнан ни файда.
- Җил алдан булса — битең туңдырыр, арттан булса — туның туздырыр.
  Җил исми яфрак селкенми.
  Җил кай якка иссә, камыш шул якка борылыр.
  Җил чәчсәң, давыл урырсың.
  Җил җелеккә үтәр.
  Җил җилләми, томан ачылмый.
  Җилгә каршы төкермә, битеңә төшәр.
  Җилгә сәнәк белән каршы тормыйлар.
  Җилдән килгән, җилгә киткән.
  Җиле булгач, бураны булыр.
  Җилне төтен кумый, җил төтенне куа.
  Җилнең эше суырмак, утның эше куырмак.
  Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый.
- Иртәнге яңгыр төшкә хәтле.
- Кар астыннан карга тизәге дә табылмас.
  Кар башын кар ашый.
  Кар матур да, аякны туңдыра.
  Кар яуганда салкын булмый, кар киткәндә суыта.
  Кара суык кардан яман.
  Кара җиргә кар яуса, карны күрү бер зәвык; кара җирдән кар китсә, җирне күрү бер зәвык.
  Кардан гөмбә эзләмә.
  Карның базга салганы да бетә.
  Кары калын кышның үләне калын булыр.
  Кары эресә дә, бозы кала.
  Каты давыл тиз туктар.
  Килмәгән болыт, яумаган яңгырга чиләк тотмыйлар.
  Кызуы да пешерә, суыгы да пешерә.
  Көзге бозның көзге калынлыгына да ышан, язгы бозның ястык калынлыгына да ышанма.
  Күк күкрәмичә «алла» димиләр.
  Күкрәгән болытның явымы аз.
- Ләйсән* — рәхмәт яңгыры.
  Ләйсән суын җиде ел сакласаң, энҗегә әверелә, имеш.
- Суык белән эт — сәләмәгә үч.
  Суык төлке тунлы кешегә сәлам бирә, ертык тунлы кешенең куенына керә, имеш.
- Тама-тама күл булыр, тузан-тузан тау булыр.
  Тамчы кечкенә генә — таш тишә.
  Тамчы тамса да, диңгезгә су файда.

Тамчыдан качкан явымга юлыгыр.
Тамчысыз диңгез булмый.
Томан төшә — җимешләр пешә.

- Узган болытны тотып булмый.

- Хәерсез болыт диңгезгә явар.

- Чык суы матур булса да, сусын кандыра алмассың.

- Шаулы яңгыр тиз үтәр.
  Шәп яуган яңгыр җиргә сеңми.

- Явым теләсәң, давылына да чыда.
  Ярыктан кергән җил усал була.
  Яумасаң да, күкрә.
  Яшен яшьнәгәндә зур агачка сыенма.
  Яшене хәтәр булса да үтәр, артыннан күкрәве яман.
  Яңгыр көтсәң, кар явар.
  Яңгыр яуганда чиләгеңне тотып кал.
  Яңгыр үткәч, артыннан ябынча белән йөгермиләр.
  Яңгырга чыланган тамчыдан курыкмас.
  Яңгырда чапсаң, корыда печән җыярсың.
  Яңгырдан качып, дәрьяга төшкән.
  Яңгырдан соң тузан да басыла.
  Яңгыры булсын димә, шифасы булсын диген.

* * *

- Араларыннан җил дә үтми.
  Аяз көндә яшен сугар.
  Аяз көнне бар, болытлы көнне юк.
  Аҗаган кайнаган урын.

- Бер караганда ал да гөл, бер караганда җил-давыл.

- Җил белән симертү.
  Җил искән якка аву.
  Җил кайсы яктан исә, ул да шул яктан кисә.
  Җил ягына салам кыстыру.
  Җил-яңгыр тидермәү.
  Җилгә җиленләп, бозга бозаулап.

- Кара болыт булып йөрү.
  Кызыл кар яуганда.
  Көн явым — ят та юрганың ябын.

- Миңа дисә: ни эссе түгел, ни суык түгел.

- Салкынга өшетми, кайнарга пешерми.
  Сафура бураннары* кубару.
  Сиңа җил дә юк, яңгыр да юк.

- Төкерек җиргә төшмәслек салкын.

- Чыландык та киптердек, яңгыр безне нишләтсен.

- Яумаган яңгырга балаган кору.

### *Үсемлекләр*

### Үлән, гөмбә, гөл, чәчәк һ. б. Печән эше

- Ак алабута — ачлык елның бодае.
  Аксыргак* бар җирдә ат үлмәс.
  Актамыр* атка булган үчен сабаннан алыр.
  Алабута орлыгы булганчы, солының саламы бул.

- Әрекмәнем: кызу капса — яулыгым, баш авыртса — саулыгым.
  Әрем төбенә гөл үсмәс.

- Бер чәчкә яланны матурламый.
  Бер үк чәчәктән корт — бал җыя, елан — агу җыя.
  Берәү печәнне чалгы белән чаба, берәү дуга белән чаба.
- Вакытсыз ачылган гөл тиз сулар.
- Гөл булса, гөлгә куан, гөле булмаса, бөресенә куан.
  Гөл төбенә кычыткан үсми.
  Гөлен яраткач, чәнечкесен дә ярат.
  Гөмбә яңгырдан туймас.
- Елына бер балтырган ашамаган кешенең эче кортлар, имеш.
- Камыш, суда утырса да, бар үләннән элек корый.
  Камышны үз күлеңнән ал*.
  Корыган камыш ерактан тавыш бирер.
  Кылган башы юкка кымшанмый.
  Кырмавык үзенә тигән һәркемгә ябыша.
  Көчләп ачкан чәчәкнең исе булмас.
  Күбәдән— чүмәлә, чүмәләдән — кибән.
- Матур гөл чәнечкеле була.
  Матур чәчәкне кырау тиз ала.
- Олы юлга үлән үсми.
- Печән чабып җыелмый, тарап җыела.
- Сарана төбендә суган ятыр.
  Сары мәтрүшкә алтмыш төрле авырудан, көрән мәтрүшкә җитмеш төрле авырудан дәва.
  Сырланның үзен өзсәң дә, тамыры кала.
  Сәнәге кыйбат түгел, җәпләкәсе кыйбат.
- Тигәнәк арасына кермәгәнгә тигәнәк иярми.
  Тигәнәк арасында үскән чәчәктән саклан.
  Тигәнәк булып аякка кадалганчы, гөл булып якага кадал.
  Тигәнәк чәчеп бодай ура алмассың.
  Тик торганнан чыкан* чакмый.
- Умырзая, яфрагыннан алда, чәчәген күрсәтер*.
- Үлән башыннан корыр.
  Үсәсе чәчәк таптауда* да үсә.
- Һәр гөл үз сабагында чәчәк ата.
  Һәр гөлнең үз исе бар.
- Чабучылар начар булса, печән аз чыга.
  Чалгы тавышы чыга башласа, яңгыр ява башлый, ди.
  Чәчәкле гөл кадерле була.
  Чәчәк булган җирдә бал була.
  Чүмәлә көеңә кибәнгә үрелмә.
  Чүп җыйсаң — чүмәлә, чүмәлә җыйсаң — богыл.
- Шайтан таягына кырау тими.
- Эргәзембай* — яз күрке.
  Эт эчәгесенең очы-башы булмас.
- Яшь үләндә арык мал да уйнаклый.
  Яңа чалгы каты чаба.

* * *

- Абага чәчәк атканда*.
- Баскан җиреңә үлән бетте*.
- Гөмбә белән шалканны аера алмау.
- Ку* үләнгә үрт* салу.
  Көлдән гөл булган, гөлдән көл булган.
- Сәнәк белән көрәкне аера алмау.
  Сәнәк-көрәк кулдан китте.

Сәнәктән көрәк булган.

- Тилебәрән орлыгы ашаган.
- Урак белән печән чабу.
- Эскерттән ишек эзләү.
- Әрем белән тәрем булып яшиләр.
- Үлән арасыннан ут йөртмәк.
  Үләннән ашак*, судан тонык.
- Һәммәсе дә бердәй, бакчадагы гөлдәй.

**Игенчелек**

- Амбарың белән мактанма, ашлыгың белән мактан.
  Амбарыңда булса, кесәңдә булыр.
  Ашлаган җир аш бирә, ашламаган җир таш бирә.
  Ашлык тулган саен башын түбән ияр.
  Ашлыкны арба өйгә кертә, чана базарга илтә.
  Ашлыкның йозагы — салам, акчаның йозагы — саран.
- Башын ал да, саламына ут төрт.
  Бер башак — башак кына, йөз башактан капчык тула.
  Бер көн алдан чәчсәң, бер атна алдан урырсың.
  Булыр ашлык шытымыннан билгеле.
  Буш башак башын югары тота.
  Буш көлтәне сукмыйлар.
  Буш тегермән җилсез дә әйләнә.
  Бүген — кибәк, иртәгә — кирәк.
- Егыла башласаң, җиргә ябыш.
- Җир карынына көл салган, көленнән көмеч алган.
  Җир кемнеке — икмәге шуныкы.
  Җир туймаса ил туймас.
  Җиргә чәчкән гөл булыр, утка төшкән көл булыр.
  Җирдән аерылган җилгә оча.
  Җире — коргаксыз, кулы — коры капчык.
  Җиреңниндибулса, икмәгең шундый була.
  Җирне бер кат туйдырсаң, ул сине ун кат туйдырыр.
- Иген камылыннан билгеле.
  Иген сугучы кояш сорый, күмер сатучы яңгыр тели.
  Иген үсмәс дип, җирдән түңелмә.
  Игенеңне яшел урма, урагыңның теше сынар.
  Игенле байның исе бар, игенсез байның нисе бар.
  Игенне иң элек бурага салдым диген, аннары уңыш алдым диген.
  Игенне җир уңдырмый, тир уңдыра.
  Игеннең җаен иккән белер, арбаның җаен җиккән белер.
  Игенче — кырда, балыкчы — суда.
  Игенче явым теләгән, чүлмәкче аяз теләгән.
  Игә белгән иген ашар.
  Иксәң иген, ашарсың тиген*.
- Качып китсәң дә, чәчеп кит.
  Кем чәчкән, шул урсын.
  Киртәле кибәнгә мал тими.
  Кырга барганда мактанма, кайтканда мактан.
  Кырда калган — кар астында.
  Кырда эзе булмаганның ашъяулыкта күзе булмас.
  Кырдагы — кырда, өсәктәге* — кесәдә.
  Көз чәчсәң, көлгә чәч; яз чәчсәң, сазга чәч.
  Көз җир сөр, кыш кар сөр.
- Начар сөргән җирне чүп басар.
  Ни чәчсәң, шуны урырсың, җил чәчсәң, буран урырсың.

- Орлык кибәксез булмас.
  Орлыгын ашаган кеше — өметен ашаган кеше.
- Өйдәге исәп кырга ярамый.
  Өсәккә кермәсә, исәпкә кермәс.
- Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың.
  Сабанчыга җир — ана, ялкауга — үги ана.
  Сакла саламны — килер заманы.
  Сука тотып кулың кабармыйча, мичкә ягып ипиең кабармас.
  Сукадан тугарып атны бирмиләр.
- Тарлан җирне* саз йотмас.
  Тегермән ташына эләккән он булыр.
  Тегермән тик торса, ташы ярыла.
  Тиресне калын түшәсәң, амбарың буш калмас.
  Тук башак аска иелә, буш башак өскә үрелә.
  Туфракны җир иткән — изгелек күргән, җирне туфрак иткән — ачтан үлгән.
- Уракчының уңмаганы уракка сылтар.
  Учлап чәчсәң, йөкләп җыярсың.
- Үз чәчкәнеңне үзең ур.
- Чикерткәдән курыккан иген икмәс.
  Чәчкән — җыяр, чәчмәгән — елар.
  Чәчмәгән җиргә урак күтәреп барып булмый.
  Чүпле орлык чәчкәннең кырын кырлык* басар.
- Ындырда илле кешегә эш табыла, тиле кешегә генә эш табылмый.
- Юл буенда үскән орлык өлгерми.
- Язын иген икмәгән әтәмбигә* моң булыр.
  Яхшы җиргә төшкән орлык югалмас.

* * *

- Әвен сугып кайту.
  Әвене янган кеше сымак кылана.
- Иске кибәнем исән булсын.
- Кеше вырыхын* суыра, үзенекен җил алмый.
  Кеше уракта, без эштә.
  Кибәгеңне туздырма, күзгә керер.
- Саламга тук, башакка юк.
  Саламны печәннән аера алмау.
  Салпы ягына салам кыстыру.
  Синең урагың урган, печәнең өйгән.
  Суккан көлтә булгансың.
- Урак та урасы бар, тамак та кырасы бар.
  Ураклары урылган, зуратлары куелган.
- Чәчкән бакыра*, үзе акыра.
- Яз игенче, кыш теләнче.

**Иген төрләре**

- Алай диеп болай булмый, арпа чәчеп бодай булмый.
  Арпа алтмыш көндә өлгерә, бодай туксан көндә өлгерә.
  Арпа иккән бодай урмас.
  Арыш анасы арыштан алда өлгерә.
  Арыш башаксыз булмас, арпа кылчыксыз булмас.
  Арыш булса, башы бер карыш булсын.
  Арыш саламы алты елдан алтын булыр.
  Арыш унике көн баш чыгара, унике көн серкәдә утыра, унике көн эч иңә.
  Арыш уңса ун булып, тары уңар мең булып.
  Арыш чәчсәң, ипи ашарсың.

Арыш чәчсәң, көлгә чәч, солы чәчсәң, суга чәч.
Арышны көлгә чәчсәң, гөл булыр, солыны грәзгә* чәчсәң, кенәз булыр.
Арышның хисабын суккач беләләр.
Арышы булса, үлчәве табылыр.

- Бакра чәчкән бодай урмас.
Бер тарыдан ботка булмас, ботка булса йортка булмас.
Бер уч көнбагыш ашасаң, ике уч кабыгы чыгар.
Бодай иләп арпа төшмәс.
Бодай кибәнен арыш саламы белән ябалар.
Борчак чәчсәң, арасына сарык кереп ятарлык булсын.
Борчакның яхшысы читкә чәчри.

- Кемнең тарысы — шуның тавыгы.
Киндер ыстаны киендерә, чүпләме күзне сөендерә.
Киндер чәчсәң, күлмәк киярсең.
Коры борчак бүрәнәгә ябышмый.
Кырдагы бодай — алтмыш пот, кайткач-суккач — алты пот.

- Мәк җиде ел буе уңмаган да, аңа карап ачлык булмаган.

- Пәҗи* килегә кермичә, мае чыкмас.

- Саламга үскән арышның башы булмый.
Солы чәчеп бодай көтмиләр.

- Тармадан* тула басмыйлар.
Тары чалгы кайраган тавышка үсә, ди.
Тары ярмасы сөттә җитмеш җиде кисәккә ярыла.
Тургайдан курыксаң, тары икмә.

- Уңган бодайга кырау тими.

- Чүбек чәйнәп май чыкмас.

- Җитен: «Тырмага ияреп тишелеп чыгар идем дә, кешедән оялам»,— дип әйтә, ди.

* * *

- Арпа эчендә бер бодай.

- Башын карабодай саламы белән япкан*.
Бирдем бодай, килдем сорай.
Бодай буласы җиргә борай булып калган.
Бодай күрсәтеп арпа саткан.

- Менә сиңа тары — хәзинәдә бары.

- Ташта борчак үстерү.

- Ярмам арыш, җаным тыныч.

**Яшелчәләр**

- Ачы кабакка эт тә тими.
Ачы торманың сирәге яхшы.

- Бакча байлык — бер айлык, тагы да килер гидайлык*.
Бакча иясенә түтәл юк, өй иясенә бүкән юк.
Берәүгә торма кирәк, берәүгә хөрмә кирәк.
Буш карбызда орлык күп.
Бәрәңге ашаган тук булыр, тез буыны юк булыр.
Бәрәңге — ярты икмәк.
Бәрәңге әйткән: «Илтүен илтермен, кайтуыңны үзең кайгырт»— дигән.
Бәрәңге әйткән: «Кырык биш көндә карыныңа керермен»,— дигән.

- Җимеш юк җирдә чөгендерне дә әфлисун диләр.
Җир алмасы* җилектерми*.

- Ике карбыз бер култыкка сыймас.

- Кабак карбызга әйткән: «Мин олы»,— дигән. Карбыз әйткән: «Син олы булсаң, мин баллы»,— дигән.
Керән тормадан татлы булмас.

Кәбестә аркасында суган да су эчә.

 Мич башында шалкан пешми.

 Сарымсак хаҗга барып кайтса да татлыланмас.
Сарымсакны серкәгә салып тотсаң да, сигез ел исен саклый.
Сирәк торма төпле була.
Суган сирәк булса, башы олы булыр.
Суганның татлысы юк.

 Тиле суган сабакка уңар.
Торма: «Мин бал белән тәмле»,— дигәч, бал аңа: «Мин синнән башка да тәмле!» — дигән.

 Шалканны ефәккә төргәннән бәясе артмас, энҗене ыштырга төргәннән бәясе кимемәс.

 Ярык карбызда тәм булмас.

* * *

 Акча җимеше түгел, бакча җимеше.

 Бакчачының бакчасы, утап кына баксачы.
Бер керән ашап, ике атна кикергән.

 Кирәкле кишер яфрагы.
Кәбестә кебек беркатлы инде ул.

 Пешкән шалкан, төшкән-калган.

 Суган суы суыру.
Суган тураганда елый.

 Торма ачуын тоздан алу.
Торма өстенә тоз.

**Агач**

 Авам-авам дигән агач йөз яши.
Агач аеры үссә дә тамыры бер.
Агач кайсы якка кыек булса, шул якка авар.
Агач нинди генә биек булса да, тамыры җирдә булыр.
Агач урманнан ерак үссә дә, шунда таба сыгыла.
Агач утырткан ага булган.
Агач хәтта үзен кисүчегә дә күләгә бирә.
Агач яшь вакытында яхшы бөгелер.
Агач үз ихтыяры белән урманын ташламый.
Агач үз урынына егыла, таш бик ерак тәгәри.
Агачны яшьлектә бөк.
Агачны үстерергә илле ел, кисәргә биш минут кирәк.
Агачның аскы ботаклары өскеләрен күтәрешә.
Агачның башын киссәң төбе калыр.
Агачның корты эченнән булыр.
Агачның тамырына балта чабып, яфрагы белән дус булма.
Агачның яфрагы түбенә төшә.
Агачтан яфрак төшми тормый.
Асылсаң асыл асыл агачка, егылсаң егыл мамык түшәккә.

 Бер агачның шаулавы илгә яңгыр яудырмас.
Бер агачта ике кайры булмас.
Бер шыгырдаган агач гомер буе шыгырдый.
Ботаксыз агачның күрке юк.

 Иелгән агачка үрмәләү җиңел.

 Йомшак агачны корт басар.

 Карт агач үзеннән-үзе корыр.
Каты агач шарт сынар, черегән агач кырык ел чыдар.
Корт баскан черек ботакны кисеп ташлыйлар.
Кыеш агачның ботагы туры булмас.
Кыйшык агач төзне бозар.

Кәкре үсеп картайган агачны төз итеп булмый.
Күмәк агач давылдан курыкмас.

- Тамыры ерак агачның гомере озак.
Тотынган агачыңның тамыры нык булсын.
Туры агачның күләгәсе дә туры була.

- Хур күргән агачың гүр өстеңә күләгә булыр.

- Чүлгә кое казыган — бер саваплы, сазга күпер салган — ике саваплы, юлга агач утырткан — өч саваплы.

- Шыгырдавыклы агач озак чыдар, шыгырдамаган тиз сынар.
Шәрә агачтан ышык көтмә.

- Ялгыз агач урман булмас, ялгыз кирпеч курган* булмас.
Ялгыз агач җилдә тиз сына.
Ялгыз агачны җил борган, күмәк агач җилне борган.
Яман агачка асылынганчы, яхшы агач үзеңне бассын.

* * *

- Агач арасыннан урман күрмәгән.
Агачтан сандугач кына ясамый.

- Ике агач арасында адашу.

- Яфрак астына керү*.

**Агач төрләре**

- Бер каенның күләгәсе бөтен илне капламас.
Бәрмәчлектән* йөзем булмас.

- Имән агач — каты агач, каен агач — чырагач.
Имән агачының иелгәне — сынганы.
Имән бик каты агач та, аның да яфрагы саргая.
Имән күмере исле булыр.
Имән чикләвеге алмагач төбенә тәгәрәми.

- Каен агач тал булмас, каен суы бал булмас.
Каен тузына масаер, имән үзенә масаер.
Каены бар кайгырмас, тимере бар тилмермәс.
Карагайның көле күп, имәннең күмере күп.
Карама агачы — каршы агач.
Карышып үскән караманы турайталмассың.
Кечкенә имәндә ботак күп була.
Корыган тирәк су янында да яшәрмәс.
Куба тал шарт сынар, сары тал йөгенеп* калыр.

- Нарат — башыннан, имән — төбеннән корый.
Нарат төз карап үсәр, өянке өялэп үсәр.

- Озын тирәкнең күләгәсе төбенә төшмәс.

- Тал ком ярата, усак дым ярата.
Тик торган караулы тирәккә тимиләр.
Тирәк, ни юан булса да, пычкыдан котылмас.
Тирәкнең, тамыры черемичә, яфрагы саргаймый.
Тубылгы агач зур булмас, тубылгыдан өй булмас.

- Чатлы-ботлы — карама булыр, шарт-шорт янган — усак булыр.
Чикләвек агачы эчтән чери.
Чикләвек җыйганда җиләккә бармыйлар.

- Юкәнең чәчәге — бал, кабыгы — юкә, черегe — дару, агачы — сөян*.

- Ялгыз каенга кош кунмас.
Яшь каенга терәлеп, карт каен кырык ел яшәгән.

* * *

- Ватылмый торган чикләвек.

- Ике тирәк бер төптә, ике төймә бер җептә.
- Карама көленә утырту.
  Кеше чикләвек җыярга барганда, ул җиләк җыярга бара.
  Кәкре каенга терәтү.
- Тузга язмаганны сөйли.
- Чикләвегемнең төше юк, сезнең кебек кеше юк.
- Юкә агачка атландыру.
  Юкәдә икән чикләвек.

**Җиләк-җимеш агачлары**

- Агач, җимеше күп булган саен, ныграк иелер.
  Агачны кем утыртса, җимеш шуныкы.
  Агачта җимеш арткан саен, ботагы күтәрелми.
  Агачы кыек булса да, алмасы тәмле була.
  Аланда үскән балан әче була.
  Алма агачыннан ерак төшми.
  Алма ничек пешкән — эргәсенә шулай коелып төшкән.
  Алма теләсәң, агачыннан күз алма.
  Алмалары булмаса, алмагач гаепле түгел.
  Алманы үстерү кыен, черетү ансат.
  Алманың асылын аю ашый, чикләвекнең төшен корт ашый.
  Алманың кызылына алданма.
  Алмасын ашарсың — агачын кисмә.
  Аяз елны алма күп, явым елны гөмбә күп.
- Балан бал белән тәмле, бал балансыз да тәмле.
  Бер агач ике төрле җимеш бирмәс.
  Бер черек алма бөтен йөкне черетә.
  Буласы җимеш чәчәгеннән билгеле.
- Җиләк бердән җыйнала.
  Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген өзмә.
  Җимешен аша, бакчасын сорама.
  Җимешле агач зур булмый.
  Җимешнең асылын эт ашый.
  Җимешсез агачка таш атмыйлар.
- Кызыл алманың эче кортлы булучан.
  Кулың җиткән ботакның алмасын өз.
- Миләш дигән җимеш авыздан — су, күздән яшь китерер, имеш.
- Өлгергән өрек сабагында тормый.
- Сау алма саптан төшми.
  Сусыз агачта сусыл җимеш пешмәс.
- Тиз пешкән җимеш тиз чери.
- Һәр җимешнең үз корты бар.
- Чәчәк күрсәтмәгән агачтан җимеш көтелмәс.
- Шомырт чәчәк аткан вакытта кызлар җилкенә, балан чәчәк аткан вакытта балык сикерә.
- Яфракка карап, алма санама.

* * *

- Алма пеш, авызыма төш.
  Алмалары суга туенган.
  Аңа бит алма — шалкан, ком — талкан.
- Кеше бакчасына таш ату.
  Кипкән җимеш күк куырылган.
- Миләш диеп капкан идем, балан булып чыкты бу.

- Пешмәгән җимештән катмаган как.
- Яңа җимеш, иске авыз.

### Урман

- Бер агачтан унау үскән, ун агачтан урман үскән.
- Кәкре агачсыз урман булмас.
- Урман авызы тар булыр.
  Урман артындагы күренә, борын астындагы күренми.
  Урман бүресез, тау куянсыз булмас.
  Урман — колак, кыр — күз.
  Урманга кер, ботакка кадалма.
  Урманга кергәнче чыгар юлыңны кара.
  Урманга утын ташылмый, коега су салынмый.
  Урманда агач күп, сайлый башласаң яраклысы юк.

* * *

- Берсе урманга, берсе тугайга киткән.
- Урман чытырман, качсам тоттырмам.
  Урманда урынсыз, кырда койрыксыз.
  Урманы үсмәгән, агачы кисмәгән.

### Урман эше, агач эшкәртү

- Агач киссәң озын кис, чаба-килә кыскарыр.
  Агач корыса, утын булыр.
  Агачны ега белмәгән үз өстенә аударыр.
  Агачны кинәт бөксәң шарт сынар.
- Балта агачны кисмәс иде, агач сабы булмаса.
  Балта да чапкан төштән генә кисми.
  Балта остасының юньле балтасы булмас, чабата ясаучының юньле чабатасы булмас.
  Балта остасының үз йорты тирәсе һаман җимерек.
  Балта сораганга көрәк тоттырмыйлар.
  Балта чапкан чакта йомычка чәчрәми булмас.
  Балта чапканчы искә* ял итә.
  Балтасы суга төшкән сабын да атар.
  Балтасыз урманга барма.
  Ботагыннан чөй ясап, агачын яралар.
- Егылган агачка балта чабучы күп булыр.
- Имән җиде ел суда ятса, таш булыр.
- Кабык зур булса да, бәһасе бер тиен.
  Кайрысында кипкән агач чатнамый.
  Кеше өстендә бүрәнә дә җиңел, үз өстеңдә кура да авыр.
  Кәкре агачны төзәйтүдән төзен кәкрәйтү җиңелрәк.
  Күп тукмасаң, ботаклы утын да ярыла.
- Өйне эшләгән балта тышта кала.
- Пычкы сораганга — ышкы, ышкы сораганга пычкы тоттырмыйлар.
- Сапсыз балта агач чабарга ярамас.
  Сыймас җиргә чөй какма.
- Такта тар булыр, бәясе бар булыр; кабык киң булыр, бәясе ким булыр.
  Таяк бирә тай көче.
  Таяк ике башлы.
  Тимер балта булдыра алмаганны кайчакта юкә чөй булдыра.
  Тугыз балта бер сәкедә ятар, ике каба ятмас.
  Төз агачтан ук чыгар, кәкредән — җәя.
- Урманга кергән саен утын күбәя.
- Үткен балта тиз кителә.

Үтмәс балта сөяк чабарга ярый.

 Чыбык вакытында бөкмәсәң, зурайгач бөгә алмассың.
Чөе кайда, тукмагы шунда.
Чөйне чөй белән чыгаралар.

 Шырпылы агач кулга кас*.

 Юан булса да, ялгыз агачтан өй булмый.

 Яраклы түмәр җирдә ятмас.

* * *

 Аркылы яткан агачны буйга алып салмый.

 Балта биреп, шөшле алдым.
Балтасы суга төшкән.
Барысы да бер чыбыктан сөрелгән.
Бере тукмак, бере чөй, берен ал да берен төй.
Бутау мунчаласы ясау.

 Йомычканы йомыш итеп йөри.

 Кабык сугып, чәүкә очыру.

 Тамырына балта чабу.
Тукмак тисә — тик торыр, чыбык тисә — сикерер.
Тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән.
Төп башына утырту.
Төптән куркып, түмгәккә абынган.

 Урманны үтеп, утын күрмәгән.

 Үзе утырган ботакны кисүче.
Үтмәс балта белән юнган.

 Чыбыктан чыбыркы булган.
Чөй өстенә тукмак.

### *Хайваннар*

### Аучылык, ерткычлар, киекләр

 Аучы белән балыкчы беркайчан да баемас.
Аучы козгын ауламас, үрдәк аулар.
Аучы ничә әмәл белсә, аю шунча юл белә.

 Болан куган аучы тауны күрми.

 Ерткыч тырнагыннан билгеле.
Ерткычына күрә капканы.

 Киеккә үлем сәгате җитсә, туп-туры аучыга чабар.

 Сунарчыга эз кирәк, эз таныргa күз кирәк.

 Тозакчы күренмәс, җимен күрсәтер.

 Уңмаган аучының эте кыек чабар.

 Читлеккә эләккәч, ерткыч та юашлана.

 Юньсез сунарчы арба белән куян тотар.

 Яхшы аучының мылтыгы тутыкмый.

* * *

 Корган капкан, үзе капкан.

 Сукыр аучы кыек атып туры тидергән төсле.

#### *Арыслан*

 Ана арыслан баласы өчен утка керер.
Арыслан айга менмәсә дә, сикерүе дан.
Арыслан ат өеренә баш булса, арыслан өере булыр, арыслан өеренә ат баш булса, ат өере булыр.

Арыслан баласы арыслан булыр.
Арыслан бауда торса да эт булмас, арыслан булыр.
Арыслан картайса, тычкан өнен күзәтер.
Арыслан көче төлкегә хас түгел, төлке хәйләкәрлеге арысланга төс түгел.
Арыслан күләгәсендә тиен туеныр.
Арыслан тешен күрсәтсә, көлә дип уйлама.
Арыслан юлбарыстан качмас.
Арыслан үлгәннән соң, азу тешен тычканнар кимерә, ди.
Арысланга атлансаң, камчың кылыч булсын.

- Бәйле арысланга куян да ташлана.

- Читлектә арыслан да ачуын баса.

- Эттән калганны арыслан җимәс*.

*Аю*

- Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
Ач аю уйнамас.
Аю белән бүре гомергә дус булмас.
Аю белән танышсаң, мылтыгыңны калдырма.
Аю бии, чегән акча ала.
Аю кыш буе йоклый, «йокым туйды» дими.
Аю урманны саклый, урман аюны саклый.
Аюдан курыккан бүрегә юлыккан.
Аюны да биергә өйрәтәләр.
Аюны үтермәс борын тиресен сатмыйлар.

- Балның тәмен аю да белә.
Бер өнгә ике аю сыймас.
Бии белмәгән аюга урам тар.
Көчсез аю тавышы белән куркытыр.

* * *

- Аю дисәң өне юк, бүре дисәң җоны юк.
Аю куып, куян тоткан.
Аю хезмәте күрсәтү*.

- Безнең әти — аючы, эшләмичә баючы.

*Болан*

- Боланга ияргән сачәккә аунар, дуңгызга ияргән балчыкка аунар.
Боланның — башы, филнең теше кыйммәт.
Боланның үз мөгезе үзенә авыр түгел.

- Үлгән боланның башы белән тере боланны куркытма.

*Бүре*

- Ач бүре арысланга ташланыр.

- Бала чагында бүре баласы да сөйкемле.
Бар бүре дә бертөсле улый.
Бер юлдан йөргән бүреләр берен-бере ашамый.
Бүре арыгын белгертмәс, эткә сыртын кабартыр.
Бүре ачка түзәр, коллыкка түзмәс.
Бүре баласын бүреккә салып асрасаң да иш булмас.
Бүре баласын тотарга өйрәтсә, сарык баласын качарга өйрәтә.
Бүре бер күзе белән йоклый.
Бүре бәйләүгә күнмәс, дуңгыз әйдәүгә күнмәс.
Бүре дә тук булсын, куй да бөтен булсын.
Бүре екса — эт тә туя, кош та туя, ә козгыннныкы агач башында.
Бүре йонын алыштырыр, бүрелеген алыштырмас.

Бүре караңгыны ярата.
Бүре санаулы сарыкны да ашый.
Бүре, сарык туны кисә дә, бүре булыр.
Бүре: «Сарыкларны буш күтәр идем»,—дип сораган.
Бүре тиресе янында сарык тиресенең йоны коелыр, имеш.
Бүре утлагында ишәк җәйләмәс.
Бүре, ябагасын койса да, холкын үзгәртми.
Бүрегә кунакка барсаң, этеңне калдырма.
Бүредән курыккан көтү көтмәс, тычканнан курыккан иген икмәс.
Бүредән курыккан урманга бармас.
Бүрене телгә алсаң, каршыңа чыгар, ди.

- Карт бүре көрт ера.
  Котырган бүре утка керер.
  Көтүгә ияләшкән бүре бөтен көтүне буар.
- Сарыкның ничә сум торганын бүре каян белсен.
- Тамагы тук булса, бүре уламый.
- Эт булып кол булганчы, бүре бул да азат бул.

* * *

- Аның бүресе улый*.
- Бүрәнә аркылы бүре куган.
  Бүрәнә ярыгыннан бүре күрә.
- Корсакта бүреләр улау.
- Сарык тиресе ябынган бүре күк.
- Эчтә бүре асрау.

### *Керпе*

- Керпе баласын «йомры гынам, йомшак кынам» дип сөя, имеш.
  Керпе баласын «йомшагым» дияр, аю баласын «аппагым» дияр.
  Керпенеке шырпылы.
  Керпенең аягын күреп булмый.

### *Колан*

- Атның киеге — колан, кәҗәнең киеге — коралай*.
- Колан кайда симерә, төген шунда түгәр.
  Колан кодыкка егылса, кыр бакасы колагына чыга, имеш.
  Колан — кырда, кондыз — суда.
- Тауда туган коланның ике күзе ташта булыр.

### *Куян*

- Бер елга куян тиресе дә чыдаган.
  Биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян.
- Ике куян кусаң, берсен дә тотмассың.
- Койрыгыннан ныграк кыссаң, куян да шырпы кабызыр.
  Куян белән уйнама — чарчарсың*, ут белән уйнама — көярсең.
  Куян да баласын «Кушколак пәһлеван» дип йөртәдер, ди.
  Куян — күләгәсеннән дә куркыр.
  Куян тауга үпкәләгән, тауның исендә дә юк.
  Куян тиреләре базарда: «Исәнме, менә тагын күрештек»,— дип әйтерләр, ди.
  Куян тозакны онытса да, тозак куянны онытмый.
  Куян тотасың килсә, бурзай ал.
  Куян туны эт өрсә дә ертыла, имеш.
  Куянга күптән койрык әйткәннәр дә, әле дә юк.
  Куянны этсез куып булмый.
  Куянның өе — урманда, мәченең өе — өйдә.

- Төлке белгән хәйләгә куян да оста, тик нишләсен: койрыгы кыска.
- Шашынган куян аучы өстенә менәр.
- Өркетмә куянны, арыслан итәрсең.

* * *

- Алырсың аннан, куянга койрык үссә.
  Атмаган куян, асмаган казан.
- Бу куянны атсам, тиресен тунап сатсам, бер тай алып кайтсам, килер көзгә ат булыр.
- Куян шулпасының шулпасы.
  Куянны тотканчы куырдык.
- Сөрелмәгән җир өстендә тумаган куян баласы.

*Төлке*

- Бар төлке дә үз койрыгын мактар.
  Бер төлке җиде бүрене җитәкли.
- Кабып йотар алдыннан төлке дә тавыкны мактый.
  Карт төлкене урманнан куып чыгара алмассың.
- Томанлы көн төлке узар, буранлы көн бүре узар.
  Төлке арысланны тәү күргәндә куркуыннан чак җаны чыкмаган, икенче күргәндә «Әссәламегаләйкем!» дигән, өченче күргәндә алдап киткән, ди.
  Төлке бүредән туграк тора.
  Төлке дә йөземгә буе җитмәгәч: «Пешмәгән әле»,— дип әйтте, ди.
  Төлке саклы бакчага керми.
  Төлке — тиресе белән, былбыл — өне белән кадерле.
  Төлке төндә йөрер, көндез йоклар.
  Төлке төшендә дә тавык саный.
  Төлкегә баш булганчы, арысланга койрык булу хәерлерәк.
  Төлкенең уены күп булса да, иң яхшысы — качу.
  Төлкенең хәйләкәрлеге кетәк тирәсеннән күп узмый.
- Хәйләкәр төлке койрыгыннан эләгә.

* * *

- Без үзебез төлкече, түлке адәм көлкесе.
- Кара төлке булу*.
- Син төлке булсаң, мин койрыгы.
- Төлкене көлкегә калдырырлык*.

*Башка җанварлар*

- Баш маймыл ни кыланса, калган маймыллар бар да шуны кыланыр, ди.
- Йомран койрыксыз булмый.
- Кабан кабанның карынын ярмас.
  Канат булмаса, тиен койрыгы белән оча.
  Каплан — песинең агасы.
- Маймыл ни хәтле шыксыз булса, шул хәтле күбрәк кыланыр.
- Сусар ауга киткән, тиресе кайткан.
  Сыртланнан ашалганчы, арысланнан ашал.
- Тигәнгә — тиен башы, тимәгәнгә — куян башы.
- Ярканат теләге белән төн йөрми.
  Ярканат төнне көтә, сандугач таңны көтә.
  Ярканатның көндез күрмәвенә кояш гаепле түгел.
- Әрләннең әрен кузгатма.
- Өерле суер өн казымас.
- Җофарны яшерсәң дә исеннән беленер.

* * *

- Йомран, тишегенә су салгач, чыккан шикелле.
- Тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка.
- Җордай* юртак, еландай елдам булу.

**Йорт хайваннары, терлекчелек**

- Алдан чыккан колактан соң чыккан мөгез узар.
  Асылы кара тирене юган белән ак булмас.
  Ашаган малда өмет бар.
- Баш кая — койрык анда.
  Бер кылдан аркан ишеп булмый.
  Береккән көтү бүредән курыкмый.
- Дүрт аяклы хайван да сөртенә.
- Итче ак сарыкны да суя, кара сарыкны да суя.
- Йонны ятышына таба сыпырган яхшы.
- Кассапчыга* мал кайгы, карт ишәккә җан кайгы.
  Качаган* мал кашкырга* җим.
  Койрык булганчы баш бул.
  Кылыгын белмәгән малга якын барма.
  Көтү ташлаган малны бүре алыр.
  Көтүче белән бүре бервакытта да килешә алмый.
  Көтүче ялкау булса, көтүне тәкә көтәр.
- Мал да ашаган җиренә кайта.
  Мал казасы эткә яхшы.
  Мал — колыннан, акча — тиеннән.
  Малның җаен баккан белер, утынның җаен яккан белер.
  Малсыз кеше — җансыз кеше.
  Малчы мал карар, балчы бал карар.
  Малың булса, көтүче табыла.
  Малың мал булсын дисәң, азыгың мул булсын.
- Начар токымнан яхшы нәсел көтмә.
- Орып мөгез чыкмый, торып мөгез чыга.
- Тамгалы мал югалмас.
  Тәкә симергәнче итче күз салмас.
  Төс бирмәгән малны асрама.
- Үләр мал кое тирәсендә йөри.
- Хайван мөгезеннән таба.
  Хаҗтарханда* мал бер акча, килә-килә мең акча.
- Шәп мал аякланып туа.

* * *

- Араларына кыл да сыймый.
  Аяк урынына тояк.
- Башы-тоягы бер тиен.
- Ике койрыклы булу.
- Йонны тискәре якка сыйпау.
- Калган көтү калган инде.
  Койрыгы бозга каткан.
  Койрыкны бот арасына кыстыру.
  Койрыкны сыртка салу.
  Кыл өстендә калу.
  Кылны кырыкка яру.

Кырык ел көтү көтеп, чыбыркы шартлата белмәгән.

Мөгезен саклыйм дип, колагыннан язган.

*Ат*

Авыр йөкне ат тартыр.
Азыклы ат арымас.
Аксак булса да — үз атың.
Алама атка менгәнче, йөгер кеше күргәнче.
Арканлы ат казыгына уралыр.
Арыган атка йөгән дә йөк.
Арык атка камчы авыр, көр атка таш та җиңел.
Ат азгыны тайга иярер.
Ат алмас борын йөгән эзләмә.
Ат алсаң, сынап ал, акча алсаң, санап ал.
Ат арымаса, камыт арымас.
Ат аунаган җирдә төк калмый булмас.
Ат ачуын — тәртәдән.
Ат аяган ат менәр, тун аяган тун кияр.
Ат аягын дагалатканда бака да ботын сузган.
Ат башы белән уйнаганчы, атаң башы белән уйна.
Ат белән тибешкән тайның аягы сынар.
Ат бер юлга күнеп алса, йоклаган килеш тә йөри.
Ат бүләккә чабар, эт сөяккә чабар.
Ат дүрт аяклы, алай да абына.
Ат егылса көлмиләр, дөя егылса көләләр.
Ат иясенә килгәч аксамасын.
Ат камытка муенын үзе сузар.
Ат кемнеке — менгәннеке, тун кемнеке — кигәннеке.
Ат куркытырга тибә, тай үтерергә тибә.
Ат күрмәгән ат күрсә, абзарда атланып йөрер.
Ат тапсаң, ияр табыла.
Ат тарталмаганга арба гаепле булмый.
Ат тартмый, азык тарта.
Ат типмәс димә, эт капмас димә.
Ат урлангач абзар ныгытмыйлар.
Ат чаманына* менгәнче ике табаныңа ялын.
Ат эшләр — тирен чыгарыр, эт ятыр — телен чыгарыр.
Ат югалтсаң, йөгәнең ташла.
Ат яхшы булса, чыбыркы кирәкмәс.
Ат яхшы түгел, җим яхшы, җим өстенә дим яхшы.
Ат әйләнеп казыгын табар, су әйләнеп ярыгын табар.
Ат үлеме — эткә бәйрәм.
Атка атланган — атасын белмәс.
Атка мендем — атакка* мендем.
Атка менсәң — ат яхшы, җиргә төшсәң — җир яхшы.
Атка сукканда камчы авыртмый.
Атка ышанма, Иделгә таянма.
Атлының аягы да армый, туны да тузмый.
Атны йөгәненнән башка сатмыйлар.
Атны камытка үлчәп алмыйлар, камытны атка үлчәп алалар.
Атны ярга батканда кыйнамыйлар.
Атның аламасы кеше тибеп үтерә.
Атның даны егет кулында.
Атның кечкенәсен макта, зурысын җик.
Атның күрке ял булыр.
Атның, тамагы туйса, тоягы тузмый.
Атсыз ир — канатсыз кош.
Атта да гаеп, тәртәдә дә гаеп.
Аттан ала да туар, кола да туар.

Аттан ат тумыйча, эттән аргамак тумас.
Аттан егылганга дөя кирәк.
Аты барның канаты бар, сыеры барның сые бар.
Аты булса, йөгәне табылыр.
Аты симезнең юлы тигез.
Аты юк арба ярашкан.
Атым яхшы дип, чыбыркыңны куйма.
Атын урлаткач, сараен бикләүдә файда юк.
Атына көче җитмәгән тәртәсен кыйнар.
Атың симез булса, аягы сигез була.
Атыңны урласалар, йөгәнен чыгарып ташла.

Барасы килмәгән ат тәртәгә тибә.
Барган атның башына сукмыйлар.
Белгән атка бер камчы, белмәгән атка мең камчы.
Белмәгән атның сыртыннан әйлән.
Бер абынган өчен ат муенын өзмиләр.
Бер ат аркасында мең ат су эчкән.
Бер атка ике камыт кигезмиләр.
Бәләкәй атка арба юлы тар күренер.
Бүләк атның тешенә карамыйлар.

Дүрт аяклы ат та сөртенә.

Җәяү йөрмичә, ат кадерен белмәссең.
Җиккән атың җилдәй булсын.

Ике ат бер казыкка бәйләнмәс.
Ир канаты ат булыр.

Йөгәнсез ат үз иркендә.
Йөремсәк атны кешәнлиләр.

Кайнар ат тиз аручан була.
Кайтыр юлга чыккач ат та елдамлана.
Карт ат буразнаны бозмый.
Кеше аты тирчән, кеше киеме керчән.
Кеше атына менгән тиз төшәр.
Колагын яткырган аттан саклан.
Корчаңгы ат ияр салдырмас.
Күмәк ат арасында бер атның аксаганы беленмәс.
Күндәм ат күп җигелә.

Начар атка кыңгырау такмыйлар.

Олы атның тире чыкканчы, кече атның җаны чыга.

Саламда торган ат саламга барырга гына ярый.
Серен белмәгән атның авызлыгын салдырма.

Тарткан атка йөкне күбрәк төйиләр.
Тешләшкән атның артыннан үт, тибешкән атның алдын- нан үт.
Тәртә арасына кергәч, чыгымчы ат та юашлана.

Чыгымчы ат белән камчы телендә сөйләшү яхшырак.
Чыгымчы ат үрдә туктый.

Юаш атның тибүе каты булыр.

Ялгыз атның тузаны чыкмый.
Ялына тотынып кала алмасаң, койрыгына тотынып кала алмассың.
Яман атны яхшы баксаң, толпар булыр.
Яхшы ат ирнең данын тарата.
Яхшы ат та бер сөрлегә.
Яхшы ат тәртә арасында үлә.
Яхшы ат үзенә камчы тидермәс.
Яхшы атка бер камчы, яман атка мең камчы.
Яхшы атка дилбегә кагу да җитә.
Яхшы атка кыңгырау тагучы күп була.

* * *

- Агач атка атландыру.
  Алар ат булганчы, үзең эт булырсың әле.
  Асау* ат кебек йөрисең.
  Ат ачуын тәртәдән алу.
  Ат белән чыпчык куу.
  Ат чапканга бот чапкан.
  Ат юк, арба юк, аннан калган бар да юк.
  Ат янында бозау эзләгән.
  Атлылар аттан төшеп, җәяүлеләр ятып карарлык түгел.
  Аттан төшсә дә, өзәңгедән төшми.
  Аттан иңеп, җәяүгә калу.
  Аты бармагач, тәртәсен кыйный.
  Атына түгел, чанасына кыңгырау таккан.
- Без дә кеше булырбыз: атка кешән салырбыз.
- Йөз кешегә — йөз ат, ялгызыма — бер ат.

*Айгыр*

- Азнаган* айгырны өердә сына.
  Айгыр өерен ташламас.
  Айгырың ала булса, колының кола булыр.
  Айгырың үлмәс борын амбарыңны бикләә.
- Бөләсең килсә, айгыр асра.
- Җигә белгән айгыр җигәр.
- Ике айгырны бер сарайга япмыйлар.
- Тәртәдән ашкан айгыр яман.

*Алаша*

- Алаша кибәннән өрекмәс.
  Алга киткәндә алаша да тайлый.
  Ашарга карт алаша, тартырга — тай.
- Карт алашаны камыт сукмый.

*Аргамак һәм башка чабышкы атлар*

- Аргамак алын бирмәс.
  Аргамак ат юл башлар.
  Аргамак егылса, алдына егылыр.
  Аргамакның билгесе — эчен эчкә тартканы.
  Аргамактан ат туса, ал аягы ак булыр.
  Ат та йөгерек булсын, җир дә тигез булсын.
  Ат юргалар иясе дан алыр.
  Атның солтаны—юрга.
- Җаена сыпырсаң — юрга булыр, кирегә сыпырсаң — чыгымчы булыр.
- Җилдерми йөгерек басылмый.
- Йөгерек атка камчы кирәкми.
  Йөздән юрга чыгар, меңнән толпар* чыгар.
- Камчылатып чапкан атның йөгереккә саны юк.
- Солы ашамас аргамак яфракка моң булыр.
- Толпарга тиң ат булмас.
  Толпарның утлавы бер булса да, атлавы башка.
  Толпар, аягы кызса, канатланып очар.
- Чабыш аты чапмый түзә алмый.
  Чабышка чыккан аргамакның аягын тышауламыйлар.

Чабышкыга чабышкы янында чыбыркы кирәкми.

- Юрганың кадере җилгәндә беленер.
  Юртак атның тоягы ике.

*Бия*

- Байтал бия булганчы, башыңа чал иңә.
  Байтал чабып бәйге алмас.
  Байтал яманы ике айгырны тибештерер.
  Бия каян юртса, колын да шунда.
  Бия эштә тирли, колын бушка тирли.
  Биясенең серен иясе белер.
  Биясенә атлансаң, тае ияреп кайтыр.
- Карт бияне төпкә җигәләр, яшь бияне кырга җигәләр.
  Колынлы биядән кое суы артмас.
- Тайлы биядән күл курка.
  Тумаган тайдан кысрак* бия артык.
- Чиләктән җирәнгән бия ач калыр.

*Колын*

- Авызы йомшак колын биш бияне имәр.
  Алтмыш колын ат булмас.
  Анасы типкән колынның тәне авыртмас.
- Булыр колын бәендә уйнар.
- Колын асрасаң, ат менәрсең.
  Колыннан елкы булыр.
  Колынның яхшысы атка иярер.

*Тай*

- Ат басканны тай да басар.
- Бер тай әйткән: «Тагын да ныграк чабар идем, җир җимерелер дип куркам!» — дигән.
- Тай алсаң, биясенә кара.
  Тай артыннан йөргән — тайлыккан.
  Тай атка җиткерер, ат моратка җиткерер.
  Тай бияне тыңламаса, бүре ертыр.
  Тай типсә, аттан яман.
  Тайның яхшысы атка иярер, атның начары тайга иярер.
  Тумаган тайга атланма, билен сындырырсың.
  Тумаган тайга — тимер ыңгырчак.
- Яшь тай тибүчән була.

* * *

- Башыма тай типмәгән.
- Кешенең аты узганда, аның тае узган.
- Тай биреп котырткан, ат биреп туктата алмаган.
  Тумаган тайга йөгән ясау.

*Дуңгыз*

- Байыйсың килсә — дуңгыз асра, бөләсең килсә — айгыр асра.
- Дуңгыз ай белән көнне аермас.
  Дуңгыз башын табакка салсаң, тәгәрәп төшәр.
  Дуңгыз борынын чөйгән белән күкне чөймәс.
  Дуңгыз да дуңгызны яратмый.

Дуңгыз кылыннан киез итек басып булмый.
Дуңгыз муенына энҗе такмыйлар.
Дуңгыз мөгезле булса, һәркемне сөзәр иде.
Дуңгыз тукмактан туймас.
Дуңгызга ай тотылды ни, көн тотылды ни.
Дуңгызга дага какмыйлар.
Дуңгыздан кыл йолка белү дә һөнәр.
Дуңгызны кондыз итәр хәл юк.
Дуңгызның ите харам булса да, акчасы хәләл.

- Заманасына күрә дуңгызны кондыз диярсең.

- Ил аулак булса, дуңгыз түбәгә чыгар.

- Чучканы алтын белән дагаласаң да, ат булмас.

* * *

- Алла булып башлады, дуңгыз булып очлады.
  Аның дуңгызы да боламык ашый.

- Битенә дуңгыз тиресе каплаган.

- Дуңгызны җизни дип әйтмәгән.

*Дөя*

- Бер дөядә ике өркәч, бере шиңсә, беренең көче юк.
  Берәүдән дөя, берәүдән дога.

- Дөя авыр йөк ташый, үзе чәнечке ашый.
  Дөя ике мөгез сорады, ике колактан коры калды.
  Дөя Кәгъбәгә бару белән хаҗи булмас.
  Дөя күп булса, йөк сыймый.
  Дөя үз бөкресен күрмәс.
  Дөяне кесәгә яшереп куеп булмый.
  Дөясе булганның капка башы биек булыр.

- Йөк авырын нар* күтәрер.

- Соңгы дөянең йөге авыр.

- Тәвәгә* менеп чокырга качма.
  Тәвәче белән күрше булсаң, капкаң биек булсын.

- Дөя акрын китсә дә, күп юл алыр.
  Дөя качып йөктән котылмас.
  Дөя төягәннән курыкмас.
  Дөя хуҗасына үчексә, өстенә косар.
  Дөянең койрыгы җиргә җиткәнен кем күргән?
  Дөянең үзе нинди булса, йөге дә шундый.

- Чүккән дөягә суккан юк.

* * *

- Энә күзеннән дөя күрү.
  Энәдән дөя ясау.

*Ишәк*

- Алла, ишәкнең кем икәнен белгәнгә, мөгез бирмәгән.
  Ат абынса да, ишәк гаепле.
  Ат булмаганда ишәк тә ярый.

- Иртәге өчен ишәк кайгырыр.
  Ишәк алга тарта, койрыгы артка тарта.
  Ишәк, атлас кисә дә, һаман ишәк булыр.
  Ишәк, ашсыз калса да, эшсез калмас.
  Ишәк бакырганда сандугач сайрамас.

Ишәк йөккә килмәсә, йөкне ишәккә илт.
Ишәк колагы белән мактаныр.
Ишәк мактанып толпар булмас, карга мактанып шоңкар булмас.
Ишәк түшәк кадерен белмәс.
Ишәк янына атны бәйләсәң, ишәклеге йогар.
Ишәккә алтын ияр салсаң да, һаман ишәк.
Ишәккә иснәргә мәтрүшкә биргәннәр — капкан да чәйнәгән.
Ишәккә: «Сине оҗмахка кертәбез»,— дигәннәр, ишәк: «Анда шайтан таягы бармы соң?» — дип сораган, ди.
Ишәкне кыйнап кына ат итеп булмый.
Ишәкнең иярен алыштырып кына холкын алыштырып булмый.
Ишәкнең үз бакыруы үзенә ямьле.
Ишәктән егылу аттан егылудан яманрак.

Уңган ишәк аттан йөгерек булыр.

* * *

Ишәк төчкергәндә туу.
Иштең ишәк чумарын.

Маңгаеңа ишәк типмәгән.

*Кәҗә*

Бер кортлы кәҗә бөтен читәнне җимергән.
Бер кәҗә ике күршене сугыштырыр.
Бүрегә сәлам бирү кәҗә эше түгел.

Йон уңаена сыпырсаң, кәҗә дә койрыгын селкетә.

Кемгә нәрсә, кәҗәгә кәбестә.
Корчаңгы кәҗә саф чишмәдән генә су эчәр.
Кәбестә бакчасына кәҗәне каравыл куймыйлар.
Кәҗә асраган каргыштан чыкмас.
Кәҗә: «Бакча буеннан үтмәсәм, тамагым туймый»,— дип әйтә, ди.
Кәҗә бар җирдә каза була, ди.
Кәҗә белән кәбестә дус түгел.
Кәҗә койрыгына кырмавык ябышмый булмый.
Кәҗә сауганнан сыер сауган сөт сорап килгән.
Кәҗә, тынычлыктан туйса, көтүченең чыбыркысын чәйни, имеш.
Кәҗә үзе затсыз булса да, күне затлы.
Кәҗәгә дигән таяк оҗмахтан чыккан.
Кәҗәдә чуан тормый.
Кәҗәне макта, сыерны сау.
Кәҗәнең ашамаган әреме башын авырттырыр, имеш.
Кәҗәнең бакчага бер күз салуы да зыян.
Кәҗәнең бер исеме кәҗә, икенчесе — каза.
Кәҗәнең туганда ук сакалы була.
Кәҗәнең әҗәле җитсә, көтүченең таягына ышкыныр.

Мөгезсез кәҗә үзен: «Мин — куй!» — дия икән.
Мүкләк кәҗә, мөгез сорыйм дип, колагыннан коры кал- ган, ди.

Сөтсез кәҗә бакравык.

Урлап ашамаса, кәҗәнең тамагы туймый.

* * *

Кактым-суктым кәҗәне, таптым үземә бәлане.
Кәҗә билеты бирү.
Кәҗәгә акчасы җитми, сыер сатулаша.
Кәҗәне кәбестә сакларга куя.

Муеныңнан кәҗә мае чыгарырмын.

*Сарык (куй)*

- Аксак сарык төштән соң бакыра.
  Аксак сарык ятып симерер.
  Арык булса да — сарык булсын, аз булса да — каз булсын.
- Бер куй аркасында мең куй су эчә.
  Бер куйдан ак та туа, кара да.
- Ике куйның башы бер казанга сыймас.
- Кара куйдан ак туган, башын әллә кая куйган.
  Куй «кыркырга бәйлиләр» дип әйтә икән, кәҗә «суярга бәйлиләр» дип әйтә икән.
  Куй үз бәрәненең аягына басмас.
  Куйны бүрегә ышанмыйлар.
  Кысыр сарык күп бакырыр.
  Көтү борылганда аксак сарык алга чыга.
  Көтүдән аерылган куйны бүре ашый.
- Сарык булмасаң, бүре дә ашый алмас.
  Сарыкка эт тиресе кидерсәң дә, бүредән куркыр.
  Сарыкның егылганы да күренми, дөянең сөртенгәне дә күренә.
  Сарыкның карыны туяр, күзе туймас.
- Үзең сарык булгач, көтүчең Сарбай булганга үпкәләмә.
  Үлгән сарыкка бүре куркынычы юк.
- Югалган куйның койрыгы зур булыр.
- Ялгыз бәрән бакравык була.

* * *

- Бары — бар, югы — юк: сарык исән, бүре тук.
- Сарык биреп сөйләтә алмыйм, сыер биреп туктата алмыйм.
  Сарык янында батыр, батыр янында сарык.

### *Тәкә*

- Башбаштак тәкәгә болын тар.
- Ике тәкә башы бер казанга, мөгезе булмаса, сыя.
- Кәҗә тәкәсе түрә булырга яратыр.
- Сөзешкәндә мөгезсез тәкә җиңелер.
- Тау башындагы тәкәгә тау астындагы арыслан сәлам бирер.
  Тәкә асраган шулпа эчәр.
  Тәкә ите им булыр, кәҗә ите җил булыр.
  Тәкә сөзеп тау түнтәрмәс.
  Тәкәнең, тауга менмәсә, тоягы кычый, ди.

* * *

- Ул гына Алланың кашка тәкәсе*.
- Син генә кашка тәкә, мин генә аксак бәбкә түгел.

### *Сыер*

- Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер.
  Ашаган җиренә сыер да кайта.
- Әстерханда сыер бер акча, кил-килә мең акча.
- Бер былчырак сыер бөтен көтүне былчырата.
  Берәү мөгез тота, икенчеләр сыер сава.
  Бозавы үлгән сыерда сөт булмас.
- Инәге* булса, чиләге булыр.
  Ишек алдында сыерың булса, табыныңда маең булыр.
- Кара сыердан да ак бозау туган.
- Мөгрәп килгән сыерның мөгезен бәреп сындырма.

Мүкләк сыер сөзешкәк, аксак бия тибешкәк.

- Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра.

Сыер алсаң савып ал, сөтен-маен кабып ал.
Сыер ашаудан туймас.
Сыер басу таптаган өчен чөйдәге бозау тиресен кыйнамыйлар.
Сыер дуласа аттан яман.
Сыер көтүчесен белер, хуҗасын белмәс.
Сыер су эчәр — сөт булыр, елан су эчәр — агу булыр.
Сыер сыйпаганны белмәс.
Сыер үги бозау имезә.
Сыер җиленендә сөт ачымый.
Сыерга ияр килешмәс.
Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый.
Сыерлы кеше — сыйлы кеше.
Сыерлының төсе гөлдәй, сыерсызның төсе көлдәй.
Сыерны яхшы күрсәткән — артындагы танасы.
Сыерның сөте җиленендә түгел, тагарагында.
Сыеры барның сые бар.
Сөзә торган сыерга алла мөгез бирми.
Сөмсез сыер үз ыруын танымас.
Сөтле сыер базарга барып җитмичә кала.
Сөтсез сыер күбрәк мөгри.

- Үгез мөгезле сыерның сөте булмас.

Үзе китеп үзе кайткан сыер — солтан.
Үлгән сыер сөтле була, калган сыер бетле була.

- Яман сыер мөгрәп йортка бүре чакыра.

* * *

- Аягына сыер басмаган.
- Кысыр сыерны бозаулату.
- Сыер биреп кушсаң, ат биреп тә туктата алмассың.

Сыер колагына телефон сузма.
Сыерга ияр салу.
Сыерым юк киртәдә, кайгым юк иртәгә.

*Бозау*

- Бозавын сатып алганда сыеры турында сораш.

Бозау анасыннан алга узып йөрсә, бүре ашар.
Бозау үгез булганчы, иясе дуңгыз булыр.

- Имә белгән бозау ике сыерны имгән.
- Көтүдән калган бозау бүрегә азык.
- Мөгрәмәгән бозауга имчәк бирмиләр.
- Уртак үгездән ялгыз бозау артык.
- Өйдә үскән бозау яланда үгез булмас.
- Үгез аягы булганчы бозау башы булса изге.

* * *

- Ат яныннан бозау эзләгән.
- Бозау агачка арты белән менгәндә була.
- Җилгә җиленләп, бозга бозаулап.
- Ике бозауга кибәк аера алмый.

*Тана*

- Тана бозау тарлауда, үгез бозау үләндә.

Тана күзен сөзсә, үгез җебен өзә.
Тана сыер җиленләгәндә белми, бозаулаганда белә.
Таналының тамагы тук.
Тар җирдә тана башы, алачыкта бозау башы.

*Үгез*

- Бер үгезнең мөгезенә суксаң, мең үгезнең тоягы шакылдар.
Берәүгә үгезе кыйбат, берәүгә мөгезе кыйбат.
Булмаган үгезне көтеп бозаудан мәхрүм калма.
- Иртәгә дигән үгезнең мөгезе чыкмаган.
- Карт үгез абзар юлын караңгыда да белер.
Котырган үгезгә юл бир.
- Мүкләк үгезне дә үчектерергә ярамый.
- Чалмаган үгезгә казан асмыйлар.
- Үгез боендырыкка* муенын үзе бирер.
Үгез гомере буе сабан сөрә, ник сөргәнен белми.
Үгез туса — ит булыр, тана туса — сөт булыр.
Үгез үгезгә сылтый, үгез мөгезгә сылтый.
Үгез үлгән курада кутырлы кәҗә баш була.
Үгезне сөзәргә, балыкны йөзәргә өйрәтмиләр.

* * *

- Аларның үгезләре дә бозаулаган вакыт.
Аның үгезе дә сөт бирә.
- Кызыл үгез аны сөзгән.
- Лашман* үгезе күк акыра.
- Үгез савып сөт бир, арба ватып утын бир.
Үгез үлсә — ит, арба уалса — утын.
Үгезем юк урамда, кайгым юк буранда.
Үгезне мөгезеннән эләктерү.

*Фил*

- Дөядән биек фил бар.
- Зур фил дә кечкенә тычканнан курка.
- Фил бик масаймасын дип, алла тычканны яраткан, имеш.
Филнең башы — тере булса да, үле булса да — мең тәңкә.

*Мәче (Песи)*

- Ач песидән тычкан котылмас.
- Зыянчы песи күзен елтыратыр.
- Йоклап яткан мәче авызына тычкан үзе килеп керми.
- Карак мәче син таяк алганчы сизенеп качар.
- Май ашаган песи төгеннән билгеле.
Мыштым мәче майны күбрәк ашый.
Мәче асрамаган тычкан асрар.
Мәче битен юа — колак арты кап-кара.
Мәче иткә буе җитмәгәч, «сөрсегән» дияр, имеш.
Мәче тычкан оясына керә алмас.
Мәче тырнагында сандугач сайрамас.
Мәче урлар, эт түләр.
Мәче әйтә ди: «Хуҗасы сукыр булса иде, балалары күп булса иде»,— дип.
Мәче, үзе йокласа да, күсене күрә.
Мәчегә уен, тычканга кыен.

Мәчене түбәдән атсаң да, дүрт аягы өстенә төшәр.

- Песи сөт салып ала белмәсә дә, чүлмәкне аудара белә.
  Песинең тычкан сөзәсе юк: аңа мөгез ни эшкә?
- Сыйпаганны песи дә ярата.
- Тәүфыйклы песи дә каймак ашый.
- Хуҗасы янында булса, мәче дә эт баса.

* * *

- Аның мәчесе дә куян тота.
  Араларыннан кара мәче үткән.
- Каймак эчкән мәче кебек.
  Койрыгы пешкән мәче кебек порсалану.
- Суга төшкән песи кебек йөрү.
- Таба ялаган мәче шикелле карана.
  Табаны пешкән мәче төсле кая басарга белми.

*Тычкан, күсе*

- Акыллы тычкан ике тишек тишәр.
- Былтыр үлгән күсе, быел чыккан исе.
- Әҗәле җиткән тычкан мәче койрыгын тешләр.
- Икмәк әйләнәсенә тычкан да җыела.
- Койрыгына бассаң, тычкан да чыелдый.
- Сукыр тычканга карт песи дә арыслан булып күренә.
- Тегермәндә туган тычкан күк күкрәгәннән курыкмас.
  Тычкан да кышка азык әзерли.
  Тычкан каргышы мәчегә төшми.
  Тычкан таш тауны да тишә.
  Тычканга йон чыккан саен катырак чиный.
  Тычканга — үлем, мәчегә — көлке.
  Тычканнан курыккан иген икмәгән, бүредән курыккан көтү көтмәгән.
- Үз оясы алдында тычкан да арыслан.
- Һәрбер күсе үз койрыгын үзе сөйри.

* * *

- Песине җиңеп, тычканнан җиңелгән.
- Тычкан башы ярылырлык.
  Тычкан таяк белән йөргән чак*.

*Эт*

- Авыл эте ала булыр, бүре килсә берегер.
  Авыл эте, яман булса, бүре белән дус булыр.
  Авыл этсез булмас.
  Азган эт үз оясына килеп өрер.
  Ак эт бәласе кара эткә.
  Аксак эт төштән соң өрер.
  Акыллы эт юкка тешләми.
  Акылсыз эт көндез өрә.
  Анасына өргән эт бүре авызына төшәр.
  Арка ишле эт бүрене җиңәр.
  Астыртын эт өрми тешли.
  Ау этенең өргәне гаеп, йорт этенең өрмәгәне гаеп.
  Аш кадерен эт тә саклый.
- Бер курыккан эт өч көн өрер.
  Бер эт белеп өргән, дүртесе белми өргән.

Бер эт түрә булса, ун эт койрыгын күтәрер.
Буш кулны эт тә яламый.
Бәйләнгән этне котырту җиңел.
Бәхете кире киткәннең эте карак киткәч өрер.
Бүре катында үскән эт куй ашар.

Искәрмәс эт каты тешли.
Иясен сыйлаганның этенә сөяк сал.

Картайган эт юкка өрми.
Каты өргән эт тешләмәс.
Кече этнең картайганчы көчек исеме калыр.
Койрыгын кисеп эттән куян ясый алмассың.
Койрык болгаган этне сугарга кул бармый.
Котырган эт иясен тешләр.
Котырган эт үз койрыгын үзе чәйни.
Куркак эт капка астыннан өрер.
Куркак эт өреп җиңәр.
Куштан эт бүре киткәч өрә.
Күмәк эт арыслан үтерә.
Күрше эте күршегә өрми.

Мосафир этнең койрыгы кысык.

Өрә белмәгән эт авылга бүре китерә.
Өргән бер этнең авызына сугып булмый.
Өргән эт тешләми, астыртын эттән саклан.

Тегермән ташы яларга өйрәнгән эт шул гадәтен ташлый алмас.
Тере эт үлгән арысланнан яхшырак.
Тешләгән эткә йә таяк, йә сөяк кирәк.

Уртак малны эт җыймас.
Усал эт арттан килеп өрми кабар.
Утлы кисәү эләккән эт яшен яшьнәгән саен дерт итәр, ди.

Һәр эткә таш атсаң, ташның мыскалы мең алтын булыр иде.

Хуҗасы кай якка мыегын борса, эте шул якка койрыгын борыр.

Эт авызына кергән белен ертылмый чыкмас.
Эт авызына кергән сөяк май булып эри, ди.
Эт авызыннан беленне алып булмый.
Эт айга өрер, айның нуры китмәс.
Эт амбар саклый, мәче казан саклый.
Эт ашаганчы бүре ашасын.
Эт барында таяк булмый, таяк булганда эт туры килми.
Эт батырга өрер, куркакны тешләр.
Эт белән дус булсаң, янында таягың булсын.
Эт белән кода булсаң, сөяк белән кунак итәр.
Эт белән мәче дус булмас.
Эт булмаган җирдә төлке йөрер.
Эт буранлы көндә котырыр.
Эт, бүрегә әйләнсә, бүредән яман.
Эт догасы кабул булса, күктән сөяк явар иде.
Эт ирләр янында, мәче хатыннар янында.
Эт иярткән — иптәшле.
Эт йөгерегеп төлке сөйми.
Эт каргышы бүрегә җитмәс.
Эт кемгә өрә, мәче шуңарга мыраулый.
Эт корсагына сары май килешмәс.
Эт куркуыннан түмгәккә дә өрә.
Эт көче җиткәнен талый.
Эт күзе тәтен белмәс.
Эт, нихәтле алдан чапса да, өйгә хуҗасы артыннан керә.
Эт — оясында көчле.

Эт сабыйга тимәс.
Эт симез, ашарга ярамый.
Эт, симерсә, иясен кабар.
Эт талашыр-талашыр, иснәшер дә ярашыр.
Эт тә ашатканда койрык болгар.
Эт, түрә булса, сөяк җыярга приказ чыгарыр.
Эт — эткә, эт — койрыкка.
Эт этлеген итми калмас.
Эт югында куян да мактана.
Эт юк илдә песиләр өрә.
Эт яхшыга да өрә, яманга да өрә.
Эт өрер, бүре йөрер.
Эт өрмәсә, авызы кабара, ди.
Эт үлгәнгә бүре еламас.
Этенә әйтсәң, кунагына тия.
Эткә бал сый түгел, үләксә сый.
Эткә йомыш кушсаң, сөяк сөйрәп китерер.
Эткә сөяк белән атсаң шыңшымас.
Эткә эт булып өреп булмый.
Этне кыйнап, ишәк итә алмассың.
Этне түрә итсәң, бүре булыр.
Этне үзең талама, эттән талат.
Этнең баласы анасының эчендә өрә.
Этнең койрыгы да үзенә табан кәкре.
Этнең койрыгын киссәң дә, куй булмас.
Этнең тамагы кайда туйса, иле шунда.
Этнең — теше, дуңгызның тиресе чыдам.
Этнең, үләксә ашамаса, башы авырта.
Этнең үпкәсе озакка бармас.
Этсез авылда мулла таяксыз йөрер.
Этсез куян тотып булмый.
Эттән калган сөяктән җилек көтмә.

- Юаш эт өрми тешләр.
  Юаш эткә таяксыз якын барма.
  Юлында эт ятса, әйләнеп үт.

- Яман эт бүрегә өрер, песидән өркер.

* * *

- Авызыннан чыкканны эт җыймас.
  Артыннан котырган эт капса да пыжламый.

- Биредә Алабай, аргы якта ялагай.

- Ерактан каты өрә, якыннан койрыгын кыса.

- Капка астыннан кергән, түргә менеп өргән.

- Печән өстендәге эт кебек.

- Эт баш, сыер аяк.
  Эт белән мәче дуслыгы кебек.
  Эт булдым, койрык кына кирәк.
  Эт дисәң — койрыгы юк, сыер дисәң — мөгезе юк.
  Эт күк талаша, мәче күк ялаша.
  Эттән котылган куян кебек.
  Эттән әрсез, Алабайдан кадерсез.
  Эшләгәнемне эт ашый, аркамны бет ашый.

*Көчек*

- Бер тигәнәдән ике көчек ашамый.
  Бәләкәй көчек аюдан курыкмый.

- Кеше артыннан көчек кенә йөри.

Көче җиткәнгә көчек тә ябыша.
Көчек өрә, олы этне кыйныйлар.
Көчекнең аласы да, карасы да бер була.

- Олы эт алдында бала эт койрыгын кыса.
- Тимәгәнгә тиле көчек тә тими.
- Эт бар җирдә көчек бар.
  Эт ничек өрсә, көчек шулай өрә.
  Эте тик тора, көчеге өрә.

## ***Кошлар***

### **Кош аулау, кыргый кошлар**

- Асыл кош — аягыннан, сак балык — саңагыннан.
- Бала кош очар, кунар агачын тапмас.
  Бала кошның авызы зур булыр.
  Балалы коштан җим артмый.
  Бер канат белән очылмый.
- Канаты бәйле кош очмас.
  Кош кунмаган агач юк.
  Кош, оясында ни күрсә, очканда да шуны кыла.
  Кош сайравыннан билгеле.
  Кошларга иректә очу алтын читлектә торудан артыграк.
  Кошны кош белән аулыйлар.
  Кошның да туган оясы бар.
  Кулда асралган кош ерак очмас.
  Куркак кош оясын олы юл өстенә ясый.
  Көчсез кошның оясы бөркет янында булыр.
- Өметле кош күкәйдә дә җырлый.
- Талпынган кош очмый калмас.
- Һәр кош үз оясын үзе корыр.
  Һәр кош үз оясына карап оча.
  Һәр кошның үз тавышы үзенә хуш.
- Читлеккә өйрәнгән кош иректә башын югалтыр.

* * *

- Авыз белән кош аулап йөрү.
- Ике канат, бер койрык.
- Канат алырга бардык, койрыксыз кайттык.
  Канатсыз очып китмә.
- Тисә — кошка, тимәсә — бушка.
- Өстеннән кош та очырмау*.

### *Аккош*

- Аккош аягына су йокмас.
  Аккош очар күл күреп, былбыл очар гөл күреп.
  Аккош һәр күлгә төшмәс.

### *Байгыш*

- Байгыш та үз баласына лачын дип исем кушкан.
  Байгыш чыпчык аулар.
  Байгыштан байгыш туар.
  Башыңа кунса, байгыш та сәмруг* булыр.

*Бүдәнә*

- Бер ел бүдәнә симерә, бер ел тартай симерә.
  Бүдәнә симереп батман* булмас.
  Бүдәнәнең унике пот мае бар.

*Бытбылдык*

- Җәйгә чыкса, бытбылдык күкәй сала, тартайның көчәнеп арты тала.
- Һәр бытбылдык үз сазын мактый.

*Бөркет*

- Бөркет биектән курыкмас.
  Бөркет бәрән ауласа — өлгесе, тычкан ауласа — көлкесе.
  Бөркетнең канаты очканда ныгый.
  Бөркетнең оясы биек ташта булыр.

*Каракош*

- Каракош та кояштан ары күтәрелә алмый.
  Каракошка ук тигән, каерылып караса үз йоны*.
  Каракошның күзләре үткен булса да, тамыры черегән агачка оя ясый.

*Карга*

- Асыл буяуга төшкән белән карга каргалыктан чыкмас.
- Әҗәле җиткән карга бөркет белән уйный.
- Балалы каргадан чүп тә калмый.
- Идел каргасы Идел ибенә, Җаек каргасы Җаек җаена очар.
  Ике карга талашса, бер козгынга җим төшәр.
  Иртә торган карга ашап туя, соң торганы борынын кыра.
- Йөз каргага бер таш җитә.
- «Кар» дисәң каргага барып тия, «тор» дисәң — торнага.
  Кара карга гына картаймый.
  Карга баласына: «Бер чукы да, биш артыңа кара»,— дип әйтә, ди.
  Карга ит ашаса да кычкыра, тизәк ашаса да кычкыра.
  Карга, казга охшыйм дип, ботын каерган.
  Карга кар теләсә, яңгыр явар.
  Карга карганың күзен чыгармас.
  Карга каңгылдап каз булмас.
  Карга күзе төшкән орлык шытмас.
  Карга, ни хәтле канатын кыеп очса да, карчыга булмас.
  Карга, ни хәтле югары күтәрелмәсен, барыбер үләксәгә кунар.
  Карга, тутый кош йөрешен йөреп, үз йөрешен оныткан.
  Карга үзен кош санар.
  Карга үстерсәң, күзең чукыр.
  Каргадан карчыга тумас.
  Карганы бал белән сыйласаң да, тизәк чукымый туймас.
  Карганы читлеккә япмыйлар.
  Карганың «карык» дигәне үзенә ямь.
- Сандугач сайрый дип карга да кычкырган.
- Үзең карга булгач, кая барсаң да кара йомырка саласың.
- Чукыган карга ач булмас.

* * *

- Ала каргадай алдан олы кычкыру.
- Бер карга туярлык ите юк.

- Каз урынына карга.
  Карга мие эчкән.
  Карга җиргә төшмәс борын.
- Тавис каурыйлары таккан карга.
- Бер карлыгач килеп яз булмый, бер саескан килеп кыш булмый.

*Карлыгач*

- Карлыгач сандугачка иярә алмас.
  Карлыгачның койрыгы җәпле, еланның — теле.
  Карчыга очканда карлыгач узар, сайраганда сандугач узар.
  Карчыга авызыннан ит кире чыкмый.
  Карчыга күгәрчен белән дус түгел.
- Очарга ирек бирмәсәң, яхшы карчыга да берни тотмас.
- Бер чебеш алган карчыга икенчесенә янә кайтыр.
- Ике карчыга сугышкан, киекчегә йон файда.
- Чит илнең карчыгасын үз илеңнең каргасы талый.
- Үлгән карчыгадан тере саескан артык.

*Козгын*

- Козгын баласы анасыннан да узган.
  Козгын карганы «кара» дип хурлаган.
  Козгын яу башлар, яуга карга иярер.
- Үләксә исен козгын алдан сизәр.

*Көртлек*

- Көртлек, кар астына башын яшергән белән, артын күрмиләр дип уйлый.
  Көртлек әйткән ди: «Көрткә чумсам да, кышны чыгармын».
- Тозагың кормас борын көртлеген ашый башлама.
- Үз туенда көртлек тә бии.

Күгәрчен

- Күгәрчен булып туган кош карга булып үлми.
  Күгәрчен күгәрченне «гөлдер бу-у» дип мактаган.
  Күгәрченнең бодае һәркайда.
- Ут чыкса — күгәрчен су ташый, чыпчык чүп ташый, имеш.

* * *

- Күгәрчен сөте генә юк*.
- Пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп торалар.

*Күке*

- Иртә кычкырган күкенең башы авырта.
- Күке гыйшык тота, баласын карга карый.
  Күке кычкырмый җәйнең яме булмый.
  Күке күкәйне үзе салган, баласын каргага тапшырган.
  Күкегә оя кирәкми.

*Саескан*

- Саескан сайрау белән сандугач булмас.
  Саескан, туры очса да, кыек яшәр.
  Саескан тутый телен әләкләп сакау калган.
  Саескан, үзе бур булгач, оясының түбәсен каплаган.
  Саескан җиргә бер кунганда кырык сикерер.

Саесканның койрыгы үзеннән шәп.

- Туры очкан саескан төшеп урлап май эчкән.

* * *

- Абзарыннан саескан оча.
Арттан тере саескан очыру.

*Сандугач (былбыл)*

- Бака кычкыра башлагач, сандугач телдән калыр.
Бакчасыз йортка былбыл кунмас.
Былбылны алтын читлеккә япсаң да, үз тал-тирәген сагынып сайрар.
Былбылның өне татлы, тутыйның теле татлы.
- Оясыз сандугач сайрамый.
- Сандугач булсаң сайрый да бел.
Сандугач — читлектә, карга — иректә.
Сандугач шәп сайраган өчен читлеккә эләгә.
Сандугач юк елны карга дан тотар.
Сандугачны сайраргa өйрәтмиләр.
Сандугачны өйгә җибәрсәң, мәчеңне читлеккә яп.
- Өй артында куагың булса, сандугач кунагың булыр.

* * *

- Йокым — сандугач йокысы*.
- Сандугач күк сайрый.

*Тавис*

- Тавис — каурые белән матур.
Тавис киенер дә ясаныр, аккош коеныр да сыйпаныр.
Тавис кошы койрыгына бакса — кинәнгән, аягына бакса —җирәнгән, ди.
Тависның күлмәге ефәк булса да, аягы ыштыр булыр.

*Торна*

- Йөз чыпчык чырылдавыннан бер торнаның торылдап куюы артык.
- Торна да кыйбланы ташлап туган җиренә кайта.
Торна каурыен салган — аяклары да томшыгы калган.
Торнадан курыккан тары икмәс.
- Һавадагы торнаны тотам дип, кулыңдагы чыпчыкны җибәрмә.

* * *

- Торна тәпи алып килү*.
- Һавадагы торнага кулымны тотып тормага.
Һавадан торна санау.

*Тукран*

- Тукран башы авырткач «чукымам, чукымам» дисә дә, авыртуы беткәч «чукырмын, чукырмын» дип әйтә ди.
Тукран кич тәүбә итәр, иртән онытыр.
Тукранның балтасы борынында.
- Урманда тукран да солтан, ди.

*Тургай*

- Сарыкка сыенган тургай да сау кала.
- Тургай котырса бөркеткә чабар, эт котырса иясен кабар.
Тургай, яңгыр тисә, баласын яшерә, рашкы* тисә, үз башын яшерә.

* * *

- Таң алдындагы тургай кук тәкелдәдең.

*Тутый*

- Тутый аягын күреп хурланды, буен күреп сырланды.
  Тутый сөйли белсә, күркә тик тора белә.
  Тутый сөйләшергә өйрәнер, кеше була алмас.
  Тутыйны читлеккә теле кертә.

*Чыпчык*

- Аучы чыпчыкка тозак кормас.
- Ил өстендә чыпчык үлми.
  Иртәнге чыпчык тешен казыр, соңгы чыпчык күзен казыр.
- Карт чыпчыкны кибәккә алдый алмассың.
- Чыпчык дулап киртә җимерә алмас.
  Чыпчык, симерсә дә, батман килми.
  Чыпчык та тутый кош кызын сораган, ди.
  Чыпчык «чыбыгым» ди, карга «каеным» ди, имеш.
  Чыпчыкның да үзенә күрә моңы бар.

* * *

- Чыпчык биреп каз алмакчы була.
  Чыпчык пыр иткәндә, йөрәге шыр итә.
  Чыпчык чүпләп бетермәс.

*Шоңкар*

- Очкан кошның барысы да шоңкар түгел.
- Шоңкар юкта ябалак мәйдан тотар.
  Шоңкардан кош куркыр, тургайдан корт куркыр.

*Ябалак*

- Былтыр үлгән ябалак быел башын күтәргән.
- Үзе ябалак булса да, үзен лачын атаган.
- Чырайсыз ябалакны урман да куган, авыл да куган.
- Ябалак елый, урман йоклый.
  Ябалак күрмәгәнгә кояш гаепле түгел.
  Ябалакка көннән төн якты.
  Ябалакның планын куян белмәс.

* * *

- Ябалак кыйнаган нәрсә*.
  Ябалак шулпасы* чөмергән.
  Язгы ябалак, көнче күбәләк.

*Башка кошлар*

- Акчарлак килми яз булмый.
  Акчарлак суда булыр.
- Әтәлге* мактанса, «тычкан тоттым!» дияр.
  Әтәлгене куй, карчыганы чөй.
- Дөя кошы* башын комга тыгып кына аучыдан яшеренә алмый.
  Дөя кошын да арбага җигәләр.
- Каз килсә — яз килә.
  Каз китә дип карга киткән.
  Каз үзе чүлдә булса да, күзе күлдә булыр.

Карга теләген теләшкән тартай үзенә давыл китергән.
Кенәри үзе читлектә, күңеле иректә.

 Лачын кошка һава кадерле.

 Сиртмә койрык*: «Минем койрыгым сиксән пот»,— ди, имеш.
Сыерчык бала чыгарганчы гына сайрый.
Сыерчык, диңгез артына китсә дә, үзе туган ояга кайта.

 Тартар гомере «тар-тар» дип үтәр.
Тартарның теле башына җитәр.
Тәвә кошы, «оч» дисәң — «мин тәвә», «йөк тарт» дисәң, «мин — кош» ди икән.
Торымтайдан* очкыр кош булмас, тургай ташлап каз алмас.

 Үз урманында чупай* да купай*.
Үлгән лачыннан тере чыпчык артык.

 Һәрбер көелте* үз сазлыгын мактый.

 Шәүлегән су чыгарган, карга кинәнгән.

* * *

 Күгәрченнәр арасындагы чәүкәләр кебек.

 Тилгән мие ашаган.

 Һөдһөд* тоткан күк булган.

## Кошчылык, йорт кошлары

### *Каз*

 Аерылган каз тупланган каргага җим булыр.

 Балалы казга җим тимәс.

 Каз артыннан тавык Идел аша очмас.
Каз — каз белән, үрдәк үрдәк белән очар.
Каз какылдаудан туймас, үрдәк бакылдавын куймас.
Каз үрдәкне талый, үрдәк тавыкны талый.

 Оясын пычраткан каз басып торыр.

 Ялгыз казның тавышы чыкмый.

* * *

 Аңарда каз зиһене бар.

 Мактанма, каз,— һөнәрең аз.

### *Күркә*

 Кабарыну — күркә гадәте.
Кызыл күрсә, күркәнең гайрәте килер.
Күркә җилгә симерә.
Күрше авылның күркәсе — үз авылыңның үрдәге.

### *Тавык*

 Алмаган тавык, салмаган йомырка, чебешләрне сата башлама.
Аңгыра тавык көшел өстендә ач йоклый.

 Балалы тавык — гаугалы халык.
Берәүнең чебешен үтерсәң, тавык түләрсең.
Бүленгән тавыктан бүленмәгән күкәй артык.

 Йомырка салган тавык үзе кытаклый.
Йомыркадан җөй эзләмә.

 Кап-кара тавык та ап-ак йомырка сала.
Кеше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек.
Кешенең чебешен ашасаң, казыңны бирерсең.
Күкәй салмас тавык көн элгәре кытаклый.

Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә.

- Мая башы — бер күкәй.

- Соңга калган йомыркадан сукыр чебеш чыгар.
  Сукыр тавыкка бакра да бодай.

- Тавык белән ят, әтәч белән тор.
  Тавык берәр бөртек чүпләп тә тук тора.
  Тавык, йомыркасы артына җиткәч, урын эзли.
  Тавык «кикрикүк» дигән белән әтәч булмас.
  Тавык кытакламаса, күкәй саласын кем белә.
  Тавык очса — тамга* куна, лачын очса — тауга куна.
  Тавык төшенә тары керә, ашамаса тагы керә.
  Тавык чүпләнеп тамак асрый.
  Тавык үз кетәген мактый.
  Тавыкны күкәй өйрәтми.
  Тавыкның азганы әтәч булып кычкырыр.
  Тавыкның ерак сәфәре — ындыр.
  Таңдагы тавыктан бүгенге йомырка артык.

- Үләсе килгән чебеш кое кырыенда йөрер.

- Чебешне көз санныйлар.
  Чебиле тавык тилгәннән курка.

* * *

- Аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт саварсың.
  Аның тавыгы юргалый.

- Йомыркадан җөй тапкан, беләүдән тут тапкан.

- Кичә йомыркадан чыкты, бүген кабыгыннан җирәнә.
  Күкәй эчендәге сары кебек.

- Суга төшкән чебеш кебек.

- Тавык түгел, йолкып ашамаслар.
  Тавык чүпләп бетергесез.
  Тавыкка күз салып, сарыктан колак каккан.
  Тавыкны күкәй өйрәтә.

*Әтәч*

- Әтәч кычкырса, «хатыным күп, түшәгем юк!» дияр, имеш.
  Әтәч — үз чүплегендә патша.

- Булыр әтәч йомырка эчендә үк кычкырыр.

- Вакытсыз кычкырган әтәчне суеп ашыйлар.

- Карт әтәч кычкыручан була.

- Соң кычкырган әтәчнең тавышы ягымсыз.

- Тавык кытаклый дип, әтәч тә кытаклаган.
  Туйга да шул әтәч башын өзәләр, үлек ашына да.

* * *

- Аның әтәче дә кубыз уйный.
  Аның әтәче дә күкәй сала.
- Йомыркадан чыкканчы әтәч булган.
- Кызыл әтәч җибәрү.
- Әтәч белән сука сөрү.
  Әтәч булып җитмәгән, читәнгә менеп: «Кикрикүк!» — дигән.

*Үрдәк*

- Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чумар.

- Балалы үрдәк күлдән китмәс.
  Берәүнең үрдәген ашасаң, казыңның аягыннан тотып тор.

Бөтен дөньяны су алса, үрдәккә ни гамь бар.

 Йөзә белмәгән үрдәк суга кермәс.

 Симертергә ябылган үрдәк ашаудан туймый.

 Үрдәк, ашаганда, хуҗасының өй кыегына карап ала, ди: «Ашасам, өй кыегы да бар әле»,— дип.
Үрдәк баласы күкәйдә үк суны белә.
Үрдәк биргән — каз көтәр.
Үрдәк, ничаклы ыспайланса да, аккош була алмый.
Үрдәк: «Ризыгымның өйдәгесен тавык ашый, судагысын балык ашый»,— дип кайгырыр, имеш.
Үрдәк теләген теләшкән тавыкның оясын су басар.
Үрдәк, үзенә ышанмаса, әкәлә йотмый.

* * *

 Аларның үрдәге дә каз кебек.

 Үзем тук, үрдәгем ач.
Үрдәгенә каз кую.
Үрдәк биреп каз алган.

***Җир-су хайваннары, бөҗәк-коңгызлар***

**Балыклар, балык тоту**

 Агым су бал татыр, ак чабагы май татыр.
Ач балык җимне кармагы белән йотар.

 Балык ашаган — ит эстәмәс.
Балык ашыйсың килсә, судан курыкма.
Балык башыннан бозыла.
Балык кармакны кабам дип капмый, җим кабам дип каба.
Балык сөяксез булмый.
Балык тирәнгә омтыла, кошлар биеккә оча.
Балык тоталмаган суны яманлаган.
Балыкка — арык, тараканга — ярык.
Балыкка кармаксыз бармыйлар.
Балыкны йөзәргә өйрәтмиләр.
Балыкның батасы юк.
Балыкның сырты көнгә көймәс.
Балыкчы балыкчыны ерактан күрә.
Балыкчының кулы ак, малчының йөзе ак.
Балыкчының күзе кармакта.
Берәү судагы балыкка карап ярты икмәген ашаган.

 Вак балык көтүе белән йөри.

 Дәрьядагы балык сатылмас.

 Җәен койрыгы җигән йотлыкмас.

 Итәк чыланмый балык тотылмый.
Иң зур балык һәрвакыт тоткач китә.
Качкан балык зур була.
Коеда балык булмас.
Коры кармакка балык капмый.
Күлнең данын балык чыгарыр.

 Салган саен кармакка балык эләкми.
Су ташканда балык тәкәббер була.

 Ташбашның томшыгы ташта.
Тымызык күлдә табан ятыр.

 Һәркем үзенә җайны карый — җәен дә лайны карый.

 Чабак сикерсә — чуртан авызына.
Чабак өстән китәр, чуртан астан килер.
Чабакның үзеннән бигрәк чупырдавы кыйммәт.
Чуртан тотканчы чабак кояшка бер сикереп калыр.

Чуртанның, үзе үлсә дә, теше үлмәс.
Чыракчыны* чуртан күрмәс.

* * *

 Балык кебек симез.
Балык та түгел, ит тә түгел.
Болганчык суда балык тота.

 Комга ташлаган балык сымак.
Кипкән балыкка әйләнү.

 Ничә чәйнәсәң дә, бер балык башы.

 Чуртан кушуы буенча*.

**Бака, кысла, сөлек, кәлтә, еланнар**

 Агулы елан өчен агусыз тузбаш еланны үтерәләр.
Алла сакласын, бака чакмасын: бака чакса, имен тапмассың.
Аптыраган сөлек юкә агачын тешләр.
Арбавын белсәң, кара елан да карышмый.
Ат дагалаганда бака ботын кыстырган.
Ач сөлек ачы тешләр.

 Бака бакылдамый тормас.
Бака баткактан курыкмас.
Бака да: «Бакылдамый торсам, ярылам»,— дигән.
Бака да: «Комырыгым*, томырыгым* — оҗмах»,— дигән, ди.
Бака, елан бер күлдә, икесе дә бер телдә.
Бака күлгә төшсә, су артыр.
Бака, күпме өрелсә дә, үгез булалмый.
Бака теле белән елан теле бер.
Бака үз күлендә ирекле.
Башы авырткан елан юлга аркылы яткан.
Бер кысла бөтен күлне болгар.
Бүрәнә арасында елан була.

 Елан агуы еланга үтми.
Елан аягын күрсәтмәс.
Елан бар җирдә тычкан булмый, тычкан булган җирдә елан булмый.
Елан белән дус булсаң, агуланырсың.
Елан бугазына кергән кире чыкмас.
Елан җеп кебек булса да, бәйләүгә ярамый.
Елан булсын да чакмасын, эт булсын да капмасын!
Елан елып керер, чагып чыгар.
Елан кабыгы җитмеш төрле авыруга им.
Елан, кабыгын салса да, елан йөрәген үзенә калдыра.
Елан картайса, өстенә бака атланып йөрер.
Елан кәкре йөрсә дә, өненә төз керер.
Елан чаккан кеше киндерәдән куркыр.
Елан өере белән йөрер, өненә ялгыз керер.
Елан өчкә өзелсә дә, кәсәрткелек* хәле бар.
Елан үз кәкресен белмәс, дуңгыз үз бөкресен белмәс.
Елан үзе үлсә дә, агуы калыр.
Еланга ярдәм итсәң — кулың чагар.
Еланга яхшы булса, бакага начар.
Еланны аждаһага әйләнгәнче үтереп кал*.
Еланны кем үтерсә, шуңа савап.
Еланны коткарсаң, иң элек тешен суыр.
Еланны өненә кергәндә койрыгыннан тартып алырмын димә.
Еланны үтерергә дошманыңа куш.
Еланның агы да елан, карасы да елан.
Еланның баласы да елан.
Еланның башын киссәң, койрыгы селкенер.

Еланның башын өзмәсәң, койрыгын өзүдән файда юк.
Еланның койрыгы уйнар, башы белән чагар.
Еланның, симергән саен, күзе ялтырый.
Еланның тешен сындырсаң да, агуы кала.
Еланның тышы йомшак булса да, эче зәһәр.

- Йоклаган еланның койрыгына басма.

- Кара бака судан чыкмас, өсте-башы агармас.
Кара елан каны җитмеш төрле имгә ярый.
Кое бакасы диңгезне күрми.
Койрыгын кем кискәнне елан онытмас.
Күзең бакага төшсә, күл буеннан кайтмассың.
Күп йөргән еланның аягы күренер.

- Оясын актарсаң, агусыз елан да тешләр.

- Сиңа тимәгән елан үз юлы белән йөри бирсен.
Сөлек сау канны иммәс.
Сөлекнең телен асраган белер.

- Ташбака кая барса да, сарае үзе белән.
Ташбака куянны узган*.
Туңган елан эреткән кешесен чагар.

- Уйламаган җирдән елан чагар.
Ун кеше арасына төшкән елан сау калыр.
Урдалы елан белән уйнама.

- Үзеңне чакмаган елан мич башында кышласын.
Үлгән еланның башын калкытма.

- Һәр еланга таяк табылыр.

- Чаян ачыргаланса, үзен-үзе чагар.

- Эчеңнән елан туса, ал да биленә бу.

- Юлда яткан еланның гомере кыска.

* * *

- Анда елан мөгезе генә юктыр.

- Бака туе ясау.
Безне чаккан елан җир өстендә йөрмәсен.

- Елан аягын кискән.
Елан кабыгын салу*.

- Җир астында йөргән еланны да белә.

- Күлен танымаган күк бака.

- Синнән игелек күргәнче, еланның тәпиен күрерсең.

- Эчендә кара елан ята.

## Бал корты, умартачылык

- Ана корт гайрәтле булса, умарта куәтле булыр.
Анасыз корт бал җыймас, бал җыйса да, мул җыймас.
Анасыз корт балавыз сузалмый.
Анасыз корт ил булмас, ил булса да, җим булмас.

- Бал корты бал алыр чәчәген белә.
Бал корты чәчәк тирәсендә йөрер.
Бал кортының балы бар, балга хәтле назы бар*.
Балны башлап балчы авыз итә.
Бер корт анасын тоткан бөтен күчен тотар.

- Елан агу тапкан чәчкәдән бал корты бал табар.

- Зәхмәтсез бал җимәсләр.

- Ике ана корт бер умартага сыймый.

- Корт чакмыйча бал булмый.
  Кортның анасы кая кунса, күче шунда сарыр.
  Көчле умарта — гүләвеннән билгеле.
  Көчле корт бал ашый, көчмә коңгыз үләксә ашый.
- Умарта, кечкенә булса да, бал ташый; карга, зур булса да, тирес ташый.
- Читтә сарган корт иле кем тапса — шуныкы.
- Өй артында корты барның өй эчендә коты бар.

* * *

- Аерылып чыккан корт кебек*.
- Умарта оясы кебек шаулый.

### Чебен-черки, кырмыска. Башка бөҗәкләр һәм кортлар

- Ак кандала кызарганчы эчәр, кызыл кандала канганчы эчәр.
  Акрын-акрын алтмыш адым дип, бет алтмыш чакрым юл йөрер, ди.
  Алла һәлак итим дигән кырмыскасына канат үстерер.
  Ат басып үтәр, кырмыска торып басар.
  Ат кигәвене корт түгел, бал җыймый.
- Балак бете башка менсә, әтәч булып кычкырыр.
  Балга батып үлү чебенгә куркыныч түгел.
  Бер борча өчен юрган ярмыйлар.
  Беткә ачу итеп тунны утка якмыйлар.
  Беттән күреп, борчасы талый.
  Бик сикергән борчаны уып ташлыйлар.
  Бүгенге чикерткә кичәге чикерткәне чикылдарга өйрәткән.
  Бүре булышкач, черки дә атны җиңгән.
- Җыен кырмыска чаянны җиңәр.
- Кайда кутыр булса, кара чебен шунда кунар.
  Кандала да үз баласына: «Тәтием, син бик хуш исле»,— дигән, ди.
  Кандала кунак итен «каз ите» дип ашый, имеш.
  Кара чебен сау җиргә күзен салмас.
  Карышлавык* карышлап йөреп ашар.
  Катыра торган таракан оятсыз була.
  Копшангы*: «Хуш, сау булыгыз, мин Һиндстанга киттем»,— дип очкан икән дә, тик юлда ат тизәге күргәч, шунда кунып калган.
  Корт агачны эчтән ашый.
  Кыерсытсаң, кырмыска да тешли.
  Кырмыска кышлык йорт салыр, йортсыз бака катып үләр.
  Кырмыска мәйдан тотар, кем дә белмәс.
  Кырмыска оясына таяк төртмә.
  Кырмыска чикерткәне җиңәр.
  Кырмыскадан гыйбрәт ал — яздан кышны каршыла.
  Кырмыскалар зур түгел, күмәкләшкәч тау өя.
  Кырмысканың амбары буш булмый.
  Кырмысканың үзеннән ничә кат авыр чыбыкка көче җитә.
  Кыш күренгән чебеннең безелдәве дә тансык.
  Көзге чебен ачы тешләүчән була.
  Күбәләк тә яшеренер урын таба.
  Күмәк кырмыска дөяне үтерер.
- Сагызак*, күпме безелдәсә дә, бал җыймас.
  Сагызакның җиде еллыгы, чакса, кеше үтерә.
- Таракан дулап кына мич башын җимерә алмый.
  Тирес кондызының да чәчәккә менеп балдан авыз итәсе килә.
- Үз өендә кырмыска да — Сөләйман*.
  Үләсе күбәләк утның күзенә керер.
  Үрмәкүчкә дә чебен ауларга тозак кирәк.
- Ут чыгасы өйнең тараканы алдан күчә, имеш.

- Чебен дулап тәрәзә вата алмый.
  Чебен үләр җиренә җыела, ди.
  Чебенгә чукмар күтәрмә.
  Чебенне күп кусаң, борыныңа кунар.
  Чебеннең сукыры күзгә керер.
  Черки: «Көндез маем эри»,— дип, төнлә генә чыга, имеш.
  Черки черелдәп җиңәр.
  Черкинең талавыннан бигрәк безелдәве яман.
  Чикерткәдән курыккан иген икмәс.
- Шөпшәнең оясын туздырсаң, уртага алып талый.
- Яфрак корты, ясмыктай булса да, бакчаңны корытыр.
  Яңа өйнең кандаласы очлы була, ди.

* * *

- Ашка таракан төшү.
- Бет ачуын туннан алу.
  Бетен сыгып, канын эчә.
  Ботыннан тотып селексәң, бете юк.
- Күзен алган кигәвен кебек.
- Пәрәвез оясы кору.
  Пәрәвезгә эләккән чебендәй.
- Талпан булып кадалу.
  Таракан катырырлык суык.
  Таракан санап яту.
- Үрмәкчедән* күрмәкче.
- Чебен очканы ишетелерлек.
  Чебен тисә чер итәр, тукмак тисә тик торыр.
  Чебенгә күсәк күтәрү.
  Чебеннән фил ясау.

### *Кеше һәм аның тән төзелеше*

### Баш, маңгай, муен, чәч, сакал-мыек

- Акылсыз баш аякка тынычлык бирми.
  Акылсыз башка алтын бүрек файда бирмәс.
- Бармагың сыймаган җиргә башыңны тыкма.
  Баш белән таш ярып булмый.
  Баш булса — мал, аш булса казан табылыр.
  Баш китсә, аяк котылмас.
  Баш — чәчсез, урман кошсыз булмас.
  Баш ярылса — бүрек эчендә, кул сынса — җиң эчендә.
  Башта ми булмаса, ике кулга көч төшә.
  Баштан колак узмас.
  Башы булса, чәче үсәр.
  Башың буш булгач, кәшемир яулыктан ни файда.
  Бер башка караганда ике баш яхшырак.
- Иелгән башны кылыч кисмәс.
- Кара сакалың кая барсаң да калмас.
  Кеше башында чәч алырга өйрәнәләр.
  Күсәдән* көләр өчен үз сакалың яхшы булырга кирәк.
- Маңгае киңнән түңелмә*, иңсәсе киңгә үрелмә.
  Маңгай тире эшнең сыйфатын яхшырта.
  Мең алтын ташың булганчы бер акыллы башың булсын.
  Муен булса, камыт табыла.
  Мыек бөтереп кенә тамак туймый.
- Олы баш белән ярыктан үтәсе кыен.

 Сакал кешене түрә итмәс.
Сакал кисеп, мыек ялгап булмый.
Сакалга карама, акылга кара.

 Тел өчен баш җавап бирә.

 Үзеңнең чәчең ятның башыннан кадерлерәк.

 Чәч агару чир түгел.
Чәч кенә булсын, таравын төрлечә итеп була.

 Яңгыр яуганда бала башы җәл, боз яуганда үз башың җәл.

* * *

 Алар нигә мыеклы да, без нигә кыеклы.
Алла биргән баш, Хәтифә теккән бүрек.

 Баш күккә тию.
Баш ярылып, күз чыкмаган.
Башы керсә, аягы кермәгән.
Башына карасаң, бүрегең төшәрлек.
Беткән баш беткән, муен калса җиткән.

 Сакалы озын, акылы кыска.

 Түбәңнән керер, табаныңнан чыгар.

 Чәче белән җир себерә.
Чәчләр чәчкә бәйләнү.

**Күз, колак, күрү, ишетү**

 Баш күзеннән ни файда, күңел күзе күрмәсә.
Бер колагың йокласын, икенчесе тыңласын.
Бер күзгә төртсәң, икенче күздән яшь чыгар.

 Ике колак бер сүзне тыңлар өчен.

 Каш төзәтәм дип күз чыгарма.
Кеше колагын кискәндә үзеңнеке авыртмый.

Кеше күзендәге чүпне күргәнче борын астыңдагы бүрәнәне күр.
Колагың кисек булса, чәчең белән каплый бел.
Колагыңны кызганып, башыңны кистермә.
Күз берне күрсә, күңел меңне күрә.
Күз каравы сүздән күбрәк аңлата.
Күз куркак, кул батыр.
Күздән ерак булса, күңелдән ерак булыр.
Күзеңне йомма, авызыңны йом.
Күргәнең сигез, күрмәгәнең тугыз.
Күрер күзнең кыйммәте сукыр янында билгеле булыр.
Күрәсең килмәгәндә кибән дә күренми.

 Мең ишет, бер сөйлә.

 Сул күзең уң күзеңә каравыл булсын.

 Яман күздән таш чатный.

* * *

 Без күрмәгән аз булыр, Бохардагы таз булыр.
Бер колактан керде, икенче колактан чыкты.

 Ике күз дүрт булу.

 Кара күзлектән үткәрү.
Колагым киез, корсагым тигез.
Колак итен ашау.
Күз алмасы кебек саклап тору.
Күз чыгарып каш ясау.
Күзгә төтен җибәрү.
Күзгә төртсәң дә күренмәү.

- Минем колак: берсе — ишек, берсе — тишек.

### Борын, авыз, ирен, тешләр

- Авыз бер, колак ике: сөйлә бер, тыңла ике.
  Авызын ач, теше булса кач.
  Авызында теше беткәннең кулында көче беткән.
  Авызың белән чәчкәнне кулың белән җыеп ала бел.
  Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә.
  Авызың ни әйтсә, колагың шуны ишетер.
  Авызың тулы кара кан булса да, кеше алдында төкермә.
- Бер төкергән төкерекне кире йотып булмый.
  Борын булмаса, ике күз бер-берсен чукыр.
  Борын югары менгән саен баш түбән төшәр.
  Борыныңны күккә чөймә, чиләк элеп куярлар.
- Иләк авызга чиләк капла.
- Селкенгән теш төшми калмас.
- Теш — кала, тел — бәла.
  Тешең барда таш чәйнә, көчең барда көл чәйнә.
- Үз борын астын күрмәгән урман астын тикшерер.
- Эрегән авыздан чергән сүз чыга.

* * *

- Авыз балга тигәндә, борын җиргә тиде.
  Авызга су кабу.
  Авызы белән кош тота, теле белән төймә төя.
  Авызы — колакта, колагы — еракта.
  Авызын ачса, үпкәсе күренә.
  Авызына йөзек яшергән.
  Авызында ашы, күзендә яше.
  Ачык авыз, йомык күз.
- Борыны белән боз яра, карыны белән кар яра.
  Борынынан кыссаң, җаны чыгарга тора.
- Тешне аркылы тешләп түзү.
- Ут авызлы, урак телле.

### Төс-бит, йөз-чырай, матур-ямьсез

- Ак матур — чак матур, кара матур — бик матур.
  Ачык йөзле кешедән игелек көт.
- Гөл чәнечкесез булмас, гүзәл назсыз булмас.
- Йөзе ачыкның күңеле ачык.
- Кара кеше кызганчы сары кеше яна башлый.
  Караңгы чырайлы кешедә ачык холык булмый.
  Күрекле дип күбәләкне кочмыйлар.
- Матур ачылыр, ямьсез качыныр.
  Матурлык йөз гаепне каплый.
  Матурлык күлмәк белән сәдәптә түгел, оят белән әдәптә.
  Матурлык туйда кирәк, татулык көн дә кирәк.
- Сылу күңел аздырыр, алтын юлдан яздырыр.
- Төс-битне табага салып йөртмиләр.
  Төсе килешмәгәннең эше килешми.
- Чибәр кешене чикмән белән дә таныйлар.
- Шадра йөрәк яндыра, шома хәтер калдыра.
- Эчке матурлык күктәге ай кебек, тышкы матурлык болан муенындагы энҗе кебек.
- Ягымлының шадрасы күренми, сөйкемленең сипкеле беленми.

Ямьсезнең көзгесе начар, булдыксызның коралы начар.

* * *

- Ачык чырай, кайнар чәй.
- Битенә катык сөртсәң, көчек яламас.
- Йөзем — кара, телем — кыска.
  Йөзгә ыштыр каплаган булу.
- Күрергә чибәр, тәртәгә тибәр.
- Теләсәң — төсең бар, эшләсәң — көчең бар.
- Чибәрлеккә бик чибәр, күрсәң гайрәтең чигәр.
  Чыраем яман булса да, ыраем* яхшы.
- Яңагы яңакка ябышкан.

**Буй-сын, тән-гәүдә, эчке әгъзалар, юан-нечкә, симез-ябык, көчле-көчсез**

- Алтын төймә зур булмый, кечкенә кеше хур булмый.
- Берәүнең буе кыска, берәүнең уе кыска.
  Билеңне бу, битеңне ю.
  Буй белән су буйламыйлар.
  Буй эшләми, кул эшли.
  Буй үстергәнче акыл үстер.
- Җан рәхәте тән белән, тән рәхәте мал белән.
- Кан тартмаса, бавыр тартыр.
  Канны кан белән юмыйлар, су белән юалар.
  Кечкенә кеше телгә беткән була.
  Куй, симерсә, койрыгын күтәрә; кеше, симерсә, борынын күтәрә.
  Көче җитмәгән зур күтәрер.
  Көчең белән мактанма, эшең белән мактан.
  Көчеңне сынамыйча сәнәк күтәрмә.
  Көчле белән көрәшмә, маллы белән даулашма.
  Көчле кешедән тау курыккан.
- Озын кешенең акылы тубыгында була, имеш.
  Озынның бөгеләсе килми, кысканың үреләсе килми.
- Симез — күркәм, бай — чичән.
  Симерү белән авырсаң — такта яр.
- Тере тәннең ямаулыгы үз өстендә.
- Үз сөягең үзеңә авыр түгел.
- Юан нечкә булганчы, нечкә өзелә.

* * *

- Авызымда тешем бар, күкрәгемдә көчем бар.
  Аркадан килеп пычак кадау.
  Аркамны бет ашый, эшләгәнемне эт ашый.
  Аркаңа уклау тыкканмы, бөкерәя алмыйсың.
- Ите сиңа, сөяге миңа*.
- Кешегә буй өләшкәндә мич астына качып калган.
- Нечкә билле, эшкә җилле.
- Сөйкемле сөягең булу.
- Тәнендә карга чукырлык та ите юк.
  Тиресе сөягенә ябышкан.
  Тышы ялтырый, эче калтырый.

**Кул, аяк, бармак, тырнак**

- Алдан аягын киенгән алга чыгар.
  Аягың былчырак булса, баскан саең эз калыр.

Аягың «ләп» итсә, авызың «чәп» итәр.
Аяк атламый баш йөрми.
Аяк бармаса, кул алып кайта алмый.
Аяк сыйса, баш сыяр.
Аяктан кергән авыру бөтен тәнгә таралыр.

- Балта белән агач арасына бармак тыкма.
Бармак белән икмәк кисмиләр.
Бармаклар да барысы да тигез түгел.
Бер аяк белән атлап ерак китә алмассың.
Бер бармагыңны бөкләсәң, бишесе бөгелер.
Бер бармакны тешләсәң, бөтен кулың авырта.
Бер учтан тавыш чыкмый.
- Ике бармак арасына ит үсми.
- Йодрык белән закон кертеп булмый.
- Кул коралы — бармак, бармак башы — тырнак.
Кул кулны юар, ике кул битне юар.
Кул эшли, акыл эшләтә.
Кулы кыймылдаганның авызы да кыймылдар.
Кулың күтәрә алмаган чукмарны билеңә такма.
Кулың пакь булса, йөзең ак.
Кулыңнан бер килсә, бишне кыл.
- Терсәк бик якын да, тешләп булмый.
Тырнак астыннан кер эзләмә.
- Уч җәелсә — юмартлык, уч йомылса — йодрык.
Уң кул башлар, сул кул ярдәмгә килер.
- Һәркемнең бармагы үзенә таба кәкре.
- Чәбәк ике кулдан чыга.
- Энә текми, кул тегә.
- Яткан агач ял табар, йөргән аяк мал табар.

* * *

- Аягы бар, кулы бар, бара торган юлы бар.
Аягы баскан җирне күзе күрми.
Аягы җиргә тими.
Аягын тыккач, таягын да тыгасы.
Аягың — ат, кулың — камчы.
Аяк астында туфрак булу.
Аякка тартсаң башка юк, башка тартсаң аякка юк.
- Бармакка бармак сукмау.
Бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә.
Бер кулында аш, бер кулында таш.
Бер җиңнән ике кул чыгарып эшләү.
Бот күтәреп яту.
- Дөньяга аягы белән килгән.
- Ике аягын бер кунычка тыгу.
- Кисеп ташлаган тырнагына да тормау.
Кулы илә ашый, корсагы илә эшли.
Кулыннан гөл генә таммый.
- Мин аннан сул кулымны селектем.
- Пыяла бармак, көмеш тырнак.
- Син дигәндә аяк идәндә.
- Урта бармак шикелле.
Уч төбендә генә йөртерлек.
Учыннан акканны ялаучы.

***Дөнья көтү, гомер, яшәү-үлем***

**Дөнья, гомер, тормыш**

- Башны тарак шомартмый, гомер шомарта.
- Гомер итү урам аша кичү түгел.
  Гомер кыска — үткәрмә бушка.
  Гомер саплаяк түгел, сабыннан тота алмассың.
- Дөнья — акыллыга уй, җүләргә туй.
  Дөнья бер алдын, бер артын күрсәтә.
  Дөнья, бер көлдерсә, биш елата.
  Дөнья — куласа*, әйләнә дә бер баса.
  Дөнья кыен булса да, ахирәттән күп артык.
  Дөнья эшен ахирәткә калдырма.
  Дөньяда торсаң, торганыңның эзе калсын.
  Дөньяны кусаң — качар, качсаң — куар.
  Дөньяның ун михнәтенә бер шатлык.
- Тормыш тозлы су кебек: эчкән саен эчәсе килә.
- Үткән гомер — аккан су.
- Энә тишегеннән караучыга дөнья бәләкәй.

* * *

- Алды койма, арты дөнья.
  Ач күзеңне — дөнья бу!
  Аңа ике дөнья — бер кәнди.
- Әй дөнья! Кая соң җылы оя?
- Гомереӊ узган юк, күлмәгеӊ тузган юк.
- Дөнья буш калмасын дип туган.
  Дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше.
- Ике дөнья — бер морҗа, төтене кайтмаса ярый.
  Ике дөнья — бер, уртасы камыр.
  Ике дөньядан буш калган.

**Рәхәт-михнәт, шатлык-кайгы, бәхет, язмыш. Бәла-каза, елау-көлү**

- Агачсыз урман юк, нужасыз дөнья юк.
  Алтын — утта, кеше авырлык килгәндә сынала.
  Асылырга язган суда батмас.
  Адәм баласы михнәткә түзә, рәхәткә түзми.
- Бер бәхетең булмаса, Кытайга барсаң да, чәй эчә алмассың.
  Берәүгә язмыш — ана, берәүгә — үги ана.
  Бетәргә бәхет кирәкми.
  Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри.
  Бәла башы бер акча, актыгыннан меӊ акча.
  Бәла бәхеттән тизрәк йөри.
  Бәләкәй мәшәкатьтән качкан — зурысына капкан.
  Бәхет ишектән керсә, юклык морҗадан чыгар.
  Бәхет килгәндә җеп белән тартсаң да килә, киткәндә аркан белән бәйләсәң дә тормый.
  Бәхет пыяла кебек: сакламасаң тиз ватыла.
  Бәхет тәрәзәдән карый, кайгы ишектән керә.
  Бәхетең булмаса, тапкан алтының да бакырга әйләнә.
  Бәхетең булса, алашаң колынлый.
  Бәхетлеңең этәче дә күкәй сала.
  Бәхетсезгә, эремчек ашаса да, кылчык эләгә.
  Бәхетсезне ат өстендә эт талар.
- Елаганның кайгысы бер, көлгәннең — биш.
- Каза житсә, җиң эчендә кул сынар.
  Кайгы үгез түгел, үкереп килми.

Кайгыдан соң куаныч яхшы, куанычтан соң кайгы яман.
Кайгысыз кара суга симерер.
Кеше кайгысы кешегә иртә керә, кич чыга.
Көлке көлә килер, артыннан куа килер.
Күз яше җиргә тамса да кипми.
Күрәсең булса, күркә талап үтерер.

- Маңгайга язылган язмышыңны тир белән сыпырып төшереп булмый.
  Михнәтсез тапкан аштан михнәттә тапкан таш яхшы.
- Нужа артыннан нужа, дөньялар шулай уза.
- Сагыш беркемгә дә сары май түгел.
- Тутык тимерне ашый, хәсрәт йөрәкне ашый.
  Тәхетең югалса да, бәхетең югалмасын.
- Уртаклашкан шатлык — икеләтә шатлык, уртаклашкан кайгы — ярты кайгы.
- Шатлык күрсәң, очынма, кайгы күрсәң, пошынма.

* * *

- Акылым-буем таман, тик бәхетем яман.
  Аның кыйгырышы* бардыр.
- Безгә дигән ырыскал* төшкән калган тырыстан.
  Бодай биреп арпа алган, акча биреп кайгы алган.
- Исемем Шомбай, бәхетем шундай.
- Кайгы өстенә хәсрәт.
- Үзе көләр, йорты бөләр.
- Эчем елый, тышым көлә.

## Яшьлек-картлык, олы-кече, әби-бабай

- Ат азгыны тайга иярә, карт азгыны малайга иярә.
- Бер картлыкта, бер яшьлектә.
  Бер үлүгә карт үлә, бер үлүгә яшь үлә.
  Булыр адәм ун яшеннән баш булыр, булмас адәм кырыкка җитсә дә яшь булыр.
- Дөньяны таныган — карт булыр, юлны таныган — ат булыр.
- Егет килсә — эшкә, карт килсә — ашка.
- Карт кеше җилгә сүз сөйләми.
  Картаерга акча кирәкми.
  Карт хәтер — тишек иләк.
  Картлар — акылы белән, яшьләр матурлыгы белән узар.
  Картлар сүзен капка сал, егетләр сүзен җилгә җибәр.
  Картлар үлем көтә, яшьләр үлеп китә.
  Картлыгың бәхетле булсын дисәң, яшьлегеңдә ялкау булма.
  Картлык дәвер кышка охшар, яшьлек дәвер язга охшар.
  Кырыкта куян атмаган алтмышта болан атмас.
- Олы кешегә юл бирмәсәң, үз юлың бикләнер.
  Олылар сүзен тотмасаң, олыгайганчы игелек күрмәссең.
  Олыларга хөрмәт кыл, кечеләргә шәфкать кыл.
- Үзеңнән бер көн элек туганнан акыл сора.
- Яшь хәтер ташка язган, карт хәтер бозга язган.
  Яшь чак — бер чак, арысландай йөрер чак.
  Яшьлегең тырыш булса, картлыгың тыныч булыр.
  Яшьлек очкан кош түгел, әйләнеп кайтмый.

* * *

- Арттан баксаң — малай, алдан баксаң — бабай.
  Ашын ашаган, яшен яшәгән.
- Кырыкка кадәр малай, кырыктан соң бабай.

- Олы башыңны кече итеп йөрмә.
- Тумас борын картайган.
- Үзе — яшь, үзе — баш.
- Яше күп тә акылы юк.
  Яшьлеген аның яшен атсын, картлыгым минем чәчәк атсын.

**Саулык, авыру, гариплек, дәвалану**

- Авырмас сөяк булмас.
  Авыру — атны да ега.
  Авыру бер үләр, иренчәк көн дә үләр.
  Авыру ишектән керә, энә тишегеннән чыга.
  Авыру күрмәгән кеше сәламәтлек кадерен белми.
  Авыру үлгәнче җаннан өмет, ярлы үлгәнче малдан өмет.
  Авыруга алтын караватта файда бирми.
- Байлыкның башы — тазалык.
  Баш сау булса, башка бүрек табылыр.
  Бурычын яшергән бөлгән, авыруын яшергән үлгән.
- Дөньяда иң кечкенә бәхет — байлык, иң зур бәхет — саулык.
- Сау кешегә көн дә бәйрәм.
  Саңгырауга күк күкрәми, сукырга яшен яшьнәми.
  Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер.
  Сәламәтлек — үзе бер бәхет.
- Тазның гаебен бүрек каплый.
  Телсезнең теле ялганчы теленнән яхшырак.
- Чирлегә җәйге челләдә дә суык.
  Чирнең тиюе тиз, китүе озак.
- Авырып яттыңмы, авыру бактыңмы?
  Арулыгым — байлыгым, тазалыгым — саулыгым.

* * *

- Башы — таз, күңеле — наз.
- Җәрәхәткә тоз сибү.
- Кутыр өстенә чуан.
- Салкын бизгәк булдың.
  Сукырга таяк тоттырган.
- Язгы бизгәк булсаң, җанын алмый китмәс идең.
  Ятыр сырхау түгел, йөрер сау түгел.

**Әҗәл-үлем, җеназа, гүр**

- Авыру гарип итә, үлем юк итә.
- Бай да бер үләр, ярлы да.
  Бурычтан котылып булса да, әҗәлдән котылып булмый.
- Кеше гүренә кеше керми.
  Кешегә үлем теләгәнче үзеңә гомер телә.
- Суның кадере чишмә корыгач беленә, кешенең кадере үлгәч беленә.
- Әҗәл кычкырып йөрми, үкчәңә басып йөри.
  Әҗәлдән котылып булмаса да, чигереп була.
- Үлгән артыннан үлеп булмый.
  Үлгәнне яманлык белән искә алмыйлар.
  Үлгәннән соң тәүбә юк.
  Үлеккә гүр табылыр, тереккә өй табылыр.
  Үлем — елаусыз, туй үпкәсез булмас.
  Үлемнән башка барына да ашык.
  Үлемнән курыксаң, тизрәк үләсең.

Үләсеңне белсәң, кабер казып куяр идең.

- Һәр әҗәлгә бер сәбәп.

* * *

- Алты үлеп, җиде исән калган.
  Аның белән каберең янәшә булмасын.
- Бүген түрдә, иртәгә гүрдә.
- Кәфен байдан, үлем Ходайдан.
- Сиңа да бер зират капкасы, миңа да.
- Тере булып җирдә юк, үле булып гүрдә юк.
- Үлсә дә үкенече юк, торса да сөенече юк.
  Үлсәң — дөнья кала, үлмәсәң — халыкка бәла.
  Үләргә дә үлмәссең, яхшы көн дә күрмәссең.

***Җәмгыять***

**Ил, Ватан, халык, күмәк-ялгыз, киңәшләшү**

- Аерылган ил азар, кушылган ил узар.
  Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
  Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык.
  Асыл кеше алтын дип үлмәс, халкым дип үләр.
  Ашны бергә пешерсәң, куе була.
- Бер кешедә бер акыл, халыкта мең акыл.
  Бердә түгел, илдә көч.
  Берлек барда тереклек бар.
  Берлек кайда — көч шунда.
  Берүзең тау күчерә алмыйсың.
  Болыт берексә — күк күкрәр, халык берексә — җир тетрәр.
  Бөтен халык берьюлы суласа, давыл кубар.
- Ватан барыннан да газиз.
  Ватаны юк — җыры юк сандугач.
- Җиреннән аерылган җиде ел елар, иленнән аерылган үл-гәнче елар.
- Ике киңәш бер булса, илле егет йөз була.
  Ил аткан таш еракка барып төшәр.
  Ил бай булса, ярлылыгың сизелмәс.
  Ил барда — ир хур булмас, ир барда — ил хур булмас.
  Ил белән киселгән бармактан кан чыкмый.
  Ил — иргә, ир илгә таяна.
  Ил кичкән күпердән кич, ул эчкән чишмәдән эч.
  Ил төкерсә — күл булыр, төкермәсә — чүл булыр.
  Ил эче — алтын бишек.
  Ил өстендә чыпчык үлми.
  Ил өстеннән берәр җеп — бер ятимгә күлмәклек.
  Ил өчен яшәмәгән кеше үзе өчен дә яшәми.
  Илгә таянган Идел кичәр.
  Илдә булса — үлмәссең, илсез көн күрмәссең.
  Илдә йөргән ил таныр, кырда йөргән җир таныр.
  Илдә яшисең икән — иленә хезмәт ит.
  Иле ныкның биле нык.
  Илен белмәгән — игелексез, халкын белмәгән — холыксыз.
  Илен белмәгәннән игелек көтмә.
  Иленнән аерылганның канаты каерылган.
  Иленә кайтканның ояты юк.
  Илеңне яу басса, йортыңны кар басар.
  Илнең күрке — тынычлык.
  Илнең төтене дә тәмле.
  Илнең утына ян, бозына туң.

Илнең эше ирнең муенында, ирнең эше илнең муенында.
Ир егет үзе өчен туа, иле өчен үлә.
Иң зур сагыш — Ватан сугышы.

- Кеше илендә иш булалмыйсың.
  Кеше йортында йөреп солтан булганчы, үз йортыңда йөреп олтан бул.
  Киңәшле ил азмас, киң кием тузмас.
  Киңәшле җыен таркалмас.
  Көн күрмәк кеше белән.
  Көтү ташлаган малны бүре алыр, ил ташлаган ирне гүр алыр.
  Күмәк күтәрсә, күлне күчерер.
  Күп типкән җирдән күл чыгар.
- Мал — туйган җирен, ир туган илен онытмас.
- Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил.
- Суы булган җир кадерле, иле булган ир кадерле.
- Тау тауга кушылмас, ил илгә кушылыр.
  Туган илдән туйган юк.
  Туган илең — туган анаң, чит ил — үги ана.
  Туган илнең җире — җәннәт, суы — ширбәт.
- Үз илем — алтын бишек, башка илнең төбе тишек.
  Үз илең — гөлстан, кеше иле — гүрстан.
  Үз илеңдә карлыгач булсаң да, чит илдә карга буласың.
- Халык белән хаклыкка карышма.
  Халык иелсә дә сынмый.
  Халык күзе җир астындагы еланны да күрә.
  Халыкның бер йорты бар, ул да булса — туган ил.
- Һәр чәчәкнең үз иле, һәр халыкның үз төсе.
  Һәркемгә үз иле газиз.
- Чит илдә бай булганчы, үз илеңдә гидай бул.
- Ялгыз йөреп юл тапканчы, күп белән йөреп адаш.
  Ялгыз кеше барлы булса да зарлы.
  Ялгызлык таштан да каты.
  Ялгызлык яман юлдаштан хәерлерәктер.
  Ялгызлык ят илдә беленер.
  Ялгызның көче бетәр, эше бетмәс.

* * *

- Аерылсагыз айга җитәрсез, бүленсәгез көндә бетәрсез.
- Бер без түгел, ил белән.
  Бергә чакта талашыр, аерылгачтын ялашыр.
- Икмәк — илдән, су — күлдән.
  Ил күргәнне күрербез.
  Ил өстендә иләмән йомыркасы*.
  Илгә барса — илгәзәк, өенә барсаң бик мәзәк.
  Илдә юкны пешер, хатын.
  Итенмешең илдән аерым.
- Үз илендә йөри җиңен салып, чит илдә — мескен, гарип.

## Күрше-күлән, авыл-шәһәр

- Абзар сатып алма, күрше сатып ал.
  Авылны макта, шәһәрдә тор.
  Авылы барның кавеме бар.
  Авылыңда ни барны башка авылдан сора, өеңдә ни барны күршедән сора.
- Ерак кардәштән тату күрше яхшы.
- Кала хәлен беләсең килсә, салага бар.
  Каланың уртасында, авылның читендә тор.
  Күрше капкасын какма, үзеңнекен сындырырлар.

Күрше күрше башына тузан какмый.
Күрше күршедән иртә торырга өйрәнә.
Күрше тавыгы каз хәтле, йомыркасы баш хәтле.
Күрше хакы — тәңре хакы.
Күршегә, онга кермәсәң дә, көлгә керерсең.
Күршелек кардәшлектән якын.
Күршеләргә килсә туй, син дә капкаң ачып куй.
Күршеләре белән тату яшәмәгән кешене берәү дә хөрмәтләми.
Күршесенә ышанган ач кунган.
Күршең бай булса да, җигәреңә тай булсын.
Күршең бай булса, тавыгың тук булыр.
Күршең белән яман торыйм дисәң, кәҗә асра.
Күршең сукыр булса, сыңар күзеңне йом.
Күршең үзеңнән яхшы булсын.
Күршеңне дус тот, читәнеңне еш тот.
Күршеңә бер сыер теләсәң, үзеңнеке ике булыр.

- Өеңдәге хәлне күршедән сора.
- Сала бай булса, кала бай була.
- Урын сайлама, күрше сайла.
- Үз капка алдыңның карын күрше капкасына көрәмә.
  Үзеңдә булмаса, күршеңдә булсын.
- Шәһәрдә — дәүләт, авылда — җәннәт.
- Ят авылның карчыгасы — үз авылыңның чыпчыгы.

* * *

- Безнең авылның көне бик озын, кечкенә авылның елы хәтле бар.
  Безнең тавык кукәй салганны бөтен мәхәллә ишетә, күршенең байталы колынласа да, һич тавыш чыкмый.
- Икесе кешенеке, өчесе күршенеке.
- Калада эш сөймәс, салада кибән сөймәс.
  Күршегә кереп торасы түгел.
  Күршедә пешәр, безгә дә төшәр.
- Савыл* арасы түгел, авыл арасы.
- Түбән авыл этләре өрү*.
- Үзем күптән оҗмахлы, күршем өчен кайгырам.
  Үзендә умач умаган, күршесенә кереп токмач кискән.
- Шәһәргә килсә — дустын танымый, далага чыкса — атын танымый.

**Таныш-белеш, дус-иш, дошман**

- Авызың тулы кан булса да, дошман алдында төкермә.
  Аерылмас дустыңа онытылмас сүз әйтмә.
  Аз кайгыны аш баса, күп кайгыны дус баса.
  Акыллы дошманнан курыкма, ахмак дустан курык.
  Ара өзек булса, дуслык төзек була.
  Ат алсаң — тешен кара, дус булсаң — эшен кара.
  Ашаганда дус күп, башка төшсә берсе дә юк.
  Ашны күрсәң кадер тот, дусны күрсәң гадел тот.
- Балык сусыз торалмый, кеше дуссыз торалмый.
  Белгән җирдә баш кадерле, белмәгән җирдә тун кадерле.
  Белешең булса, баргач бәлеш ашарсың.
  Бер иске дус яңаның икесеннән артык.
  Бер күргән — белеш, ике күргән — таныш, өченче күргән — кардәш.
  Берәү җан дусың, берәү мал дусың.
  Бозылышкан дус дошманнан яман.
- Гаепсез аш эзләмә — ач калырсың, гаепсез дус эзләмә —ялгыз калырсың.
- Дошман алдында, эчең еласа да, тышың көлсен.
  Дошман, кырмыска булса, фил булып күренер.

Дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә.
Дошманга саесканнан сак бул, ябалактан уяу бул.
Дошманны куй дип уйлама, бүре дип уйла.
Дошманның азы да күп.
Дошманың бер булса, унга сана: аның да дуслары бар.
Дошманыңа әйтергә ярамаганны дусыңа да әйтмә: аның иртәгә дошман булуы бар.
Дошманыңа үлем теләгәнче, үзеңә гомер телә.
Дус — акчадан кыйммәт.
Дус артында мактар, дошман алдында мактар.
Дус аткан таш баш ярмый.
Дус беленер авырлыкта, ир беленер батырлыкта.
Дус дус булсын, хисабың дөрес булсын.
Дус дус өчен мал бирер, яу килгәндә җан бирер.
Дус-ишле булыйм дисәң, кинә тотма.
Дус көйдереп әйтер, дошман көлдереп әйтер.
Дуслар акчаң барда күп була.
Дуслар хәтерен калдырсаң, дошман хәтерен табарсың.
Дусларның йөзе дә аз, дошманның берсе дә күп.
Дуслык ашаганда беленми, эшләгәндә беленә.
Дусны табу җиңел, саклавы авыр.
Дусның дуслыгы өч көннән түгел, өч елдан соң беленер.
Дустым күп дип йөрерсең, эшең төшкәч белерсең.
Дусын сакламаган дошманга эләгер.
Дусың авырса, син дә ыңгыраш.
Дусың дус булып калсын дисәң, аңа баш булма, иш бул.
Дусыңнан аерыласың килсә, бурычка бир.

- Елан йоклар, дошман йокламас.

- Ике яңа дустан бер иске дус яхшырак.
  Ил өстендә илле дустың булсын.
  Иске дус — иярләгән ат.
  Иш — ишен табар, су — тишеген табар.
  Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

- Кечкенә дошман зур пошман китерер.
  Кешенең иң зур дәүләте — чын дусы.
  Кешенең кемлеген беләсең килсә, иптәшләренә кара.
  Коры ботка — су белән, коры дуслык — сүз белән.
  Корымнан корым йогар, начар дустан сөрем йогар.
  Кош — канат белән, кеше дуслык белән көчле.

- Мең дус — аз, бер дошман — күп.

- Чын дус йөз елдан соң да дус булыр.

- Һәр көлгәнне дусым димә, һәр ачуланганны дошманым димә.

- Яңа дус тап, искесен ташлама.

* * *

- Агылый белән тагылый.
  Алды дошман, арты пошман.

- Биргәндә дус, алганда дошман.

- Гриш-гриш, барыбыз да бер иш.

- Дошман сигез, без унике.
  Дус бар, дошман бар.

- Ике арада битараф.
  Ишәй белән Кушай.

- Танышканга тел бирмәс, йөрешкәнгә юл бирмәс.

- Әмәк белән Җәмәк, көрәк белән сәнәк.

- Җитәк белән Тотак.

Яу, сугыш-кыйнаш, тынычлык, гаскәр,
яу батырлары, кораллар

- Азамат ирнең баласы өстенә яу килсә дә моңаймас.
  Алып анадан туар, аргамак биядән туар.
  Ат — тауда, егет яуда сынала.
  Ата алмаган җәя сайлар.
  Аткан ук кире кайтмас.
- Батыр бер үлгәнче, куркак мең үләр.
  Батыр «илем!» диеп ут кичкәндә, куркак «билем» диеп мичкә керер.
  Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер.
  Бер кораллы мең коралсызны җиңгән.
  Берәү кылыч булса, берәү кын булсын, берәү кызу булса, берәү тын булсын.
- Иелгән башны кылыч кисмәс.
  Ил теләр аманлык*, дошман теләр яманлык.
  Ир егет өйдә туар, яуда үләр.
- Кичүсез елга юк, батыр җиңмәс дошман юк.
  Кылыч күтәргән — кылычтан үтәр.
- Ора алмаган олы күсәк күтәрер.
- Сугыш беткәч, батыр күбәя.
  Сугыш корбансыз булмый.
  Сугышка чукмарсыз бармыйлар.
- Тыныч торасың килсә, кешене тыныч тот.
- Шымчы колагын шыңкайтыр.
- Яу узгач, кылыч айкамыйлар.
  Яуга җаныңны бирсәң дә, сереңне бирмә.
  Яуны санап сугышмыйлар.
- Үзең кормаган мылтыкны атма.

* * *

- Алафасы* олы, кабыргасы коры.
  Атачак угын аткан, җәясен чөйгә аскан.
- Безгә йодрык белән суксаң, үз йодрыгың авыртыр.
  Берне сугып икегә тию.
- Килмәгән яудан курку.
- Зур күтәреп бәләкәй суккан.
- Сугышка барып чукмарын оныткан.
  Сөңгеле Сөләйман* булдың инде.
- Тыныч башым, тыныч колагым.
- Үзе сугып, үзе каравыл кычкырган.
- Яу артыннан йодрык күтәргән.
  Яудан аяр җаным юк, судан аяр туным юк.

**Сыйныфлар һәм социаль катламнар. Хөкем-идарә**

- Аксөяк* эш сөймәс.
  Акыллы хөкемдарда халык тыныч яшәр.
  Акырган башлык түгел, акылы бар — башлык.
  Артында патшаны да сүгәләр.
  Асыл түрә сүзенә карар, алымсак түрә күзенә карар.
  Ач утыр, теләнчелеккә сарылма.
- Бай башына кол җитәр.
  Бай — саңгырау, түрә — сукыр.
  Байдан батрак артмый.
  Барма ханга, үзе килер малга, барма бигә, үзе килер өйгә.
  Башлык булсаң башлы бул, җыерылмас кашлы бул.
  Берәүләр — түрә, берәүләр түрә янында көн күрә.

Биләр белән алышып булмас, тирәк белән көрәшеп булмас.
Бикә бизәнгәнче туй бетә.
Бинең авызы кыек булса да, сүзе туры.

- Гадел башлык — халык өчен, залим башлык — тамак өчен.
- Елан койрыксыз булмас, би боерыксыз булмас.
- Залим түрәдән ерак кач.
- Кар башына кар җитә, би башына кол җитә.
  Кешене хөкем итсәң, үзең хөкем ителерсең.
  Кол булу җиңел, хөр булу авыр.
  Көлгән түрәдән ерак кач.
- Начар арба юл боза, начар түрә ил боза.
- Патша залим булса — йорт тузар, патша галим булса — йорт узар.
  Патша казнасында ни юк булса, хәерче капчыгында шул бар.
  Патша талап ала, хәерче теләнеп ала.
  Патшадан курыкма, губернаторыннан курык.
  Патшаң сукыр булса, бер күзеңне кысып үт.
- Ташта тамыр юк, түрәдә бавыр юк.
  Теләнче оятын кесәсенә салган, ул да ертыгыннан төшеп калган.
  Теләнчегә якты чырай бирсәң, ямаулык сорар.
  Тугры бидә туган юк, туганлы бидә иман юк.
  Төрмә бик таза да, берәү дә кереп ятарга теләми.
  Түрә — боерыгына, төлке — койрыгына, ярлы — белэгенә ышаныр.
  Түрәгә ут төртсә дә гаеп юк, кара кешегә шәм кабызса да гаеп.
  Түрәнең түрен күрмәссең, еланның аягын күрмәссең.
- Үзен зур тоткан түрәнең соңы хур булыр.
- Хаким халыкка ия, халык жиргә ия.
- Якасы юк тун булмас, законы юк ил булмас.
  Яхшы булса — бидән, яман булса — колдан.

* * *

- Андый гына хан кызында да була.
  Ашау байдан, үлем Ходайдан.
- Боермак сездән, йөгермәк бездән.
  Бу патшаның тәхете ни дә, бәхете ни.
- Йә тәхет, йә ләхет.
- Куркытмага хуҗам юк, биетмәгә бикәм юк.
- Падишаһым, солтаным, иске чабата олтаным.
- Син дә би, мин дә би, иләнмәгән тире ки.
  Син түрә дә, мин түрә, безнең эшне кем күрә.
- Хәерче кесәсендәге шикәр кебек шомарган.
- Ыгыр-шыгыр көн үтсен, байның күңеле үссен.

### *Гаилә һәм туганлык*

### **Гыйшык, мәхәббәт, сөйгән яр**

- Балдак бармакка күрә, яр йөрәккә күрә.
  Бер күктә ике ай булмый, бер күңелдә ике мәхәббәт булмый.
- Гаепсез яр эзләгән ярсыз калыр.
  Гашыйк эшен дә онытыр, ашын да онытыр.
  Гыйшыкка ишек бикле булса, тәрәзәдән керер.
  Гөл — чәнечкесез, мәхәббәт көнчелексез булмас.
- Дәртсез — дивана, гыйшыксыз — багана.
  Дөнья күрке сөйгән яр белән.
  Дөньяда өч нәрсә юк: диңгезгә— капкач, күккә — баскыч, мәхәббәткә — дару.

- Йокы ястык теләмәс, гыйшык матур теләмәс.
- Кеше белән уртак кием кимә, кеше белән уртак яр сөймә.
  Күз меңне күрер, күңел берне сөяр.
  Күп сайлаган — тазга, күп эзләгән — базга.
- Матурлык туйда кирәк, мәхәббәт көн дә кирәк.
  Мәхәббәт акчасыз да бакча ясый.
  Мәхәббәт, бер булса да, ике йөрәктә яши.
  Мәхәббәт уты тәмуг утыннан җиде өлеш артык булыр, ди.
  Мәхәббәтне ара ераклыгы сыный.
- Сылу сылу күренмәс, сөйгән сылу күренер.
  Сөйгәнеңнең суы да балдан татлырак.
- Талымсызга тәмсез юк, мәхәббәткә ямьсез юк.
- Үз сөйгәнең үзеңә хур кызыдай күренә.
  Үзең янмасаң, башканы яндыра алмассың.
- Чәчәк яз белән, мәхәббәт наз белән.
- Яраткан күңелдә ялган булмый.

* * *

- Барысы да парлы-парлы, без генә моңлы-зарлы.
  Бер көн Харис белән, бер көн Барис белән.
- Гыйшыгын гыйшык, йөрергә ката кыйшык.
- Ирене белән үбәр, теле белән өзәр.
  Иске йөрәк, яңа дәрт.
- Мине күр дә дәртеңнән үл.
- Үбешкән дә көлешкән, соңыннан башына уй төшкән.
- Февраль микән, март микән — гыйшык микән, дәрт микән.
- Ятканга ябышкан, болар каян табышкан.

### Егет, егетлек сыйфатлары

- Абруйлы егеткә әҗәлле куян юлыга, ди.
  Акылсыз егет — авызлыксыз ат, юньсез егет — йөгәнсез ат.
  Алдан сөйләү егет эше түгел.
  Ат яхшысы тездән билгеле, егет яхшысы сүздән билгеле.
  Атның даны егет кулында, егетнең даны үз кулында.
- Байның күрке мал белән, егет күрке дан белән.
  Батыр егет — ил күрке.
- Ваемсыз егет — ишәккә иптәш.
- Егет буласың килсә юмарт бул.
  Егет булса, җебеп тормас; җебеп торса, егет булмас.
  Егет егетнең көзгесе.
  Егет кеше — арысланга тиң кеше.
  Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
  Егет сүзе бер булыр.
  Егет чагында малсыз да булма, ярсыз да булма.
  Егет үлемгә дә елмаеп бара.
  Егетнең егетлеге ат җигүеннән билгеле.
  Егетнең сүзе үлгәнче үзе үлсен.
- Иртә торган егетнең бәхете артык булыр.
- Куркак егет куй башыннан да курка.
- Мин-минләнгән егетне яу килгәндә күрербез.
- Чаман* егет дигәнче, яман егет дисәңче.
- Яңгырсыз болытның җиле бар, дымы юк; уңмаган егетнең теле бар, юне юк.

* * *

- Егет фартавый*, атлар тарталмый.
  Егет фырт, аты хөрт.
  Егет җилле, чикмәне билле, формасы бар да, нормасы юк.
  Егет җилле, җиләне кыскарак.
- Төнлә — егет, көндез — үлек.

**Кыз**

- Аулак өйдә кыз сайлама, урак кырында сайла.
  Ашыккан кыз кияүгә барса да мантымас.
- Белемле кыз — бирнәле кыз.
- Гөл үссә — җирнең күрке; кыз үссә — илнең күрке.
- Кош борынсыз булмас, кыз урынсыз булмас.
  Куштан кыз матур була.
  Кыз байлыгы — күркәм холык.
  Кыз баланың күңеле саф су кебек.
  Кыз кеше — мыскалга салынмаган ак ефәк.
  Кыз чак — кояшлы көн.
  Кыз яхшысы холыктан билгеле.
  Кызлар йөзек эченнән дә үтә.
  Кызлы йорт — нурлы йорт.
  Кызлы кеше капкасына кырык ат бәйләнер.
  Кызы барның назы бар.
  Кызыңның төсен мактама, эшен макта.
- Мактаулы кыз туйда хур булыр.
- Оялчан кыз — сөйкемле кыз.
- Тауның күрке — таш, кызның күрке — чәч.
- Яхшы кызны авылдан җибәрмиләр.
- Әдәпле кыз сәдәпле.

* * *

- Ашка саласы тоз түгел, базар торасы кыз түгел.
- Әкеми, сиңа кызлар тәтеми.
- Безгә дигән кыз анасыннан тумаган.
- Кияүгә бирәсе кыз түгел, ашка саласы тоз түгел.
- Сиңа дигән кызлар әле мич алдында күмер ашый.

**Гаилә кору, яучы-димче, буйдак йөрү**

- Анасы мактаганны алма, ил мактаганны салма.
  Ат алсаң, арба кирәк; хатын алсаң, бар да кирәк.
  Ат урлаган бур булыр, кыз урлаган хур булыр.
  Аучы ау аулый, яучы кыз яулый.
  Ашны ачыкканга бир, кызны гашыйгына бир.
- Барсаң табып бар, егетне танып бар.
  Бөркет булмый таусыз-кыясыз, адәм булмый йортсыз-семьясыз.
- Иртә торган белән иртә өйләнгән алданмас.
  Иртә өйләнгән улына-кызына кинәнгән.
  Иң матур итеп сайраучы кош — сандугач; иң матур итеп сөйләүче кеше — яучы.
- Кош — канаты белән, семья татулыгы белән көчле.
  Кызы бар кешегә кырык яучы килә.
  Күке оя кормас, тиле семья кормас.
- Мәхәббәтсез семья — тамырсыз агач.
- Өйләнмәгән өйсез булыр, тормышы көйсез булыр.
- Семья — бәхет ачкычы.

- Хатын алганда төсеннән бигрәк холкын тикшер.
- Яхшы атка камчы кирәкми, яхшы ярга яучы кирәкми.

* * *

- Без өйләнгәч төн кыска булды.
- Өйләнгәндә җырлый, өйләнгәч елый.
- Синең өйләнәсең юк, минем кияүгә барасым юк.
  Суга дип киткән, кияү алып кайткан.
- Төядәй кыз биреп, төймәдәй ит җимәдем.
- Үзләре табышкан, үзләре барышкан.

### Туй-төшем, бирнә, калым

- Алда булачак туй өчен хәзердән биеп торма.
- Әнә туй, менә туй, ат өстенә кәҗә суй.
- Киңәшле туй таркалмас.
  Көн дә бәлеш, көн дә туй булмый.
- Туй дигәндә түмгәк тә тибрәнә.
  Туй кунак белән күркәм.
  Туй яме уен-көлке белән.
  Туй үпкәсез булмас.
  Туйга барсаң туеп бар, ашка барсаң ашап бар.
  Туйга дигәч, тугыз еллык хаста терелгән.
  Туйның булуыннан «була» дигәне күңелле.

* * *

- Аргы очта туй бар дип, бирге очта биегән.
- Миңа туй булсын, тамакка сый булсын.
- Өйдә авызын япмаган, туйда җырлар җыр тапмаган.
- Туем капкага җиткән, орчык-кабам кайда икән?
  Туең узган, туның тузган.
  Туй сыенда яшибез.
  Туй сылтавы белән тайлы булдым.
- Хәерле булсын Хәмидәнең никяхы.
- Чакырмаган туйга күлмәк кигән.

### Килен (һәм башкалар)

- Ашамыйм дигән килен ашады җитмеш белен.
- Ике килен пешергән аш йә гел тоз булыр, йә гел тозсыз булыр.
- Килбәтле кыз килен булгач күренер.
  Килен килбәтле булсын, сүзе ширбәтле булсын.
  Килен төшсә, төкле аягы белән төшсен.
  Киленнең уңганын морҗа ачуыннан ук белеп була.
- Шапшак киленнең себеркесе чүп астында булыр.
- Яхшы килен үз кызыңнан яхшы, яхшы кияү үз улыңнан яхшы.
- Киленне килгәч күрербез.
- Үземнең киленем усал, кызымның биеме усал.

### Кияү (һәм башкалар)

- Ат тозга килә, кияү кызга килә.
- Киявең көйсез булса, теш сызлавыннан яман булыр.
  Киявеңнең түреннән улыңның ишек төбе артык.
  Көзге катык, көмеш кашык киявем белән кызыма; язгы катык, ярык кашык киленем белән улыма.

- Юньсез кияү йорт тотмас.

* * *

- Кияү үзебезнеке, гаеп итмәс*.
- Көйсез кияү булды бер.
- Утыр, кияү, урынча, эскәмия буенча.
- Эч, эч, кияү, шикәр киштәдә.

### Ир, ир-ат, ир-егет

- Агым судан ат кичәр, авыр көннән ир кичәр.
  Алты кабып ат туйсын, җиде кабып ир туйсын.
  Ат аенда сыналыр, ир елында сыналыр.
  Ат үлсә — тояк калыр, ир үлсә — мактаулы аты калыр.
- Имән агачның иелгәне — сынганы, ир егетнең оялганы —үлгәне.
  Ир, башын бөксә дә, тезен чүкмәс.
  Ир булсын, ипие булсын.
  Ир дигәннең намусы бар.
  Ир-егет ата-анасын ташламас.
  Ир-егетнең эчендә игез арыслан булыр.
  Ир-егетнең эчендә иярле-йөгәнле ат ятыр.
  Ир кичмәслек елга юк.
  Ир уңмаганы икмәксез.
  Ир өйдә күп утырса, өй пәриле булыр, имеш.
  Ирлек сүздә түгел, йөрәктә.
  Ирмен дигәннең сүзе төз, төз булмаса — аннан өмет өз.
  Ирне намус борчый.
  Ирнең асылы эштә танылыр.
- Кайгы күрми егет ир булмый.
  Карчыганың очышыннан, ир-егетнең аяк басуыннан.
- Намуслы ир хур булмас.
- Тырышкан ир морадына ирешер.
- Үзеңне ир белсәң, үзгәне шир* бел.
- Һәр бүрек кигән ир түгел.

* * *

- Карап торуга — ир, тиеп карасаң — чир.
- Өйдә арыслан кебек, урамга чыкса — тычкан кебек.

### Хатын, хатын-кыз

- Авылда талашчы хатын булса, бүредән эт кирәкми.
  Акыллы хатын — хәзинә.
  Атың начар булса да, хатының яхшы булсын.
- Баеткан да хатын, бөлдергән дә хатын.
  Бер хатын: «Салам яна»,— дисә, икенчесе: «Самар яна!» —дип әйтер, ди.
  Бәхетнең башы — хатыннан уңу.
- Дәүләт-байлык дус-иш аркасында, яхшы исем хатын аркасында.
- Изге хатын — оҗмах хуры, яман хатын — дөнья гүре.
  Ике хатын бергә килсә — базар, өч хатын бергә килсә —ярминкә.
- Йорт тоткан да хатын, йорт бетергән дә хатын.
- Күктә туй бар дисәләр, хатыннар баскыч сорар.
- Суга барган хатынның алтмыш авыз сүзе бар.
- Тависнең төзәнмәгәне булмас, хатынның бизәнмәгәне булмас.
- Уңган хатын кар өстендә казан кайната.
  Уңган хатын ул китерер, изге хатын кыз китерер.

Уңмаган хатынның пич алды тулы чүп була.

 Хатын кеше — өй фәрештәсе.
Хатын киңәше ханга ярый.
Хатын-кыз күп булган йортта су булмый.
Хатын-кызны бизәктән дә бигрәк әдәп-нәзакәт бизи.
Хатын уңса казна, уңмаса каза.
Хатыннар өчен иң авыр эш — сер саклау.
Хатыннарның кылычы бер вакытта да тутыкмый.
Хатыны яхшыга бәхет кирәкми, хатыны яманга ләхет кирәкми.

 Шайтан булдыра алмаганны хатын булдырган.

 Яман хатын мактаныр, төшкә тикле ятам, дип.
Яхшы кием — туй дәүләте, яхшы хатын — өй дәүләте.

* * *

 Кеше хатыны — мамык, минеке — кабык.
Кеше хатыны пешереп алганчы, минем хатын көйдереп тә ала.

 Сабаның чөе юк, бичәсенең көе юк.

 Үзе чуклы, түре чүпле.

 Хатыным сукыр — җаным тыныч.

**Ир һәм хатын**

 Акыллы ир хатынын яманламас.
Ата алмаган атыннан күрер, кайтып килеп хатыныннан күрер.

 Бер хатынның хәйләсе кырык ир хәйләсеннән артык.
Бил бәйләп кенә ир булмассың, чәч тарап кына хатын булмассың.

 Ир акыллы булса, хатын күндәм була.
Ир — баш, хатын — муен.
Ир белән хатын — игезәк җан.
Ир белән хатын — куш тирәк: төбе бер дә тамыры бер.
Ир китерә белсен, хатын җиткерә белсен.
Ир сугыштан кайтыр, сугыш хәлен хатыныннан ишетер.
Ир яхшы булса, ямьсез хатынга дә төс керә, ди.
Ир өй салган — хатын җимергән, хатын өй салган — шайтан да җимерә алмаган.
Ир өйдән чыкса — бәрәкәт, хатын-кыз өйдә торса — бәрәкәт.
Ир өйнең бер чатын тотып торса, хатын өч чатын тотып торыр.
Ирле хатынга бүре дә тими.
Ирләр өйдә утырса да, күңеле тышта; хатын-кыз тышта йөрсә дә, күңеле өйдә.
Ирнең уңмаганы икмәксез булыр, хатынның уңмаганы күлмәксез булыр.

 Оялчан хатын — шәһәр бәясе, оялчан ир — тәкә бәясе.

 Өйне кырык ир тутырмый, бер хатын тутыра.

 Хатын гайрәтле булса, ир куркак булыр.
Хатын канаты — ир, ир канаты — ат.

 Яман ирне яхшы хатын кеше итәр.
Яман хатынның, пычагы үтмәсә дә, теле үтәр.

* * *

 Атыбыз — ирле, буебыз — ярлы.

 Ире чыкса — киенер, ире кайтса — көенер.
Ирем китте калага, мин киттем далага.

**Бала**

 Әүвәлге байлык — бала.

 Бала — бәгырь җимеше.
Бала егыла-егыла егылмаска белер.
Бала елап үсә.

Бала, йөрергә өйрәнгәнче, үрмәләп йөри.
Бала, оятын белсә, бала да булмас иде.
Бала табу бер кыен, бала багу мең кыен.
Бала тездә чакта сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә.
Бала-чагалы кеше җимешле агач кебек.
Бала үз ризыгы белән туа.
Бала үстерсәң, буен гына түгел, акылын да үстер.
Балага өч яшь тулганда бөтен өй сөйләшергә өйрәнә.
Балалы кеше — бай кеше.
Балалы өй — базар, баласыз өй — мазар.
Балалы өйдә гайбәт булмас.
Баланы бозасың килсә — макта.
Баланы иркәләү аны типкәләүдән яман.
Баланы кыйнаганчы багананы кыйна.
Баланы кыйнап юатма, көйләп юат.
Баланы эт тә ярата, бия дә, хикмәт — тәрбиядә.
Баласыз өйдә кот юк.
Баласызның җаны тыныч, ә картлыгы — куркыныч.
Бер баланың авыруы ун өлкәннекенә тора.
Бишкә кадәр һәрбер бала — патша.
Бу дөньяда бал татлы, балдан да бала татлы.

- Исәр баладан иркә бала яман.
- Өеңдә ни юк булса, бала шуны сорый.
  Өйнең яме бала белән, күлнең яме кама белән.
- Сабыйга ат та — ат, таяк та — ат.
- Теше чыккан балага чәйнәп биргән аш булмас.
- Утынны чапкан яксын, баланы тапкан баксын.
- Үзе егылган бала еламас.
- Һәркемнең үз баласы үзенә якын.
- Яхшы бала кечкенәдән билгеле.
  Яхшы туса — илгә кот, яңгыр яуса — җиргә кот.

* * *

- Бездә тумаган бездә тормас.
- Кырык бала тапкан, керер капка тапмаган.
- Мич астында да бала, мич өстендә дә бала.
- Ник туганына үкенә.
- Өстән бишек тирбәтә, астан баланы чеметә.
- Элек туган да — белми туган, соң туган да — белеп туган.

Ир бала һәм кыз бала, ул һәм кыз

- Атадан алтау тусаң да, үз улың булмаса ялгызсың.
- Бер яхшы кыз җиде улга тора.
  Бәхете булган кешенең улы ипле, кызы күрекле булыр.
- Ир бала туса, өеңә бер фәрештә кунар, ди; кыз бала туса —җитмеш фәрештә кунар, ди.
  Ир бала унбиштә — өй хуҗасы.
- Кыз холыгы белән сөйкемле, ул әдәбе белән сөйкемле.
  Кызлы кеше — назлы кеше, уллы кеше — юллы кеше.
- Малай, кулына акча керсә, көчек сатып алыр.
- Уллы урманда үлмәс, кызлы кырда үлмәс.
  Уллы утынга ялчымас, кызлы суга ялчымас.
  Улың ялкау булса, үзеңнән күр.
- Һөнәрле булып ул үссен, холыклы булып кыз үссен.

* * *

- Балакаем, булыр сиңа ала таем.
- Ни булса — ул булыр, ул булмаса, кыз булыр.
- Ул да булды — кыз кирәк.
  Ул да тумас, кыз да тумас, туса да тормас.
  Улым юк урамда, кайгым юк буранда.
  Улсызга ул булып, кызсызга кыз булып.
  Утыз улым юк, кырык кызым юк.

**Үги бала, кеше баласы, үксез-ятим**

- Илдән берәр җеп җыйсаң да, ятимгә бер күлмәклек булыр.
- Кеше баласы кештәккә тыксаң да илекмәс*, бүре баласы бүреккә салсаң да илекмәс.
  Кубыздагы кыл моңлы, үксез үскән кыз моңлы.
- Тишек кайда — җил шунда, ятим кайда — сүз шунда.
- Үз кызына алкыш, үги кызга талкыш.
  Үксез бала үз кендеген үзе кисә, имеш.
  Үксез баланың теле ачы булыр.
  Үксезгә үгет бирүче күп, урын бирүче юк.
  Үксезнең авызы ашка тисә, борыны ташка бәрелер.
- Ятим баланың күңеле сынык.
  Ятим ярасының ямавы да өстендә.
  Ятимнәрнең бәйрәме — яңа күлмәк кигәндә.

**Ана. Үги анна**

- Алып анадан туар, аргамак биядән туар.
  Ана ачуы — язгы кар: күп булса да, тиз эри.
  Ана куены туннан җылырак.
  Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс.
  Ана теләге диңгез төбеннән чыгарыр.
  Ананың бер догасы җиде мулланың бәддогасын җиңә.
  Анаң үги булса, атаң үзеңнеке булмас.
- Инә* сүзен тотмаган олыгайганчы игелек күрмәгән.
- Мең нәнкә дә бер әнкәне алыштыра алмас.
- Үги ананың иң яхшысыннан да козгын тавышы килә.
  Үз атаң белән ачы булсаң да, үги анаң белән төче бул.
  Үз анасын зурлаган кеше анасын хурламас.
- Чит кешенең сөюе — үз анаңның йодрык төюе.

* * *

- Ана куеныннан чыгып җитмәгән.
  Анадан алган сөтләрен китерү.
  Анасы яламаган.
- Мәнди анасы да белә*.
- Тапкан анам түгел, яраткан Аллам түгел.

**Ана һәм бала**

- Агачына күрә алмасы, анасына күрә баласы.
  Ана күңеле балада, бала күңеле далада.
  Ана янында бала ятим булмый.
- Бала ананы утка бастырыр.
  Бала көя көя хәтле, ана көя дөя хәтле.
  Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр.
  Баласы алма капканга анасының теше камашкан*.
  Баласы суга төшәр, анасы утка төшәр.
- Улы данга чыкса, анасы яшәрер.

Уңмаган хатынга бала сылтавы.

- Ханнан бала олы, баладан ана олы.
- Яшь баланың зарын анасы белер.

## Ата

- Ата алмаган атасына үпкәләгән.
Ата аркасы — кала аркасы.
Ата дошманын үзеңә дус тотма.
Ата малы тиз төкәнер.
Ата һөнәрен тоткан — бай.
Атасыз йорт — батасыз* йорт.
Атаң тырыш булса, камыт бавың каеш булыр.
Атың барында җир таны, атаң барында ил таны.
- Җәйләүгә тугай яхшы, киңәшкә атай яхшы.
- Үзең тырышып тапмасаң, ата малы бер айлык.

## Ата һәм бала

- Ата гайрәтле булса, бала гыйбрәтле була.
Ата һөнәре — балага мирас.
Атадан качкан ул башсыз, хуҗадан качкан кол башсыз.
Атадан яхшы бала туса, атасының ишектәге башын түргә кичерер; атадан яман бала туса, атасының түрдәге башын ишеккә кичерер.
Атасы ат җиккәнче улы атланып чапкан.
Атасы балыкчы булса, бала да суга карый.
Атасы болан атмаганның баласы колан атмас.
Атасы карлыган ашаган булса, балаларының да теше камашыр.
Аттан тай узар, атадан бала узар.
- Бала башында бер кайгы, ата башында мең кайгы.
- Елыйсы килгән бала атасының сакалы белән уйнар.
- Мөгезен сындырганны болан онытмас, атасын хурлаганны углан онытмас.
- Яхшы ата баласы — яңа тунның якасы.

## Ата-ана һәм балалар

- Алтын-көмешнең искесе булмас, ата-ананың бәһасе булмас.
Ана өйрәтсә, балалар җитез булыр; ата өйрәтсә, балалар акыллы булыр.
Аналы-аталы — алтын канатлы.
Анасы юк кыз ятим, атасы юк ул ятим.
Ата-ана бердәм булса, балалары күркәм үсә.
Ата-ана гайрәтле булса, бала гыйбрәтле була.
Ата-ана догасы утка-суга батырмас.
Ата йөрәге таудан өлкән, ана йөрәге диңгездән тирән.
Ата күргән ук ата белер, ана күргән тун кисә белер.
Аталы бала — аркалы, инәле бала — иркәле.
Атаңны башыңда тот, анаңны учыңда тот.
- Бала яман булса, ата-анасына оят булыр.
- Дөньяда ата-анадан башка бар да табыла.
- Өч яшьлек малай атага булышыр, өч яшьлек кыз анага булышыр.

* * *

- Ата улны белми, ана кызны белми.
Атасын сорасаң — таныксыз, анасын сорасаң — белексез.
Атаң яхшы, анаң яхшы, кемгә охшаган син шакшы.
- Әтисен-әнисен тапмадым*.

Нәсел-нәсәп, туганнар

- Агач нәселе җир үтә керә, адәм нәселе ил үтә керә.
  Ара өзек булса, карендәшлек якын була.
  Ата-бабалы кеше — тамырлы имән.
- Бай булсаң — туган, ярлы булсаң — суган.
  Бакма асылына, бак нәселенә.
  Башыңа бәла төшкәндә туганыңны танырсың.
- Җиде авылда җиде кардәшең булсын.
- Ике туган, бергә килсә, сандугачтай сайрашыр.
  Ит тырнактан аерылмас, туган туганнан аерылмас.
- Кардәш кардәшне кабергә кадәр ташламый.
- Мал кардәш түгел, баш кардәш.
- Нәселленең сүзе өскә чыгар.
- Тату туганнар таштан койма койганнар.
  Туган бар җирдә ярдәм бар.
  Туган кадере — аерылгач, тун кадере — ертылгач.
  Туганнар татулыгы байлыктан артык.
  Туганыңа авыр сүз әйтмә, йөрәге әрнесә ят булыр.
  Туганыңа сүз үтә.
- Үзеңнеке бер этсә дә бер тарта.
- Ыру-туган бер тередә, бер үледә.
  Ыру-туган талашыр, дошман килсә ярашыр.
  Ырулының угы узар.

* * *

- Безнең нәселнең күзе яшел.
- Ике туып бер калганым түгел.

**Абый-эне, апа-сеңел**

- Абыеңның сакалы янганын күрсәң, үзеңнекен суга тык.
  Ага булсаң — акыл әйт, акыл әйтсәң — мәгъкуль әйт.
  Ага-эне тату булса, ат күп булыр; апа-сеңел тату булса, аш күп булыр.
  Агай-энедән аю-бүре курыккан.
  Агай-эненең кадере аманлыкта беленми, яманлыкта беленер.
  Аганы күреп эне үсәр, апаны күреп сеңел үсәр.
- Олы ага — икенче ата.
- Үз агасын агаламаган — кеше агасын якалар.
- Энесе барның тынычы бар.
- Яхшы ага — җил ягыңа койма, ышык ягыңа кала.

* * *

- Агай олы, мин зур — атка печән кем салыр?
  Агай эшли — мин арыйм.
- Камар агасы юк, куркыр хуҗасы юк.
- Син ага да мин ага, бу сыерны кем бага?
- Җиңем яман булса да, якам яхшы; үзем яман булсам да, агам яхшы.

**Ир ягы һәм хатын ягы карендәшләре**

- Ашамыйм дигән кодача ашаган алтмыш юача.
- Балдыз — алтынга манган көмеш.
  Бажа бажасын күрсә, теле кычыта.
- Җиде бажаны бер бүре ашаган*.

- Ир кардәше — ишек катында, хатынныкы — түр башында.
  Ир ягы тарткан — арткан, ир ягы төрткән — бөлгән.
- Каенанасы нинди — килене шундый.
  Кода булганчы бик сынаш, кодалашкач бик сыйлаш.
  Кодагый утырмаса, атка җиңел була.
  Кодалар капка төбенә килеп җитте, орчык-кабаңны ал, кызым.
  Кызымның каенанасы усал, үземнең киленем усал.
  Кырык өй кода булса, кыргын* килмәс.
  Кәҗә булса да малың булсын, баҗа булса да нәселең булсын.
- Усал каенанага бер килен дә начар, ун кияү дә яхшы.
- Хатын кардәше килсә — табага бәлеш, ир кардәше килсә — көн дә тавыш.
- Үзе ялкау каенананың килене дә ялкау була.

* * *

- Ала-кола безнең кода.
- Әлеге дә баягы, каенатаның таягы.
- Ике баҗа, икесенә бер кәҗә.
- Кода-кодагый булыштык, балалар туасы гына калды.
- Хикмәти хода, Мөхәммәди кода.
- Үзе ача, үзе коча, ай-һай безнең кодача.

### Туган һәм чит-ят

- Агай-эне ташласа, ятка ямь.
  Ашап эчкәндә дус яхшы, кайгылы көндә үз яхшы.
- Елашырга үз яхшы, сыйлашырга ят яхшы.
  Ерактагы туганнан якындагы ят артык.
- Ике туган арасына ят кермәс.
- Туган туган белән табышыр, ятка бәла ябышыр.
- Үз үтермәс, ят ярлыкамас.
  Үзеңнеке үз итмәсә, ятлар бигрәк үз итмәс.
- Эше төшсә — үз кеше, эше бетсә — ят кеше.
- Яман туганың булганчы яхшы иптәшең булсын.
  Ят кешенең баскычы биек.
  Ятныкы яннан үтәр, үзеңнеке үзәктән үтәр.

## *Хезмәт һәм ял*

### Эш-хезмәт. Аның вакыты, сыйфаты һәм нәтиҗәсе. Күмәк эш, өмә

- Авызындагы тешенә бакма, кулыннан килер эшенә бак.
  Авыр эшкә беләк бар, кыю эшкә йөрәк бар.
  Агач — җимеше белән, кеше — эше белән.
  Аз сөйлә, күп эшлә.
  Алтын утта сыналыр, адәм эштә сыналыр.
- Башланган эш — беткән эш.
  Бер калган эш кырык елга калыр.
  Бетмәгән эш — пешми калган җимеш.
  Бүгенге эшне таңга калдырма.
- Данның төбе — хөрмәт, хөрмәтнең төбе — хезмәт.
- Җимешне вакытында аша, эшне вакытында эшлә.
- Казганган каз ите ашаган, казганмаган кара ипи дә тапмаган.
  Калган эшкә кар явар.
  Кем эшләми, шул ашамый.
  Кошның матурлыгы төсе белән, кешенең матурлыгы эше белән.

Күмәк эш үрчемле булыр.

- Маңгай тире эшнең сыйфатын яхшырта.
  Мич башында ятып икмәк булмас.
- Плансыз эш — тозсыз аш.
- Сүз күп җирдә эш аз була.
- Тик торганга шайтан таягын тоттырган.
  Тирләп эшләсәң, аш тәмле була.
- Үткән эш кире кайтмый.
- Хезмәт төбе — хәзинә.
  Хезмәте каты — җимеше татлы.
- Эч пошуның дәвасы — эш.
  Эш батыры — ил батыры.
  Эш башына юньсез кеше килсә, эш кирегә китәр.
  Эш бүре түгел — тешләмәс.
  Эш кешене төзәтә, ялкаулык — боза.
  Эш сөйгәнне ил сөйгән.
  Эше юк әтәч булып кычкырыр.
  Эшең калса иртәгә, чуан чыгар җилкәңә.
  Эшле кешегә иң зур җәза — тик тору.
  Эшле килер — эш арттырыр, эшсез килер — эш калдырыр.
  Эшлегә көн җитми, эшсезгә көн үтми.
  Эшлисе килмәгәннең эче авыртыр.
  Эшләгән туңмас, эшләмәгән уңмас.
  Эшләмәсәң эш көне, ни ашарсың кыш көне.
  Эшләп ашасаң, арыш ипиеннән дә күмәч тәме килә.
  Эшләп баю гаеп түгел, көчләп баю гаеп.
  Эшләп үлмәссең, чирләп үләрсең.
  Эшне башлаганда ахырын уйла.
  Эшне башлама, башласаң, ташлама.
  Эшне сөйсәң — үз анаң, сөймәсәң — үги анаң.
  Эшсез бәхет табылмый, табылса да тагылмый.
- Яратмаган эш авыр була.
  Яратып эшләгән эш куаныч китерә.
  Яхшы эш үз-үзен мактый.

* * *

- Аз эшли, аз эшләсә дә күп тешли.
  Аның эше тауга каршы тәгәри.
  Аш дигәндә — ашыгыр, эш дигәндә — башын кашыр.
  Аш дигәндә — җан-фәрман, эш дигәндә — юк дәрман.
  Аш янында ат кебек, эш янында эт кебек.
  Ашаганда мин телсез, эшләгәндә мин өнсез.
  Ашка дисәң — Зәбидә, эшкә дисәң — юк өйдә.
- Башлаганда эшне үзем генә башлаган идем, бетергәндә өмә белән дә бетереп булмый.
- Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә.
- Исеме олы, эше коры.
- Кулы берне эшли, теле икенчене сөйли.
  Кулы эштән бушамый, эше эшкә охшамый.
- Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче генә эшләү.
- Нечкә билле, эшкә җилле.
- Тик тә тормыйм, бик тә кырмыйм.
  Тирләмәдем-пешмәдем, эшләдем дә эшләдем.
- Эш бетте, көлтә җыясы гына калды.
  Эш дигәндә мин бармам, аш дигәндә мин калмам.
  Эшкә булса — уф табаным, ашка булса — китер табагым.
  Эшләп түгел, кешнәп ярый.

Эштә — эшләки, сүздә — сандугач.

### Эшкә өйрәнү, һөнәр, осталык, эш җае, корал

- Акыл күпкә җиткерер, һөнәр күккә җиткерер.
- Башта үзең өйрән, аннан кешене өйрәт.
  Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр.
  Белгән һөнәр иңсәне басмый.
- Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
- Корал эшләр, кул мактаныр.
  Коралда кырык кешенең көче бар.
- Начар останың коралы үтми.
- Оста барда кулың тый, остаз барда телең тый.
  Оста кулда балта да — пәке.
  Осталык — иң зур байлык.
- Үзе эш белмәгән кешене өйрәтергә оста булыр.
- Һәр эшнең дә җае бар, ботканың да мае бар.
  Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.
  Һөнәр иясе бай булмас, бай булмаса да ач булмас.
  Һөнәр — кулдагы алтын беләзек.
  Һөнәр утта янмый, суда батмый торган хәзинә.
  Һөнәрле булу гәүһәрле булудан мең артык.
  Һөнәрле — ком өстеннән көймә йөргезә.
  Һөнәрсез яшәү кәҗә савып гомер итү белән бер.
- Шәкерт булмый оста була алмассың.
  Шәкерт эшне күп бозар, бер көн остадан узар.
- Эшең торса — бер тәңкә, өйрәнүең — мең тәңкә.
  Эшли белмәгән кулга шырпы керер.
  Эшләгәнең атаң илә анаңа, өйрәнгәнең — үзеңә.

* * *

- Белмәгән эше юк, кинәндергән төше юк.
  Боткам пешә май белән, эшем бара җай белән.
- Кеше алдында мин оста, икәү калсак, ул оста*.
- Эшләгән эше юк, тик торган төше юк.
  Эшләмәгән эше юк, рәхмәт дигән кеше юк.
  Эшләмәгән эше юк, җан тындырган төше юк.

### Тырышлык-ялкаулык, уңганлык-юньсезлек

- Авыру бер үләр, иренчәк көн дә үләр.
- Бака лайлы җир эзли, ялкау җайлы җир эзли.
  Булган кешенең көрәге утын кисә.
  Булдыклы кеше таштан икмәк чыгарыр.
- Дөньяда иң кызганыч — эшкә ялкау кеше.
- Иренгән ике эшләгән, һаман эше пешмәгән.
  Иренгәннең йөрәгенә мүк үсәр.
  Иренчәк «иртәгә эшлим» дияр.
  Иренчәк кеше — утырып та арый.
- Кулыннан килмәгән күркә асрарга керешер.
- Матурлык туйда кирәк, эшчәнлек көн дә кирәк.
- Пышлыккан — мич башында кыш чыккан.
- Сигез көн гомергә тугыз көн тырышлык кирәк.
  Сәләтсез сәнәк сындырыр, көчсез көрәк сындырыр.
- Тырышкан ил узар, тырышмаган тузар.

Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
Тырышканның даны чыга, иренгәннең җаны чыга.
Тырышлык — зурлык, ялкаулык — хурлык.
Тырышлыкның иң зур дошманы — ялкаулык.
Тырышның тире чыкканчы ялкауның җаны чыгар.

- Уңган кеше баскан җирендә ут чыгара.
  Уңган кеше кулына туфрак учласа алтын итәр.
  Уңмаганның эте кырын карап йөгерер.
- Фәкыйрьлек ялкау кеше өендә аяк бөкләп утыра.
- Һәр авыруга дәва бар, ялкаулыкка дәва юк.
- Эшкә тырышмаган эш башына менәргә тырышыр.
  Эшлеклене мал басар, эшлексезне йокы басар.
  Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау бәхетне төшендә күрер.
- Юньсез бер көн мамык тазартса, өч көн сакалын тазартыр.
- Ялкау бер эш эшли белә — чалкан ятып мышный белә.
  Ялкау кеше — ярты кеше, уңган кеше — алтын кеше.
  Ялкау киндерәсен ураганчы, тырыш эшен бетерер.
  Ялкау утырып йоклый, ятып эшли.
  Ялкау яткан җирдән әвен сугар.
  Ялкауга кояш та вакытында чыкмый.
  Ялкауга көн дә бәйрәм.
  Ялкауга эш кушсаң, ул сиңа акыл өйрәтер.
  Ялкауга яңгыр иң беренче төшә.
  Ялкауның җиренә бодай чәчсәң, билчән үсә.
  Ярлылык тырыш кешенең тәрәзәсеннән караса да, ишегеннән керә алмас.

* * *

- Былазау* белән этләч* — пар килгәннәр инде.
- Йә уңасың, йә туңасың.
- Тырыштым — таудан аштым.
- Уңганлыгы ялкаулыгы белән генә беленми.
  Уңса да үзе, туңса да үзе.
- Үзе кылалмый, кылган кешене күралмый.
- Һәммә кеше корт тапкан, безнең Әхмәт тик яткан.
- Ялкау тамыры юанайган.
  Ялкауга ял килде.

### Эш һәм ял, йокы. Бәйрәм һәм уеннар

- Ай саен бәйрәм булмас, көн саен туй булмас.
- Бал татлы, балдан бала татлы, баладан йокы татлы.
  Батыр, бирешсә дә, көрәшми мәйданны бирмәс.
  Берәүләргә көн дә бәйрәм, көн дә туй, берәүләргә көн дә сагыш, көн дә уй.
- Ирмәк* куган — бәлагә, хезмәт куган — казнага.
- Йоклаган йокы тапкан, йокламаган елкы тапкан.
  Йокы мәчегә тансык.
  Йокы — ялкауның бәлеше.
  Йокы ястык теләми.
- Казынган казна табар, йоклаган йокы табар.
  Көн дә бәйрәм арт ачар, ел да бәйрәм бит ачар.
  Көн — эшләргә, төн — йокларга.
  Күп уен яхшы булмас, аю кашка булмас.
- Сабан туе — атлыныкы, туй — тунлыныкы.
- Таң йокысын йоклаган — бәхетен йоклаган.
- Уен карын туйдырмас.
  Уенга алданып, туемнан калма.

Уйна да көл, исәплә дә бел.
Уйнавын уйна, эшең турында да уйла.
Уйнарсың — уен кебек, утырырсың — чуен кебек.

- Хезмәт ит тә мактан, уйнап көл дә шатлан.
- Эш беткәч, уйнарга ярый*.
  Эше юк кешегә көн дә бәйрәм.
  Эшләп акча тап, рәхәтләнеп ят.
  Эштән соң — ирмәк, эш бетмәсә — имгәк.

* * *

- Аяк өсте йоклап йөрү.
- Әле бит бу уены, шуннан соң булыр дуены*.
- Безнең урамда да бәйрәм булыр әле.
  Бәйрәмдә ачка үлгән, челләдә катып үлгән.
- Көн дә бәйрәм, көн дә туй, көн дә ширбәт, көн дә куй.
- Олы бәйрәм, кече туй.
- Сезнең илдә көн дә бәйрәм, көн дә туй, безнең илдә көн дә сагыш, көн дә уй.
  Сигез көнгә тугыз бәйрәм.
- Ул йоклаганда хет туй уйна.
- Элеккедәй эшем юк, бәйрәмдәгедәй ашым юк.

### *Юл-сәфәр, транспорт*

#### Юл-күпер, юлчы, йөрү-хәрәкәт, абыну-егылу

- Адашкан кешегә эт өргән тавыш сандугач сайравыннан да ләззәтлерәк тоела.
  Адашканны артындагы белер, ялгышканны янындагы белер.
  Адашмыймын дигән кеше каш белән күз арасында адашыр.
  Алдан аягын киенгән алга чыгар.
  Алтмыш адым атлаганчы алты тапкыр артыңа кара.
  Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр күрешә килер.
  Ат чанада беленер, ир сәфәрдә беленер.
  Атлының юлы бер булса, җәяуленең сукмагы — җиде.
  Аяк арса да таяк армый.
- Барганда мактанма, кайтканда мактан.
  Бер көнлек юлга чыксаң, өч көнлек азыгың булсын.
- Ерак юлга чыкмыйча, атыңның яхшы-яманлыгын белмәссең.
- Җәяүле атлыга юл бирер.
  Җәяүлегә янчык авыр.
- Исән чакта йөреп кал, яхшыларны күреп кал.
- Йөргәнче үрмәләп өйрән.
  Йөри белмәгән юл бозар, сөйли белмәгән сүз бозар.
- Кешенең йөреше нинди — эше дә шундый булыр.
  Күп бәрәкәт — күп хәрәкәт итүдә.
  Күп сикергән  — базга, күп уйлаган — тазга.
  Күп яшәгән ни белгән, күп йөргән — шул белгән.
- Мең чакрымлык юл бер адымнан башлана.
- Өйдәге исәп юлга ярамый.
- Туры юлдан олы юл яхшы.
- Эт өрер, кәрван йөрер.
- Юл азабы — гүр азабы.
  Юл кешесенең юлда булуы яхшы.
  Юлаучыга энә дә йөк.
  Юлга алган икмәк авыр түгел.

Юлда йоклаганда бер күзең ачык булсын.
Юлны яхшы белгән арымас.

* * *

- Әз хәрәкәт, күп бәрәкәт.
- Баскан эзеннән ут чыга.
  Бер басасы җиргә мең баса.
  Беребез путьсез, беребез юлсыз.
  Бу кешенең юлы җир астыннан йөри.
- Җәяүлегә таяк булу.
- Йөз юл, мең хата.
- Йөрү — олау, ашау — пылау.
- Кара җәяүгә калу.
  Ката-бата, елап кайта.
  Килгән юлың тап-такыр.
  Күперне күп үтү.
  Тар юл — тайгак кичү.
  Төн китте, көн китте, тәртә буе җир китте.
- Юлыма күрә йөрешем, үземә күрә өлешем.

## Юл күрсәтүче, юлдаш

- Ат — юлда, кеше юлдашлыкта сынала.
  Ашны сеңгәч макта, юлдашны белгәч макта.
- Бергә-бергә юл кыска.
- Җәяүле атлыга юлдаш түгел.
- Залим белән юлдаш булма.
- Кемнең кем икәнен җиде көнлек юлга чыккач белерсең.
- Сәфәргә чыксаң, әүвәл юлдаш тап.
- Үз башыңны дауга бирсәң дә, юлдашыңны яуга бирмә.
  Үзең юаш булсаң да, юлдашың батыр булсын.
- Юлга чыксаң, юлдашың үзеңнән яхшы булсын.
  Юлда тимерчегә очрасаң, сүзеңне урак-пычактан башларсың.
  Юлда кушылган юлдаш түгел.
  Юлдашың белемле кеше булса, юл кыска булыр.
  Юлдашыңның бер күзе сукыр булса, ике күзеңне йомып тор.
- Яман айгыр өерен яуга алдырыр, яман егет юлдашын дауга калдырыр.
  Яман юлдаш башта ашыңны ашар, аннан башыңны ашар.
  Яман юлдаштан кәкре таяк яхшырак.
  Яхшы белән юлдаш булсаң — эшең бетәр, яман белән юлдаш булсаң — башың бетәр.

## Транспорт чаралары. Ат җигү дирбияләре

- Ал тәгәрмәч кайдан йөрсә, арт тәгәрмәч шуннан йөрер.
  Алтын ияр атка тисә, алтынын ал да утка як.
  Арба борылыштан алда шыгырдый.
  Арба ватылгач, юл күрсәтүче күп булыр.
  Арба дуласа да алашаны уза алмый.
  Арба утынга барырга ярамаса, үзе утынга ярый.
  Арбага утыр, көпчәккә уралма.
  Арбалыга Каргалы* ерак түгел.
  Арбаны дегет тота.
  Арбаны — кыш, ә чананы җәй әзерлиләр.
  Арбаның алды-арты бер эздән барса, атка җиңел була.
  Арбасы ватылгач елаган, аты үлгәч көлгән.
  Арбаңа карап йөк сал, атыңа карап юлга чык.
  Ат тапканчы ияр тап — иярле атка атланыр.

Атка ачу итеп тәртәне сындырмыйлар.
Атка ияр йөк булмас.
Ашыккан арба акрын тәгәри.

- Бер ияргә икәү атланып булмый.
  Биек көймә дулкыннан курыкмас.
  Буш арбаның дыңгыры күп.
  Буяулы ишкәктән чыпта җилкән артык.

- Ватыласы арба кырык көн алдан шыгырдый.

- Дагасының көмешенә мактанма, атыңның йөрешенә мактан.
  Дегет лагунын арбага таксаң хаҗга да бара.
  Дегеткә тамагы туймаса арба да шыңшый.
  Дүрт тәгәрмәч бергә әйләнгәндә генә яхшы.

- Зур корабка — киң диңгез.
  Зур җилкәнне каты җил генә өреп тутыра ала.

- Ике койрыкчы бер көймәне батырыр.
  Ике көймә койрыгын тотып булмый.
  Ир коралы камчыдыр, кулда барда кадере юк.
  Ишә белгән агымга каршы ишкәк салыр.
  Ишә белмәсәң, көймәгә кермә.

- Йөгәнең булмаса, ат алма.
  Йөз тәңкәлек атың булсын, мең тәңкәлек чыбыркың булсын.
  Йөктән төшкән — югалган.

- Каекчы көймәчегә юл бирер.
  Каештан: «Ничә яшькә тикле чыдыйсың?» — дип сорагач: «Минем яшемне майдан сора»,— дигән.
  Какшаган көпчәккә ышанып юлга чыкма.
  Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың.
  Кемнең көймәсендә — шуның көендә.
  Кеше арба белән барганда, син чана белән барма.
  Кеше чанасы белән шуарга яхшы.
  Кешеләрне көймәдә чыгарсаң, ярга җиткәнче чыгар.
  Кыңгырауның эче буш.
  Көймә белән елганы кичеп булса да, туктатып булмый.
  Көймә ишкәнне ярдан карап тору җиңел.
  Көймәдә көймәче белән орышышма.
  Көймәнең ныклыгы давыл чыккач беленә.
  Көймәсенә күрә ишкәге, гөбесенә күрә пешкәге.
  Көймәң киң булганчы, күңелең киң булсын.
  Күчәрдәге көпчәкне тәртәгә такмыйлар.

- Майламаган арба шыгырдый.
  Мең тәңкәлек атны өч тиен тормаган чыбыркы белән кыйныйлар.

- Начар көпчәк күбрәк шыгырдый.

- Олы дулкын күргәч тә ишкәкне кулыңнан ташлама.

- Тәгәрмәч әйләнгәндә күчәренә көч төшә.
  Тәртә дулап ат була алмый.

- Утырган арбаңнан бигрәк көпчәкләрен сакла.

- Чана төбе буш йөрми.
  Чананың, кая китсә дә, эзе билгеле.
  Чыбыркы белән балта сабын сындырып булмый.

- Юкә өзсәң, каеш түләрсең.
  Юкәне нихәтле майласаң да, каеш булмас.

- Яман арба юл бозар.
  Ярдан торып ишәргә өйрәтмә.
  Ярык көймә ярда ятыр.

***Мал-мөлкәт, алыш-биреш***

**Байлык, мал, ярлылык. Бай һәм ярлы**

- Аз малың, күп куанычың булсын.
Азапсыз килгән мал затсыз була.
Акылсыз бай булудан акыллы ярлы булу артык.
Арыклыктан ат үлмәс, ярлылыктан ир үлмәс.
Ач кадерен тук белмәс, ярлы кадерен бай белмәс.

- Бай бай өчен тырышыр, ярлы ярлыга булышыр.
Бай булдым дип кабарма, ярлы булдым дип бөрешмә.
Бай бөлгәнче — кырык ел, ярлы баеганчы — кырык ел.
Бай кешегә каберең якын булмасын.
Бай кешедә нәфес көчле була.
Бай кешенең этәче дә кубыз уйный.
Бай — көндез уттан, төнлә карактан куркыр.
Бай малын сөйләр, ярлы моңын сөйләр.
Бай ярлыга мохтаҗ, ярлы акчага мохтаҗ.
Бай ярлыга моңдаш булмас, бүре куйга юлдаш булмас.
Байга бирәчәгең, ярлыдан алачагың булмасын.
Байга ялынганчы ике кулыңа ялын.
Байлар бал эчкәндә ярлы су эчкән.
Байлар кыек сөйләсә дә туры күренер, ярлы туры сөйләсә дә кыек күренер.
Байларның коймасы биек була.
Байлык зурлык түгел, юклык хурлык түгел.
Байлык кешенең күңелен — ташка, күзен акка әйләндерә.
Байлык морат түгел, ярлылык оят түгел.
Байлык хәзинә җыюда түгел, булганны белеп тотуда.
Байлыкның кадере беткәч беленер.
Байның алты йорты бар, бар булса да өе тар.
Байның бакыр казаныннан үзеңнең чуен казаның яхшырак.
Байның бура төбендә дә бер икмәклек он була.
Байның даны акыл күплеге белән түгел, алтын күплеге белән.
Байның ишек алдын саклаучы этләр үзеннән усалрак була.
Байның малын саный-саный ярлының шәме янып беткән.
Байның эше фәрман белән, юкның эше дәрман белән.
Байның эше, ярлының көче.
Берәүгә — мал кайгы, берәүгә — баш кайгы.
Бушлай килгән мал бушлай китә.
Бөлә башлаган байның эте дә чыгып кача.

- Дәүләт килгәндә җеп белән тартсаң да килә, киткәндә аркан белән дә тотып булмый.
Дөнья байлыгы дөньяда калыр.
Дөнья малы — тозлы су: эчкән саен эчәсене китерә.

- Ерак җирдән кайткан мал кадерле була.

- Җан карендәш булса да, мал карендәш түгел.

- Иске байның бөлгәне, яңа байның көлгәне.

- Кадерен белмәгән байлыктан кадерен белгән ярлылык артык.
Кесәңдә малың булмаса, телеңдә балың булсын.
Кеше байлык өчен түгел, байлык кеше өчен.
Күләгәсе юк таудан биз, файдасы юк байдан биз.

- Мал бөртекләп җыела.
Мал тапканны мактама, тота белгәнне макта.
Мал җыярга — йөз ел, таратырга — ярты көн.
Михнәтсез тапкан мал исәпсез китәр.

- Насыйп мал иясенә кайта.

- Табылдык малга ия күп.

- Үз малыңны әзсенмә, кеше малын күпсенмә.
Үзең тырышып тапмасаң, ата малы — бер айлык.
Үкереп килгән дәүләт кычкырып китәр.

- Фәкыйрьлек гаеп түгел, ялкаулык гаеп.

- Хәрәм малның хәере юк.
Хисаплы мал җуелмас.
- Һәлак булыйм дисәң, йә мал җыйна, йә надан кал.
- Юк кешенең акчасын усал товар бетерер.
- Яман адәмгә мал төшсә, якынын танымас.
Ярлы беләгенә ышаныр.
Ярлы булырга акча кирәкми.
Ярлы кеше акчасы торна булып кычкыра.
Ярлы кеше акчасын яман товар бетерер.
Ярлыда: «Такта чәем, якты чыраем», байда: «Бөртек чәем, төртеп эчерәем».
Ярлылык, оят булмаса да, бәхет түгел.
Ярлының аты булса, печәне булмый, печәне булса, аты булмый.
Ярлының кесәсенә акча ыңгырашып керә, җырлашып чыга, ди.
Ярлының кәҗәсе ялгыз бәти китерер.

* * *

- Ашау-эчү байларча, өстә кием юкарак.
- Бай баесынга түгел, кояш баесынга.
Бай булып күргәнем юк, ярлы булып үлгәнем юк.
Бай узганда бүрек салган, ярлы узганда көлеп калган.
Байлыгыбыз бик көчле: бер көянтә, бер шөшле.
Байлык куәтле, фәкыйрьлек белән генә беленми.
Байлыкка чама юк, җигәргә чана юк.
Бай бөлгәннән кем көлгән.
Безгә куркыныч түгел: бөләсе юк, байыйсы гына бар.
- Кыш ач, җәй ялангач.
- Ни тапты — шуны капты.
- Үзе ярлы, йөзе якты.
- Шайтан ярлы, без бай.
- Ярлы башым — гарьле башым.
Ятыш-торыш байларча, өстә-башта юкарак.

## Бар-юк, барлык-юклык

- Бар булсаң — ашма, юк булсаң — шашма.
Бар вакытта ят яхшы, юк вакытта үз яхшы.
Бар нәрсәнең зыяны булмый.
Бар нәрсәнең кадере юк.
Бар янында бар яхшы, май янында бал яхшы.
Бар өстенә бар сыяр.
Барлык өйрәтә, юклык йөдәтә.
Барлык сөйдерә, юклык көйдерә.
Барлык та өйрәтә, юклык та өйрәтә.
Барлык яраштырыр, юклык талаштырыр.
Барның бары да бар, юкның өе дә тар.
Барына канәгать кыл, югына сабыр ит.
Булган әйбер тамагына сорамый.
- Сусыз җирдә балык тормас, юксыз җирдә дәүләт тормас.
- Хәлле кеше — хәленчә, барлы кеше — барынча.
- Һәр нәрсәнең бар чагында кадере юк.
- Юк бар булмас, киң тар булмас.
Юк дип җиргә кермә, бар дип күккә очма.
Юкка суд та юк.
Юкка төшкәнче утка төш.
Юклык таштан каты.
Юклык өйрәтә, байлык боза.
Юкны юкка кушканнар, тагын юк чыккан.

* * *

 Бар булсаң күрә алмас, юк булсаң бирә алмас.
Бар дигән даны бар, каткан-коткан туны бар.
Барга сөенми, юкка көенми.
Бары бергә, югы уртак.
Барын-югын белмидер, бал телидер күңелем.
Барына шөкер, югына төкер.
Барында — бәйрәм, югында — әйрән.
Югын бар итү, барын бал итү.
Юк шөкергә тук шөкер.

**Акча, алтын, көмеш, бакыр акчалар. Сум, тәңкә, тиен**

 Акча аккош: муенын суза да оча.
Акча бакчада үсми.
Акча бакыр, санарга такыр.
Акча белән җүләр дә байый.
«Акча» дигәнне чукрак та ишетә.
Акча кадере — беткәч беленер.
Акча, кысып тотсаң — үлә, йомшак тотсаң — очып китә.
Акча күргәч күзең тонмасын.
Акча күрсә, фәрештә юлдан таяр.
Акча санаганны ярата.
Акча таш астында, таш аждаһа башы астында.
Акча тиеннән, сарык бәрәннән үсә.
Акчага арыслан сөте дә табып була.
Акчага сат, акчага сатылма.
Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный.
Акчалының эше күп, бакчалының ашы күп.
Акчаны зурлыйм дип үзеңне хурлама.
Акчаны тоту рәхәт, калдыгын санау кыен.
Акчаның күзе юк.
Акчасы барның сүзе уң, акчасы юкның сүзе соң.
Акчасыз торып була, икмәксез торып булмый.
Акчаң булмаса, кесәң ертыклыгыннан ни зыян.
Алтын адәмнең акылын алыр.
Алтын җем итә, табынганны җен итә.
Алтын кечкенә булса да, кадере зур.
Алтын кешене эзләми, кеше алтынны эзли.
Алтын-көмеш күп җирдә фетнә чыга.
Алтын күп булса да ашарга ярамый.
Алтын пычракка төшсә дә бәһасен җуймас.
Алтын үзе черемәсә дә күп башларны черетә.
Алтынның бөтен кадере дә аның аз булуында.
Алтыны барда җүләрне дә акыллы диләр.

 Бер тиен акча белән мунча салып булмый.
Бер тиен кергән баеган, бер тиен чыккан бөлгән.
Бирәү акча таба, бирәү янчык тага.

 Ике тиен чыгармый бер тиен кермәс.
Ишек йөрткән тупсадыр, эшне йөрткән акчадыр.

 Кесәңдә йөз мең булса, әтәчкә атланып очып була.
Кешенең мең тәңкәсеннән үз бер тиенең яхшы.

 Мал колыннан үсә, акча — тиеннән.

 Тамчы-тамчы күл була, тиен-тиен сум була.
Тиген килгән тәңкәдән тир чыгарган тиен артык.

 Үз акчасы булмаган кеше кесәсендәген санар, ди.

 Хәрәм акча кесә тишә.

- Юк акчага янчык текмә.

* * *

- Акча бездә бер букча, ефәк бездә мунчала.
  Акча бездә күп түгел, кирәгенә юк түгел, килә тора, китә тора, кирәгенә җитә тора.
  Акча безне тапмый, без акчаны табабыз.
  Анда акча бетсә, коеда су бетәр.
  Ат башыдай алтын бирсәләр дә кирәкми.
- Бакча җимеше түгел, акча җимеше.
  Бездәге акчаны тавык та чүпләп бетермәс.
  Бер акчага йорт та ала, сыер да ала, дөягә дә күз сала.
  Бер тиен өчен җан сата.
- Иске бер тиен кебек ялтырау.
- Күзеңә кырып салырга сукыр бер тиен дә юк.
- Сиңа биргән акчаны багор белән су төбеннән эзләргә.

**Базар, товар, бәя, санау. Исәп-хисап, үлчәү**

- Акчасыз базарга барганчы, кәфенсез гүргә кер.
  Аласы әйбер алтын булып күренер.
  Алтыга алып бишкә сат, атың булсын сәүдәгәр.
  Арзан зарарсыз булмас, кыйммәт файдасыз булмас.
  Арзанның буявы тиз уңа.
  Асыл товар зур булмас.
- Базар акчаны ярата.
  Базар юлына үлән үсмәс.
  Базарда атаң белән анаң гына юк.
  Базарда ике тиле: берсе — сатучы, берсе — алучы.
  Башта кесәңне кара, аннан сатулаш.
  Бер кеше килмәгәннән базар тукталмый.
  Бәясе арзан дип кирәкмәгән әйбер алма.
- Гаделлек белән сәүдә ит, җитезлек белән файда ит.
- Зарар күрмичә файда күреп булмый.
- Иртәнге сәүдә — сәүдә, кичке сәүдә — гауга.
  Ит күрсәтеп үпкә сатып булмый.
  Итек кисәң — кунычы кала, сату итсәң — бурычы кала.
- Кәҗә талга туймас, сәүдәгәр малга туймас.
  Кирәкмәгәнне алсаң, кирәгеңне сатарсың.
  Кирәкнең кыйммәте юк.
  Куркып сәүдә иткән файда итмәс.
- Малны алганда ялгыз да алып була, сатканда әти белән дә сатып булмый.
  Малыңның бәһасен белмәсәң, базарга чыгарма.
- Нәрсә күп булса, бәясе төшәр.
- Очсызның арты тынычсыз.
- Сату-алу эшенә алдау кермичә калмый, ди.
  Син уйлыйсың алтыга, ул каладыр яртыга.
  Спекулянт битенә иске ыштыр каплаган.
  Сәүдәдә йә эшең әйләнә, йә башың әйләнә.
- Товарны күрсәткәч мактыйлар.
  Түләүсез малның кадере булмый.
- Файда белән зарар бер арбада йөри.
- Хаклы нәрсә — затлы нәрсә.
  Хакны базар әйтә.
  Хисабын хак йөрткәннең йөзе ак.
- Эшең беткәч, базарда торма.
- Яхшы товар арзан булмый, арзан товар яхшы булмый.

* * *

- Алдым тире, саттым кире.
  Алдым файда итәргә, белмим кайда итәргә.
  Аның базары төште.
  Артыкны сату түгел, актыкны сату.
- Базар бай, кесә ягы ай-вай.
  Базарга барганда мин баймын, акчам санасам — гидаймын.
  Бишкә алып бергә сату.
- Дарым-шарым, тәңкә ярым.
- Итәк астыннан сата.
- Кавынны бушлай биргәч алмаган, кабакны акча түләп алган.
  Күпмегә алсам, шуңа сатам.
- Менә сиңа мал — үзең сайлап ал.
- Он сатсам  — җил чыга, тоз сатсам — яңгыр ява.
- Потың бер тиен.
- Унны тугызга алмаштырып йөрү.
- Үз аршының белән үлчәмә.
- Хак ярым хак, пот ярым борчак.

**Алу-бирү, әҗәт, бурыч, бүлү-өләшү, бүләк**

- Авыруың булса булсын, бурычың булмасын.
  Ала белсәң, бирә дә бел.
  Алачак яфрактан күп булса, бирәчәк туфрактан күп.
  Алган — аз, биргән — күп.
  Алган чакта карчыга, биргән чакта җан чыга.
  Алмак күрке — бирмәк.
- Әҗәт кайчысы дуслык җебен кисәр.
  Әҗәт көлеп килә, елап китә, ди.
  Әйрән сорап килгәнсең, чиләгеңне яшермә.
- Берәүгә бурычлы булсаң, аның колы булырсың.
  Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган.
  Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз.
  Бирсәң алырсың, иксәң урырсың.
  Бирәсе бар онытыр, аласы бар онытмас.
  Бурыч ашаганчы борыч аша.
  Бурычка алган — бөлгән, бурычка биргән — баеган.
  Бүләк атның тешенә карамыйлар.
  Бүләк биргән бүләк көтә.
  Бүләкнең кечкенәсе булмый.
  Кеше биргән бүләкне кешегә бүләк итмә.
  Кулың белән бирсәң, аягың белән йөреп алырсың.
- «Мә» дигәндә алмасаң, соңыннан «бир» дияргә туры килә.
- Өлешеңә чыккан көмешең.
  Өләшү белән бүлешү бер түгел.
- Төя дә бүләк, төймә дә бүләк.
- Үз өлешеңне ташлап кеше көмешенә үрелмә.
  Үрдәк биргән каз көтәр.
  Үтечкә алынган атка менгән тиз төшәр.
- Энәсе үткәннең җебе үтәр, бүләге үткәннең сүзе үтәр.

* * *

- Алачагым да юк, бирәчәгем дә юк.
  Алачагына — лачын, бирәчәгенә — карга.
  Алганда баш ия, алгач артын әйләнә.

Алты алышым юк, биш бирешем юк.

- Бер кулы белән бирә, икенчесе белән ала.
  «Бир» дигәнне ишетмәс, «мә» дигәнне ишетер.
  Бирдем борай, килдем сорай.
  Бирсәң биреп ашый, бирмәсәң тартып ашый.
  Бурычым юк — борчуым юк.
- Үзе бирә алмый, биргәнне күрә алмый.

### ***Өй-йорт, каралты***

### **Өй һәм аның кисәкләре**

- Ай-һай минем үз өем, киң сараем, бүз өем*.
  Ачык ишекне ватып кермиләр.
- Бай булмасаң, бай түшәрлек өең булсын.
  Бердәм өйдә бәрәкәт бар, бердәмсез өйдә һәлакәт бар.
  Берәү, патша йортын күреп кайткач, үз өенә ут төрткән, ди.
  Булмас йортка бөкере.
  Бурасына күрә түбәсе.
- Гүрдә ятканчы түрдә ят.
- Заманасына күрә өе, өенә күрә көе.
- Ике хуҗалы өйдә чүп тездән булыр.
  Ишек ачык булса да, сорап кер.
  Ишек барда тәрәзәдән йөрмә.
  Иясез йорт мисез баш кебек.
- Йорт хуҗалыгы чабата ясау түгел.
- Кайтып керер ишегеңне каты ябма.
  Кемнең өендә, шуның көендә.
- Олы йортка ни кирәк, кече йортка шул кирәк.
- Сусыз җиргә өй салма.
- Тирә-ягың яу булсын, йортың эче сау булсын.
  Туган өйгә тугыз кил.
  Түгәрәк өйнең түре юк.
  Түр кемнеке булса, мендәр шуныкы.
- Читкә китәсең килсә, йортыңны-җиреңне торгызып кит.
- Яңа өй салмыйча, искесен сүтмә.
- Өе барның көе бар, көе барның өе бар.
  Өен яхшы өймәгәннең өе башына ишелер.
  Өендә рәхәт тапмаган урамда тапмас.
  Өй корган уңар, өйсез кеше туңар.
  Өй салмыйча мал булмый.
  Өй салуның ние бар: өйдең — өй, кактың — чөй.
  Өйдә утырып шәһәр алып булмый.
  Өйдәге тавышны тышка чыгарма.
  Өйне сала башлаганчы нигезен ныгыт.
- Үз куышың — җан тынычың.
  Үз түреңдә үзең түрә.
  Үз өеңдә үз булмасаң, үзгә җирдә үз булмассың.
- Һәр өйнең үз гадәте бар.

* * *

- Ачмаган ишеге юк, кермәгән тишеге юк.
  Ачык ишек, якты чырай.
- Исән бул, иске өеңә түшәм бул, яңа өеңә матча бул, тараканга патша бул.
  Ишегенең кайсы якка ачылганын белмәү.
  Ишек кискән, тәрәзә тишкән.

Ишеккә сыймыйсыңмы, керергә кыймыйсыңмы?

- Йортым читән булса да, сортым бүтән.
- Салкын өй, салам түшәк.
- Түбә тактасы санап яту.
- Уз түрдән, утыр түбән.
- Өе биек, өйрәсе сыек.
  Өем читтә, ишегем чыпта.
  Өй почмагына ут капса да кайгырмый.
- Үзенә өй кормаган, илгә шәһәр корырга тотынган.

## Өй җиһазлары. Урын-җир. Чүп-себерке

- Бер чыраның яктысына кырык кеше утыра.
  Бер өйнең лампасы икенчегә яктыртмый.
- Идәндәге чүп түргә чыгар.
- Кечкенә карават та дүрт аяклы була.
  Кырын-кырын ятсаң, кырык кеше бер сәкегә сыя.
  Көндез чыра яндырган кичен караңгыда утырыр.
- Мамыгын бушаткач, юрганым бар дип хыялланма.
- Түшәге бар түшәнер, икмәге бар күшәнер.
- Юрганыңа карап аягыңны суз.
- Янмаган чыраның яктысына туймассың.
  Яткач — урын алама, торгач— кием алама.
- Өе барның көе бар, киеме барның чөе бар.
- Үзең торасы җирне үзең себер.

* * *

- Йомшак җәеп катыга яткыра.
- Өйдә идән себерә белмәгән илдә түшәм себергән.
- Утыр урыннан — сәке түреннән.
- Үзе ятып йоклаган, сәке башы кортлаган.
- Ястыгым — җир, юрганым — күк.

## Мич-учак, ут-төтен, утын Яну

- Агач, кәкре булса да, туры янар.
- Бер агач мичтә дә янмас, ике агач далада да сүнмәс.
  Биттә ут янмый, мичтә ут яна.
  Былтыр көйгән, быел исе чыккан.
- Ирекле баштан утка кермиләр.
- Карак керсә стеналар кала, уттан берни калмый.
  Кемнең итәгенә ут төшсә, шул яна.
  Кисәү агачың озын булса, кулың пешми.
  Коры утын белән чи утын да яна.
  Корымнан корым йогар.
  Кыскыч барда утка бармагың тыкма.
- Мич янмаса, морҗадан төтен чыкмый.
  Мичкә ут керде — өйгә кот керде.
  Мичнең кадере кыш җиткәч.
- Олы утынның уты күп.
  Очкын төшкән җирен ягар.
- Тиз янган тиз сүнгән.
  Төтене куе чыкканның шурпасы да куе була.
  Төтәмәгән морҗа булмас.

- Ут белән дары бергә уйнамас.
  Ут дигәннән авыз көймәс.
  Ут чыкканда җил астына качма.
  Утка кем «пөф» дисә, шуның сакалы көяр.
  Утны итәк белән илтә алмассың.
  Утны күргәч, мамыктан төтен чыга.
  Утның тышында көйгәнче, эчендә көй.
  Уттан курыккан төтеннән сакланыр.
  Уты сүнсә дә кисәве кала.
- Янгын сүндерергә таза су эзләмиләр.
  Янгыннан соң су күп булыр.
  Яхшы морҗадан ут чыкмый.
  Яшь агачтан коры агач тизрәк кабына.

* * *

- Авызыннан ут чәчә.
  Аның морҗасы төтен кайтармый.
  Артына ут капса да кыймылдый торган түгел.
  Астан ут җибәреп яту.
- Ике ут белән уйнау.
- Карама көленә утыру*.
  Көлеңне күккә очырырмын.
- Мичен яккан, үзе яткан.
- Төтене күп, ялкыны аз.
- Ул нәкъ усак утыны кебек: төтене күп, җылысы юк.
  Утка керосин сибү.
  Уты сүнгән, әйрәне түнгән.

## Каралты-кура

- Абзар зур булса, бура була; өй зур булса, кура була.
  Актыктан кем керә, капканы шул ябар.
  Ачык капкадан ат та керә.
- Бер йортка ике бикәнең тавыгы сыймас.
- Җил капка җилгә дә ачыла.
  Җил капкада җил тормый.
- Ишек алдыннан дау килгәнче өй артыннан яу килсен.
- Казык какмаган кеше казыкны үзе үсеп чыккан дип уйлый.
  Какма кеше капкасын, кагарлар үз капкаңны.
  Каралты салудан элек түбәсен хәзерлә.
  Кеше капкасын ачып керсәң, ябып та чыга бел.
  Кунаклау өчен элек колга корырга кирәк.
  Куш казыксыз читән дә булмый.
- Мунча кергән тирләми чыкмас.
- Терәү булмаса, багана да тормый.
- Черек баскычтан менмә — түнәрсең, черек басмага басма —батарсың.

* * *

- Дүрт казык каккан, күк белән япкан.
- Икесе дә бер багана төбен таптый.
  Иске мунча, иске таз.
- Казык башына утырту.
  Каккан казыгы да юк.
  Капкасыннан эт бакмый, төнлегеннән җил какмый.
- Чыксам абзар, керсәм өй.
- Яксам мунчам, чыксам бакчам.

## *Кием-салым*

### Эрләү-сугу, тукымалар, тегү-чигү, энә-җеп

- Асыл азмас, атлас тузмас.
  Атлас тун базарында кыйммәт үтәр.
- Бик каты сузсаң, җеп тә өзелә.
- Ефәкне утка якын куярга ярамый.
- Җеп нечкә җирдән өзелер.
  Җиде кат үлчә, бер кат кис.
- Инәсез торып була, энәсез торып булмый.
- Йомгакның очы була.
- Кабасы кайда, орчыгы шунда.
  Капчык тузса югыч була, ефәк тузса югычка да ярамый.
  Кешегә карап кием кисмиләр.
  Киез җәйгән — бер почмагына үзе утырыр.
  Кулың белән тукыганны инең белән күтәрерсең.
  Кыска җеп, урауга җитсә дә, бәйләүгә җитмәс.
- Начар постауга йон иярә.
- Тегүченең туны ертык, балтачының өе тишек.
  Төен бер кул белән бәйләнми дә, бер кул белән чишелми дә.
- Холыксыз кешегә кием теккәндә җеп очы чуалыр, ди.
- Энә, кечкенә булса да, нык чәнчә.
  Энә үзе ялангач — бөтен дөньяны киендерә.
  Энәне очлы ягы белән бирмиләр.

* * *

- Алтылы да бишле, бездә киндер ишле.
- Ике энә бер җептә, ике имән бер төптә.
- Йомгакның очын югалту.
- Көтәсенә җон тетәм.
- Тышлык биргәч, эчлеген сорый.
- Энә белән җеп кебек.
  Энә төртерлек тә урын калмау.
  Эрләмәгән-сукмаган, Шаһи сиңа ыштанлык.

### Кием, киенү-бизәнү, көязләнү, пакьләнү

- Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк.
  Алка, нихәтле кыйммәт булса да, колак бәясе тормый.
  Ашаган күренми, кигән күренә.
- Балдакны атсыз бармак кия.
  Бик бизәнгән — биздергән.
- Йөзеге барда Сөләйман, йөзеге юкта сөмәйгән*.
  Йөзек кашы зур булмый.
- Керне юган саен кере чыга.
  Кием кемнеке булса, кесәсендәге нәрсә дә аныкы.
  Киемгә хезмәт итмә, кием сиңа хезмәт итсен.
  Киеме яманны эт кабар.
  Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар.
  Киемне кешесенә карап кисәләр.
  Киендерсәң, киндер таягы да кияү була.
- Өс — нур, тамак гүр.
- Пакь кием кадер арттырыр.

- Сабын, сары булса да, ак юа.
- Туй үткәч кына якмыйлар.
- Хәтта яхшы күзге дә әйбернең артын күрсәтми.
- Чулпы чылтыравы — мәхәббәт тавышы.
- Ыспай туңмас — калтырар, борын асты ялтырар.
- Ялангач билгә — каеш бау.
  Ялангачка өч учак та бер киемне алыштыра алмый.
  Яман кием яшь кызны әбидәй, әбине пәридәй итәр.

* * *

- Беләзегең алтын, йөрәгең салкын.
- Йөзек үтә тарткан*.
- Күп юынсаң, карын мае дип, карга күтәреп китмәсен.
- Сабын куыгы очыру.
- Өсте комач, тамагы ач.

## Яңа һәм иске кием. Ертык-тишек, ямау

- Берәүнең яңасыннан үзеңнең искең яхшы.
- Ертык зурайса, ямаулык җитмәс.
  Ертык киемнең ямарлыгы калмаса, үзе ямауга китәр.
  Ертык сүтектән күләр, тишек икесеннән дә көләр.
- Иске кием ямаусыз булмас.
- Тишек түгел җиргә ямау салмыйлар.
- Ямавы табылмас киемне кимә.
  Ямауга калса, яманга калыр.
  Яңа кием булды дип, искене хур күрмә.

* * *

- Астан кисеп, өстән ямый.
- Кырык корама, йөз ялгау.
- Ямый белмәсә дә, ерта белә.

## Өске киемнәр

- Бакасыз күл булмас, якасыз тун булмас.
  Берәүләрнең ике тун, берәүләрнең ите тун.
  Беткә ачу итеп тунны утка якма.
  Бишмәт кигән бишне белсә, тун кигән тугызны белер.
- Киндер күлмәккә туйган ялангач түгел.
  Киң кискән тун тузмый.
  Кырык кат чабадан* бер кыптыр тун* артык.
  Күлмәксезгә чуклы бау килешми.
- Тун кидергәч, түмгәк тә туй кодасы булыр.
  Тун матурлыкка түгел, җылылыкка.
  Тун югында чикмән дә җылыта.
  Тышта туңган өйдә толып салмый утырыр.
- Үз күлмәгең үз тәнеңә якын.
- Чыптадан чикмән тегә алмассың.
- Ябынча кадере яңгырда беленер.

* * *

- Астан толып, өстән тун.
- Башка — ыштан, аякка — бүрек.
  Беткә ачу итеп тунын утка яккан.

Бишмәтенең җиңе юк, ыштанының төбе юк.

- Җитмәсенә җиң булдым, булмасына буй булдым.
  Җиңе озын, итәге кыска.
- Иске чалбарга яңа бөрмә.
  Итәк астыннан ут йөртү.
  Итәк кисеп, җиң ялгау.
- Кесәдән йодрык күрсәтү.
  Күлмәк эчендә туган*.
- Туңамын туным юкка, өшимен эшем юкка.
  Төймәдән дөя ясау.

**Баш киемнәре**

- Баш күпме үссә дә, бүрек өстен.
  Башыңны бүрекле йөрт, бүрекне күрекле йөрт.
  Бүрекнең күрке тунның гаебен каплый.
  Бүркенә карама, бүрек астын кара.
- Калфакны кантарда киеп булмый.
  Кызыл яулык кызга килешә.
- Пальто белән чалма килешми.
- Тазның гаебен бүреге каплый.

* * *

- Бүреге башыннан акыллырак.
  Бүрек белән киңәшү.
- Түбәтәй җыеп калу*.

**Аяк киемнәре. Оек-бияләй**

- Аягында итеге барга бөтен җир өсте күн.
  Аягыңдагы итегең тар булса, дөньяның киңлегендә ни файда.
- Башмак алтыннан булса да, аты һаман башмак булыр.
  Бер ташлаган чабатаны яңадан кимиләр.
- Ике аяк бер кәвешкә сыймас.
  Итеге яман түргә чыга алмый, җиңе яман аш эчә алмый.
  Итек кидем дип, чабатаны чыгарып ташлама.
- Күрми күргән күн итеген башына кигән.
- Оегыңны карап ки: эчендә чаян ятмасын.
- Чабатаны кайтаруын гына кайтар, тезүен кем дә тезәр.
  Чабатасына күрә киндерәсе.
  Читегедер өч тәңкә, чигешедер биш тәңкә.
- Шөшле сораганга балта тоттырмыйлар.
- Ялангач аякка һәр башмак таман.

* * *

- Бер аягында ката, икенчесендә чабата.
  Бияләй эченнән йодрык күрсәтү.
- Иске чабатага яңа киндерә үргән*.
- Кырык ел чабата ясап, чабатага олтан сала белмәгән.
  Көн уздырып, чабата туздырып.

***Азык-төлек, аш-су, савыт-саба. Кунак-сый***

**Азык, ризык, аш-су төрләре**

- Авыз күнгән ачы катык күнмәгән каймактан яхшырак.

Аз ашның хәсрәте дә аз.
Азыгы мул хуҗаның кышы кыска булыр.
Алмасаң да — чәй яхшы, ашамасаң да — май яхшы.
Арык иттән симез котлет пешереп булмый.
Арыш икмәге һәрнәрсәгә баш.
Ачы белән төзәтәләр, тәмле белән бозалар.
Аш артыннан — чәй шартыннан.
Аш бар өйдә бәрәкәт бар.
Аш белән атканга таш белән атма.
Ашасаң ботка, китәрсең ходка.
«Аш» дигәндә аттан төш*.
Ашсыз өйне эт тә яратмый.
Ашыңа ни салсаң, кашыгыңа шул чыгар.

Бавырга буе җитмәгән: «Мин бүген ураза»,— дияр.
Бал — ару, җитмеш төрле сырхауга дару.
Бал балчык ашатыр, балан камыр ашатыр.
Бал капкан авыз япкан, ачыккан авыз ачкан.
Бал сөрткәч пычакны да ялыйлар.
Бал татлы дип бармак йотып булмый.
Баллы кеше — маллы кеше, сыерлы кеше — сыйлы кеше.
Балы булса чебене булыр.
Бер кискән икмәк ябышмас.
Бер чынаяк чәйнең кырык ел хәтере бар.
Бер җәем токмач белән туй үтми.
Борыч, ачы булса да, ашның тәменә дару.
Ботка пешерсәң, маең җитәрлек булсын.
Бәлеш булса, белеш була.

Дөньяда таш каты, ташны эреткән аш каты.

Икмәк корсак артыннан йөрми, корсак икмәк артыннан йөри.
Икмәк югы ямандыр, каты-коты кимертер.
Иписез, тозсыз аш — ярты аш.
Иске серкә савытны боза.
Ит ашадың — дәрт алдың, шулпа ашадың — шифа алдың.
Ит ашасаң, тешкә керә, ашамасаң — төшкә керә.
Ит күрсәтеп, үпкә сатып булмый.
Ит сөяксез булмый.
Ит тапмаган үпкәгә кинәнгән.
Ит үзеннән-үзе кортлый.

Кайда коймак, шунда кунак.
Кар ак булса да, аны ашап булмый; ипи кара булса да, ансыз яшәп булмый.
Кеше ашы тәмле була.
Кеше икмәге белән мәңге торып булмый.
Кымыз барда кызык бар.
Көн саен майлы ботка булмый.
Күңел тапмак бер калҗа, күңел калмак бер калҗа.

Май ботканы бозмас.
Майламый пәрәмәч пешми.
Майсыз коймак табага ябыша.

Озак кайнаган аш тәмле була.

Пешкән аш — беткән аш.

Сагыз чәйнәп май чыкмас.
Серкә үзен бал санар.
Сөттән ак бул, судан пакь бул.

Тавышлы табыннан фәрештә качар.
Татлы — тешкә дошман, ачы — ашказанына дус.
Тату аш татлы булыр.
Тоз сипкәч, торма да төчерә.
Тәмлене яратсаң, ачысын да ярат.

Төкерсәң ашыңа, ут чыгар каршыңа.

- Үз өендә өйрә пешерә белмәгән — кеше өендә ботка пешерер.
  Үпкәне күпме кайнатсаң да, өресе чыкмас.
- Чәе булса, шикәре табылыр.
  Чәеңне сал учлап, эчәрсең тынычлап.
  Чәй эчеп беткәч, шикәр китермиләр.
- Шикәр, тәмле булса да, икмәкне алыштыра алмый.
- Язмаган ризык авыздан кире төшәр.
  Ярма суда — алтыга, сөттә уникегә ярыла*.
  Яхшы аш начар кашыкны да алтын итә.

* * *

- Авыз эчендә ботка пешерү.
  Авызында ашы, күзендә яше.
  Аз гына ашым, гаугасыз башым.
  Алдында пылавы, йөрергә олавы.
  Аннан он суы да, тоз суы да юк.
  Астан өйрә, өстән ботка.
  Ачык чырай — кайнар чәй.
  Аш пешерсә — апара, бите-кулы кап-кара.
  Ашым аш, суым су түгел.
- Бездә күп каты-коты, сездә ул да такы-токы.
  Бер карасаң үрәле, икенче карасаң шүрәле.
  Бер кулында аш, бер кулында таш.
  Борынына борыч кермәгән.
  Бәлеш — эче дөге, тышы арыш.
- Ипи салган көнне ачтан үлгән.
- Майлап ташласаң эт ашамас.
  Минем күңелем Микидә, Мики күңеле ипидә.
- Серкәсе су күтәрми.
  Су сорасаң сөт бирә торган кеше.
- Умач сораганга токмач тоттырган.
- Эч шурпасын, ник куркасың.

## Ашау-эчү, ачлык-туклык

- Авызыңа кергәнне чәйнәргә иренмә.
  Аз аша — асыл яшә.
  Аз ашаган май ашар, күп ашаган лай ашар.
  Ач карынга вәгазь сөйләмә.
  Ач кешегә аш кирәк, тук кешегә баш кирәк.
  Ач кешегә чәчәк исеннән чәлпәк* исе тәмлерәк.
  Ач кешенең ачуы яман.
  Ачка бар аш та тәмле.
  Ачка казан астырма, туңганга ут яктырма.
  Ачка үлгәннең куеныннан ипи эзләмә.
  Ачлык ни җидермәс, туклык ни дидермәс.
  Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә.
  Ачыксаң да чама белән аша.
  Аш янында күп сөйләсәң, ач калырсың.
  Ашаган белмәс, тураган белер.
  Ашаганнан үлмәссең, күп яхшылык та күрмәссең.
  Ашамыйм дигән алтмыш коймак ашаган.
  Ашап туймаганны ялап туймассың.
  Ашар өчен яшәмә, яшәр өчен аша.
- Бер авызыңа ике кашык тыга алмассың.
  Берәү туеп сикерә, берәү туңып сикерә.

- Җот* кешегә кот купмас.
- Иртәнге ашны ташлама, кичке ашны башлама.
- Карыны ач казанга карар.
  Кешегә барып казы* ашаганчы, өеңә барып су эч.
  Комагайга* кара боламык та аш.
  Комагайга кое суы да җитмәс.
  Комсызга коймак артыннан ипи кис.
  Күктәге фәрештәләр генә ашамый торалар.
  Күп ашасаң, бал да ачы була.
- Ни пешерсәң, шуны ашарсың.
- Сигез капма, симез кап.
  Суга ман, сынык аша — үзеңнеке булсын.
  Суны өреп эчсәң дә, шулпа булмас.
  Сусагач кына кое казырга керешмиләр.
- Талымсызга салма тия, талымлыга талма* тия.
  Тамак булмаса, тәмуг булмас иде.
  Тамаксауның үлеме — тамактан, угрыныкы — таяктан.
  Тар табында чәй эчкәнче, киң табында су эч.
  Туктан токмач кистермә, ачтан салма өздермә.
  Түтәнәгә* алма — шалкан, ком — талкан, чыпчык тизәге —канәфер.
  Түтәнәгә булса —бохари, булмаса — сохари.
- Чәйнәгән синеке түгел, йоткан синеке.
- Ятыр корсак ятыр, ярты әпәйне тартыр.

* * *

- Ач карынга ачы суган.
  Ач тамагым, тыныч колагым.
  Ачка өйрәнеп тә беткән, үлеп тә киткән.
  Ашау-эчү байларча, өстә кием юкарак.
- Ике кабып бер йоту.
- Туймас тамак, үлмәс җан.
- Шулай итеп, чат май итеп, суга манып ашадык.

### Аракы эчү, тәмәке Тарту

- Аек яшәгәннең акылы төгәл.
  Аракы авызга черки булып керә, аждаһа булып чыга.
  Аракы аш булмас, бавырга таш булыр.
  Аракы стаканында батучылар диңгездә батучылардан күбрәк.
  Аракыга сәлам бирсәң, акылың белән саубуллаш.
- Берәүләр кайгыдан саргая, берәүләр — тәмәкедән.
- Исергәнне төртәсе юк — үзе авар.
  Исерек кеше белән мәҗлестә утырганчы айнык кеше белән чучка көткәнең артык.
  Исереккә диңгез тубыктан.
  Исерткеч яман түгел, исерү яман.
- Тәмәке белән бергә тартучы да яна.
  Тәмәке теләнергә өйрәтер.
  Төбенә кадәр чөмергән мәхрүм калган гомердән.
- Челемченең эче дә яна, кесәсе дә яна.
- Шайтан үзе керә алмаган җиргә аракысын җибәрә, ди.
- Эчәрсең йөзем суын*, түгәрсең йөзең суын.

* * *

- Бер тиенлек эчеп, биш тиенлек исергән.
- Кистем кискә, аракысы бер мичкә.
- Төнлә исерек, көндез мәлҗерек.

 Эчтем шәраб, булдым харап.

### Савыт-саба

 Аш пешкәндә — кашык, сусаганда чүмеч кыйммәт.
Ашаган табагыңа төкермә.
Ашы бар, савыты юк; аты бар, камыты юк.
Ашына күрә табагы, балына күрә калагы.

 Бер казанда аш белән ботка бергә пешми.
Ботка барда кашык юк, кашык барда ботка юк.
Буш мичкәнең тавышы шәп булса да, файдасы юк.

 Ватык чүлмәк эшкә ярамый.

 Иләк белән су ташып булмый.
Иләк чүлпыга*: «Синең тишегең тугыз»,— дигән.
Иске казан ашны тәмлерәк пешерә.

 Казан, кара булса да, барын да туйдыра.
Казан соскан берәү, кашык тоткан җидәү.
Казанга салмаганны кашык белән эзләмә.
Казандагы хәлләрне чүмеч яхшы белә.

 Кече казанның өресе әйбәт була.
Килегә салып су төймиләр.
Коры кашык авыз ерта, баллы кашык авыз ера.
Көянтә суга бара, җилкәгә суга бара.

 Май чүлмәге тышыннан билгеле.

 Олы казанда кайнаган чи калмый.

 Өйдә табак-савыт күп булса, абыстае макталыр.

 Пычагы бар сөйгәнен җияр, пычагы юк тигәнен җияр.
Пычак, ни хәтле үткен булса да, үз сабын үзе юнмый.

 Савыт-саба шалтыраса*, өйгә тәртип кирә.

 Таба майлаган саен шомара.
Табак-савыт шалтырамый тормый.
Такта чиләкне такта капкач белән каплыйлар.
Төбе күренмәгән чиләктән су эчмә.

 Чатнаган чынаяк чиртеп карауга билгеле.
Чиләгенә күрә капкачы, капкасына күрә тактасы.
Чуманның, төбе тузса да, кысасы кала.
Чүлмәкне ватмастан элек сакла.
Чүлмәкче ун көн ясаганны таяк бер сугуда көл итә.

 Югалган пычакның сабы алтын.

 Ябулы казанның ташуы яман.
Яңа чиләкнең суы салкын була, ди.

* * *

 Асулы казан, ягулы ут.

 Бер кашык су белән йотарлык.
Бер табактан ашый торган кешеләр.

 Ике яклы пычак.

 Кайнар табага бастыру.
Капчык төбен селкү*.
Кеше өендә май чүлмәге, үз өендә чүп чүлмәге.

 Мин тартам табакка, ул китә тагаракка.

 Төпсез чуманга утырту.

### Кунак-сый

 Ай да кунак бит ача, көн дә кунак арт ача.

Алдан килгән урын өчен, арттан килгән тамак өчен.
Ашка килсәң элек кил, үз кадереңне белеп кил.
Ашның бәрәкәте кунак белән.
Ашыңнан бигрәк кашың булсын*.

- Бер көн сыйлаганга кырык көн сәлам.

- Казан кайный алты ай, кунак көтә җиде ай.
Каршы алу, озатып калу — кунакның бер хөрмәте.
Китәм дигәч самовар куймыйлар.
Кунак аз утырыр, күп сынар.
Кунак беренче көнне алтын, икенче көнне көмеш, өченче көнне бакыр, аннан ары юлы такыр.
Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач.
Кунак кадерле булса, казан тиз кайный.
Кунак килмәгән йортка игелек тә күз салмый.
Кунак килсә ит пешә, ит пешмәсә бит пешә.
Кунак килсә — таптырыр, ат урынына чаптырыр.
Кунак туймаса да рәхмәт әйтер.
Кунакка барсаң, ач та барма, тук та барма.
Кунакка барсаң, сәгатькә карама: кайтыр вакытны хуҗаның чырае күрсәтер.
Кунакның күңелен килгәндә бер тап, киткәндә бер тап.
Көтеп алган кунак кадерле була.

- Мактап йөргән кунак аш алдыннан килә.

- Сыйларга сыең булмаса, сыйпарга телең булсын.
Сөмсез кунак килә белер, китә белмәс.

- Табын җәелмәсә бер гаеп, җәелсә — ун гаеп.
Тешсез кунакка куырган борчак.

- Хуҗа күңелсез булса, кунак өйгә сыймас.

- Чакырган җиргә бар, куган җирдән кайт.
Чакырып килгәннең аты зур, сөеп килгәннең хакы зур.
Чырай сытып аш биргәнче елмаеп агу бир.
Чәй чынаягы өч булыр, өчтән ары хуҗага көч булыр.

* * *

- Алдыңа табак куйдым, кулыңа пычак бирдем.

- Килгәндә киткәли йөр.
Килсәм кунак, китсәм ерак.
Кунакка дигәч әзер тора, уракка дигәч кулы чулак.

- Рәхмәт сыйга-хөрмәткә, кич килермен калган үрдәккә.

- Сыйлаганда мактар, сыең беткәч таптар.

- Уз түрдән, утыр җирдән, ал кашык, аша балчык.
Утыр, кунагым, алты ай; кайна, самоварым, җиде ай.

- Үзе кунак чакырган, үзе баланга киткән.

- Чакырып сыйлап булмады, тотып кыйнап булмады.

### ***Рухи сыйфатлар, холык-гадәт, әдәп-әхлак***

### **Чын кеше булу, әдәп, оят, намус, дәрәҗә, җан, йөрәк, күңел, дәрт-дәрман, батырлык-куркаклык**

- Абруй — ирнең куәте.
Ак күңелленең аты армас, туны тузмас.
Акчаң булмаса да, вөҗданың булсын.
Алтын җирдә ятмас, яхшы исем илдә ятмас.
Ат айда сыналыр, адәм елда сыналыр.
Ат үләр — ияре калыр, адәм үләр — даны калыр.
Аю өнендә көчле, куркак — өендә көчле.
Адәмне адәм иткән — әдәп.
Адәмнән олы ат юк, ипидән олы аш юк.

- Әдәпле кеше солтан, әдәпсезнең бите олтан.
  Әҗәле җиткән бер үләр, абруе киткән көн дә үләр.
  Әрсез кеше сумала булып сыланыр.
- Байлык белән торылмый, холык белән торыла.
  Батыр бер үләр, куркак мең үләр.
  Батыр булсаң — йөрәктән, көчле булсаң — беләктән.
  Батыр куркак булудан курка.
  Батыр туса — ил бәхете, яңгыр яуса — җир бәхете.
  Батырлыкта матурлык.
  Бозылган илне батырлар төзәтер.
- Вөҗданы пакь — йөзе ак.
- Гайрәт иткән — таулар тишкән.
- Данықны җуйганчы башыңны җуй.
  Дөнья йорты тар булса да, күңелең киң булсын.
- Җаның олы булса, һәр эшең олы.
  Җаның сау булса — авырумын димә, тәнең сау булса —ярлымын димә.
- Исем кешене бизәми, кеше исемне бизи.
  Исемеңне ташка язма, ил йөрәгенә яз.
- Йөрәгең тимердән булса, хәнҗәрең агачтан булса да ярый.
- Казан карасы китә, намус карасы китми.
  Кеше алдында кем дә гөл, кеше артында намус бел.
  Кеше булган кешенең кеше белән эше бар, кеше булмаган кешенең кешедә ни эше бар?
  Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.
  Кеше карбыз түгел, чиртеп белә алмыйсың.
  Кеше үз кадерен белми кадирун* кадерне белмәс, былбылдан үзгә кошлар гөлстан кадерен белмәс.
  Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
  Кешедән оялмаган кешенең йөзе олтан.
  Кешенең холкы күркәм булса — тереклеге хуш була, холкы явыз булса — тереклеге буш була.
  Киемең киң булганчы күңелең киң булсын.
  Куркак ашта батыр, кыю эштә батыр.
  Куркак гомергә батырлык турында сөйләр.
  Куркак кеше үз күләгәсеннән дә курка.
  Курку үлемнән коткармый.
  Курыкканга куш, койрыгы белән биш.
  Курыкканга куян да аю булып күренә.
  Кыюлык — ярты бәхет.
  Күзе сукырга юлдаш бул, күңеле сукырга юлдаш булма.
  Күркәм кием тән зиннәте, күркәм холык җан зиннәте.
  Күңел каралыгын бернинди сабын да агарта алмый.
  Күңел ярлылыгы кесә ярлылыгыннан начаррак.
  Күңеле ачыкның юлы ачык.
  Күңелең иркен булса, бәхетең киң булыр.
- Намус җаннан кадерле.
  Намусы таза кеше ишек шакудан курыкмый.
- Оялмаган боермаганны ашаган.
  Оялмаган кеше өчен оятлының йөзе кызарыр.
  Оят юкта иман юк.
  Оятның теше булмаса да кимерә.
- Пычак ярасы китә, намус карасы китми.
- Теләгең саф булса, тормышыңда тап булмас.
  Тәвәккәл таш яра, таяк баш яра.
  Тәвәккәлдә тау көче бар.
  Тәвәккәллек белән батырлык бер чишмәдән чыгар.
  Төсең кара булса да, күңелең ак булсын.
- Холкы бозык кешенең фикере дә бозык була.
  Холкы начардан дуслары качар.
  Холыкны дәвалау җәрәхәтне дәвалаудан авыррак.

Холыксыз кеше койрыксыз көймәгә охшый.

- Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер.
- Яман ат белән торганнан яхшы ат белән үлгән яхшырак.

* * *

- Ат тартмаслык оят, үгез тартмаслык гаеп.
  Аты олы, кабыргасы коры.
  Адәм дисәң — коны* юк, хайван дисәң — йоны юк.
- Әрле Мәликәгә коры тәлинкә.
- Байлыгым булмаса, намусым бар.
- Җаным тыныч, ярмам — арыш.
- Исемем илдә, урыным түрдә.
- Кечесендә әдәп юк, олысында белек юк.
  Киемең кеше күркесе, фигылең кеше көлкесе.
- Оялса — үз бите, биртелсә — үз биле.
  Оят белән алыш-биреш бетү.
  Сарык янында батыр, батыр янында сарык.
- Үгет бездән, әдәп белү үзеңнән.
  Үз күләгәсеннән үзе курыккан.
  Үзе әдәпсез, киеме сәдәпсез.
  Үзе курка, үзе йолка.

### Акыл, аң, акыллылык һәм акылсызлык

- Аз булса да, үз акылың булсын.
  Акча ярлысыннан акыл ярлысы яман.
  Акыл байлыгы — тузмас байлык.
  Акыл булса, юл бар.
  Акыл — тезген, холык — ат, тезгенеңне белеп тарт.
  Акыллы атын мактар, кыланчык үзен мактар.
  Акыллы сүзен «мин» дип башламый.
  Акыллы уйлаганчы, тиле сугып ега.
  Акыллы өйрәнер, ахмак өйрәтер.
  Акыллыга ишарәт, акылсызга бишәр әйт.
  Акыллының аты да армый, туны да тузмый.
  Акылсыз, атка менсә, атасын танымас.
  Акылсыз калудан ике күзсез калганың артык.
  Ахмак көндез шәм ягар, мае беткәч кичен айга багар.
  Ахмакка биргән киңәш далага аткан ук кебек.
  Ахмакны алтынга мансаң да ахмак.
- Бер ахмакның соравына унике акыллы җавап бирә алмый.
  Бер юләр югалтканны йөз акыллы таба алмас.
  Битеңне бизәмә, акылыңны бизә.
- Диванага кайгы да бәйрәм.
  Дуракка доктор даруы дәрман бирмәс.
  Дөядәй алтының булганчы,төймәдәй акылың булсын.
- Ике чабата бер кием, ике җүләр бер тиен.
  Иләктә су тормый, юләрдә сүз тормый.
  Исәр яңа тунын кисәр, иске тунын ямар.
  Исәр үзе атланган ботакны үзе кисәр.
- Йөз акыллыны бер тинтәк саташтырыр.
- Кешенең акылы — эшеннән, гыйлеме сүзеннән беленер.
- Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк.
- Тиле белән тапма да, өләшмә дә.
  Тиле белән яшәгәнче, акыллы белән бергә үл.
  Тиле, «тиле» дигән саен, тигәнәк буе сикерер.

Тиле түрен бирмәс.
Тиле үзен-үзе мактар, ялкау үзен-үзе аклар.
Тинтәк белән мал тапканчы, акыллы белән югалт.
Тинтәк ике кәҗәсен берьюлы суяр.
Тинтәк тегелмәгән итеген мактар.
Тинтәкнең йә кулы тынмас, йә теле тынмас.

- Үз илендә юләр булган читтә акыллы булмас.
  Үзе сөйләр, үзе көләр — шулдыр юләр.
- Юләр бармак күрсәтсәң дә көлә.
  Юләр белән серләшмә, усал белән телләшмә.
  Юләр «җиңдем» дияр, акыллы «юл бирдем» дияр.
  Юләрне уңга борсаң, сулга йөгерер.

* * *

- Акыл сатма, үзеңә калмас.
  Акыл теше чыккан инде.
  Акыл чәчләре башын ташлаган.
  Акыл өләшкәндә абзар артында калган.
  Акыл өләшкәндә кершән буянып калган.
  Акылың алтын булса да, үзең бакыр.
  Аның акылы керәле дә чыгалы.
  Атайдан яшь калдык, акылдан буш калдык.
- Әллә юләрлек, әллә үҗәтлек.
- Бармакка чорнарлык та акылы юк.
- И юләр, юләр, мәче казыр, эт күмәр.
- Ни акыллы, ни тиле, ни булса да икеле.
  Ни чүмәлә, ни зурат, ни акыллы, ни дурак.
- Өй артында килесе, килесе янында тилесе.
- Син акыл җыйганда мин дә таш санамадым.
- Үз акылым үземдә, кеше акылы теземдә.

**Юмарт-саран, канәгать-комсыз. Җитез-акрын, тискәре, ваемсыз, астыртын, ялагай**

- Азның кадерен белмәгән күпнең кадерен белмәс.
  Акрын барган аттан узган, йөгереп барган тайдан калган.
  Акрын барган куян артыннан җиткән.
  Акрын баскан ат булган, ашыкмый йөргән ир булган.
  Акрын ишсәң — бау булыр, арбаң-чанаң сау булыр.
  Алдыңда ялагай булган артыңда алабай булыр.
  Арыш тора саламда, акча тора саранда.
  Астыртын астан кисә, өстән ямый.
  Астыртын үлән астыннан ут йөртә.
  Ашыгу борча тотканда гына ярый.
  Ашыгыч эшкә шайтан катыша.
  Ашыккан ашка пешәр, кабаланган сазга төшәр.
- Бай бәхетле түгел, юмарт бәхетле.
  Барына разый бул, югына сабыр ит.
  Бирмәснең ашы пешмәс, казаны уттан төшмәс.
- Диңгезне күмеп була, адәмнең комсызлыгын күмеп булмый.
- Еланның аягын күрмәссең, саранның сыен күрмәссең.
- Җитезгә йөз өлеш, йомшакка бер өлеш.
- Иң батыр кеше — үз нәфесен җиңә алучы.
- Канәгатьле кешедә көнчелек булмас.
  Кешегә көнең төшмәсен, саранга эшең төшмәсен.
  Коеның суы салкын, саранның күзе салкын.
  Комсыз, абынып егылса да, бер әйбер учлап алмыйча тормас.

Комсыз, котырса, коега кармак салыр.
Комсыз тау кимереп, диңгез суын эчсә дә туймас.
Курыкма тугыз башлы еланнан, курык ике йөзле адәмнән.
Кызганган кешенең малын кызыл эт җыяр.
Күпне өмет итсәң, аздан коры калырсың.

- Нәфеснең тезгене акыл кулында.

- Сабыр иткән морадына җиткән.
Сабыр төбе — сары алтын.
Саран бай хәерчедән ярлырак.
Саран кеше — төпсез мичкә шикелле: аны һич тутырып булмый.
Саранннан акча сорау — үгез саву белән бер.
Саранның агачы үсмәс, үссә дә җимеше пешмәс.
Саранның яраткан ашы — күрше шулпасы.

- Үзе өчен саран кешедән башкалар өчен юмартлык көтеп булмый.
Үтә мут булсаң — муеныңнан асылырсың, үтә җыбыткы булсаң — аяк аста калырсың.

- Чи тирене иләсәң, олтан булыр; нәфесен тыйган кеше солтан булыр.

- Шөкранасыз кешедән икмәк-тоз кадерен белгән эт яхшы.

- Юмарт кешенең морҗасыннан төтене куе чыгар.
Юмарт үз малын үзе ашар, саран малы саранның үзен ашар.
Юмартлык белән батырлык икесе бер чишмәдән ага.
Юмартлык дошманны да дус кылыр, саранлык балаларны да дошман кылыр.

- Ялагай алда мактар, артта сүгәр.
Яхшы кешенең эче белән тышы бердәй була.

* * *

- Барынча юмарт, югынча тук.

- Җае килсә — күгәрчен, җайсызланса — ябалак.

- Кайтсаң — кабулым бар, кайтмасаң — сабырым бар.
Күбенә түзгәнне әзенә түзәрсең.

- Нәфесе бозау алачыгы кадәр.
Нәфесенең башын япмаган.

- Син ашыксаң, ул кабалана.

- Тулды сабыр савытым.
Тиз пешерә — чи пешерә.
Тәмгыңны* тәртә буе сузма.

**Тыйнаклык, мактану, мин-минлек, үзеңнеке һәм кешенеке**

- Башта үзен зур тоткан — соңыннан хур булган.

- Үз-үзен мактаган — агач атка атланган.
Үзен-үзе белмәгәнне үгез сөзеп үтерсен.
Үзеңнеке үзеңә юмасаң да ак.
Үзеңнеке үзеңә, ай күренер күзеңә.
Үзеңә яратмаганны кешегә дә яратма.
Үктәмнең* аягы күктән.

- Иңкәйгәнгә иңкәй башың җиргә тигәнче, чалкайганга чалкай башың күккә җиткәнче.

- Кеше хакын хакласаң, үз хакыңны хакларлар.
Кеше үзен-үзе таныса, акылы җитешкән булыр.
Кешегә таш атсаң, үз маңгаеңа тияр.
Кешене «мин» басканчы миң бассын.
Кешене хур тотма, үзеңне зур тотма.
Киберлек* — кәрлә сыйфаты, кечелек — бәндә сыйфаты.
Купайның* калпагы да калай.
Кәпәренү күркәгә килешә.

- Мактанма, ат дип сыерга атланма.
Мактанчык — бүредән курыкмаган, тычканнан коты очкан.

Мактанчык кеше дәрәҗәгә менсә, баштан борыны уза, ди.
Мин-минлек — кимлек.

- Тыйнакның кулы эшләр, мактанчыкның теле эшләр.
Тәкәббердән тәңре бизгән.
Тәкәбберлек — шайтан сыйфаты.
- Шапырыкның арты ерык.
- Эрелек артыннан хурлык ияреп йөрер.
- Юкка кәпрәйгән — вакытсыз кәкрәйгән.

* * *

- Берсе кешенеке, берсе күршенеке.
- Гали үзенә, Вәли үзенә.
- Итенепме итенә, төкермиләр битенә.
- Кыланышы кырга сыймый.
- Мактанма, син бәрәңге ашаганда мин дә бар идем.
- Син түгел мин дә әллә кем түгел.
Сине бит тегеләр дә мактыйлар, куярга урын гына тапмыйлар.
- Уңса да үзе, туңса да үзе.
- Үз кабыгына гына бикләнеп яши.
Үзегезне белегез, сәндерәгезгә менегез.
Үзенекен ялгышмый, кешенекен аңышмый.
Үзенә дигәндә үгездәй көче бар.
Үзең кайда, ямең шунда.

**Яхшылык һәм яманлык. Яхшы, рәхимле, юаш, усал, яман кешеләр**

- Агач йомшагын корт басар, адәм йомшагын сүз басар.
Алтынга тут кунмас, яхшылык онытылмас.
Аю кашка булмас, усал яхшы булмас.
- Бака бакылдавын куймас, яман такылдавын куймас.
Бер яхшы бар — илнең гамен йотар, бер яман бар — илнең малын йотар.
- Еланның агуы телендә, яманның агуы күңелендә.
- Зәнки* кешегә гөл бирсәң, гөл корыр.
- Игелекле эшнең иртәсе-киче юк.
Изгелек ит тә диңгезгә сал: балык белер, балык белмәсә Халик* белер.
Изгелек итсәң яшер, изгелек күрсәң фаш ит.
Изгелек эшен озакка сузарга ярамый.
Ике яхшы бер сәкегә сыя, ике яман бер шәһәргә сыймый.
Йөз юу белән генә яманлык карасы китмәс.
- Казанга якын килсәң — карасы йогар, яманга якын килсәң — бәласе йогар.
Кешегә яманлык теләгәнче үзеңә яхшылык телә.
Коры суык кардан яман, яман кеше яудан яман.
Кулыңнан бер яхшылык килсә, бишне кыл.
- Начар кеше кеше кулы белән елан тотарга ярата.
Начарны күрмәгән — яхшының кадерен белмәс.
- Туксан тугыз яхшылыгыңны белмәсләр, бер начарлыгыңны белерләр.
- Усал белән каберең якын булмасын.
Усал булсаң асарлар, юаш булсаң басарлар, уртача булсаң, ил агасы ясарлар.
Усал кеше өеңә кереп ашыңны ашый, читкә чыгып башыңны ашый.
Усаллык белән баланы да җиңеп булмый.
- Чүлнең камышы булмас, яманның намусы булмас.
- Юаш булганчы чүп бул, чүп булганчы юк бул.
Юаш юанайса, ишеккә сыймас.
Юньсезгә майлап бирсәң, юеш дип әйтер, ди.
Юньсезне табакка төртсәң, тагаракка тартыр.

- Яман арба юл бозар, яман кеше ил бозар.
  Яман белән җәннәттә булганчы, яхшы белән җәһәннәмдә бул.
  Яман йөремнән яхшы үлем артык.
  Яман кеше утлы күмер кебек: көйдерә дә, каралта да.
  Яман кешедән арт итәгеңне кисеп кач.
  Яман сыйлаганны белмәс, сыер сыйпаганны белмәс.
  Яман эт итәккә ябыша, яман кеше якага ябыша.
  Яманга яхшылык кылсаң, «миннән курыкты» дияр.
  Яманлык итәргә бер кул да күп, яхшылык итәргә ике кул да аз.
  Яманны күрмәгән яхшының кадерен белмәс.
  Яманны җанга санама, кәҗәне малга санама.
  Яманның авызыннан елан чыгар, арбый* алмый җаны чыгар.
  Яманның түрендә булганчы яхшының гүрендә бул.
  Яхшы атның йөреше тигез, яхшы кешенең холкы тигез.
  Яхшы белән сөйләшсәң, балга шикәр каткандай; яман белән сөйләшсәң, эткә сөяк аткандай.
  Яхшы белән юлдаш булсаң, җитәрсең син моратка; яман белән юлдаш булсаң, калырсың син оятка.
  Яхшы белән яман арасы — җир белән күк арасы.
  Яхшы кеше ай белән көндәй: яхшылыгы һәркемгә бер- дәй.
  Яхшы күңелленең аты армый, туны тузмый.
  Яхшы төзеп куаныр, яман бозып куаныр.
  Яхшы эшнең башы бул, яман эшнең койрыгы да булма.
  Яхшыга иярсәң — бизәккә, яманга иярсәң — тизәккә.
  Яхшылыкка яхшылык — һәр кешенең эше, имеш; яманлыкка яхшылык — ир кешенең эше, имеш.
  Яхшылыкка өйрәнергә өч ел кирәк, яманлыкка — өч сәгать тә җитә.
  Яхшының яхшылыгы тияр тар җирдә, яманның кәсафәте тияр һәр җирдә.
  Яшерен эшләгән яхшылык яктыда бүләк алыр.

* * *

- Аннан качкан, моннан качкан, яманчылык белән күзен ачкан.
- Тыштан юаш, эчтән шайтанга юлдаш.
- Ул бик яхшы кеше, ләкин йоклаганда гына.
  Усалның узаманы мин булырмын.
- Үтә изге, аннан да җан бизде.
- Хайванга караса — казанга кертәм, ди, кешегә караса —кабергә кертәм, ди.
- Һәммәсе — бодай, без — салам; барча яхшы — без яман.
- Юаш дип бармагыңны авызына тыкма, бармаксыз калырсың.
- Яхшыга «җаным» ди, яманга «каным» ди.

### Турылык-хыянәт, хәләл-хәрәм, сер, вәгъдә, ачу, үпкә, көнчелек, хата. Караклык, җинаять-җәза

- Авызың үпкәдә булса, кулың тоткада булсын.
  Алган бер языклы, алдырган мең языклы.
  Ачу — агу, йотсаң — бал-шикәр.
  Ачу алдан йөри, акыл арттан йөри.
  Ачу ачу китерер, ачу шайтан китерер.
  Ачу йоту — тау кебек, йотып куйгач бал кебек.
  Ачулы кешегә песи койрык күтәреп йөрсә дә ярамый.
  Ачулының күзенә түгәрәк әйбер дә дүрт кырлы булып күренә, имеш.
  Аюны җиңгән — ярты ир, ачуын җиңгән — бөтен ир.
  Адәм түгел фәрештә — гөнаһсыз түгел һәр эштә.
  Адәм яңлыша-яңлыша өйрәнә.
- Әманәт җан саклый.
  Әманәткә хыянәт — ул кешегә кыямәт.
- Бер казага ике җәза юк.
  Бозау урлаган үгез дә урлар.
  Бур булдың — хур булдың.
  Бәндә хатадан хали* түгел.
  Бүгенге ачуны иртәгә саклама.

- Вәгъдә ителгән хәлвәдән кулга кергән серкә яхшы.
  Вәгъдә — намус көзгесе.
  Вәгъдәсен ашыкмый биргән кеше вәгъдәсендә торучан була.
- Гаеп балтада да бар, сапта да.
  Гөнаһның азы да бер, күбе дә бер.
- Җинаятьченең җаны уч төбендә.
- Ил — угрысыз, урман киексез булмас.
- Кара эшне караңгыда эшләсәң дә яктыга чыга.
  Карак, урларга әйбер таба алмаса, үз бүреген үзе урлый, имеш.
  Каракны яшергән кеше үзе дә карак.
  Карга — каркылдап, карак карганып котылыр.
  Каты яңгыр тиз ачылыр, каты ачу тиз басылыр.
  Кешенең төймәдәй гаебен күргәнче үзеңнең дөядәй гаебеңне күр.
  Кинәле кеше — энәле кеше.
  Корт — төтеннән, гаепле — хөкемнән курка.
  Кырда чалыш йөрсәң дә, кылганың туры булсын.
  Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә.
  Көнчелек гомерне кыскарта.
- Өйдәге угрыдан саклана алмассың!
- Су бөтен пычракны юа ала, тик хыянәтне юа алмый.
- Туры утырып кырын уйлаганчы, кырын утырып туры уйла.
  Турылыклы булып үлү ялганчы булып яшәүдән яхшырак.
- Угры урлый, бай булып тормый.
  Урлаган бер языклы, урлаткан мең языклы.
- Үлгәннән соң тәүбә юк.
  Үпкәләгәннең үпкәсен эчтән кыеп алып булмый.
  Үпкәләүгә каршы үпкәләү — янган утка утын ташлау белән бер.
  Үпкәне — ачу белән, утны май белән басалмассың.
- Хаклык агачы ташка утыртсаң да корымый.
  Хатаңны әйтүчене атаң дип бел.
  Хәйлә сазы сеңгәлек: бер аягыңны алганчы икенчесе батар.
  Хәйләкәрдән йомырка алсаң, эчендә сарысы булмас.
  Хәләл тышка тартыр, хәрәм эчкә батыр.
  Хәрәмнән җыелган әрәмгә китә.
- Чын яхшының, ачуы булса да, үпкәсе булмас.
- Энә урласаң, дөя түләрсең.
  Эчтә кинә тотудан үпкә сүзне әйтеп бетергән яхшы.
- Юлтый* үз үлеме белән үлми, ди.
- Ялгыша белдең — төзәтә дә бел.

* * *

- Ак тәүбә, кара тәүбә.
  Аскакка* куеп асармын, кискәккә* куеп кисәрмен.
  Ат урладык—тотылмадык, тавык урлап тотылдык.
  Ачу килгән чак, кулда балта-пычак.
- Бездә булмас гаеп, үзегездән чыкмасын таеп.
- Иске хәтер, яңа үпкә.
- Кәйләм үтмәсә, хәйләм үтәр.
  Кырыктан артык кыңгыр як.
- Сорап бирмәдем, урлап күрмәдем.
- Тәүбәң тукран тәүбәсе булмасын.
  Теле языкка туймас, авызы азыкка туймас.
  Теләге үргә тарта, язгы түнгә* тарта.
- Хатасы тездән, тәүбәсе билдән.
- «Ып» дияргә ярамый, калка-чыга ачуым.

- Язык казык башына, җавап Алла каршына.

### *Тел-сүз. Әдәбият-сәнгать. Фән-белем*

### **Телнең роле, телгә осталык, туган тел һәм чит телләр**

- Алтыда белгән ана телен алтмышта онытмас.
  Ананың балага биргән иң зур бүләге — тел.
  Ашыккан тел чүпрәккә әйләнә.
  Аяк белән абынудан тел белән абыну яман.
- Әдәп башы — тел.
- Бал тамган телдән агу да тамар.
- Дөньяда иң ачы нәрсә дә — тел, иң төче нәрсә дә — тел.
- Елан агуы тешендә, адәмнеке — телендә.
- Инсафлының теле саф.
- Кесәңдә малың булмаса, телеңдә балың юкмы?
  Кеше — теленнән, хайван тезгененнән эләгә.
  Кеше теленә чуер таш чатный.
  Кул ярасы бетәр, тел ярасы бетмәс.
  «Көш» дип әйтергә теле юкның күзен карга чукыр.
- Озын тел елан кебек: авыздан чыкса, муенга урала.
- Суны — таяк белән, кешене тел белән үлчиләр.
  Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
- Татлы тел аю биетә.
  Татлы тел еланны да өненнән чыгарыр.
  Тел — белемнең ачкычы, акылның баскычы.
  Тел белән тегермән тартып булмый.
  Тел кечкенә булса да, сүзе дөньяга сыймый.
  Тел сөйләр дә керер, ни күрсә дә баш күрер.
  Тел татлысы иясенә бал ашатыр, татсызы таяк ашатыр.
  Тел таш яра, таш ярмаса баш яра.
  Тел җиде кат җир астыннан да таба.
  Телдән килгән кулдан да килсен.
  Теле барлар халык булган, теле юклар балык булган.
  Теле барның юлы бар.
  Теле бозыкның күңеле бозык.
  Телең белән ашыкма, эшең белән ашык.
  Телең белән фикер йөртмә, акылың белән фикер йөрт.
  Телең озын булса, гомерең кыска булыр.
  Телне бал белән кисәләр.
  Телнең буе кече, гөнаһы олы.
  Телнең зиннәте — тугры сүз.
  Тиле илчегә акыллы тылмач кирәк.
  Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.
  Тугры телемне тыя алмыйм, туганыма керә алмыйм.
- Фил күтәрмәгәнне тел күтәрә.
- Һәр илнең ачкычы — тел, телен белгән ил ачар.

* * *

- Авызы бар, теле юк.
  Агач авыз, балта тел.
  Ай-һай телең, тел очыңда безең.
- Русчаны белмим, татарчаны аңламыйм.
- Тел бистәсе, куян хастасы.
  Тел өсте бал да май, тел асты ай да вай.
  Телгә килсә очынган, эшкә килсә кычынган.
  Телгә күршегә кереп тормый.

Теле авызына сыймый.
Теле белән тере агачны корытыр.
Теле дилбегә буе.
Теле көрәк, сүзе кибәк.
Теле сарыкныкы, теше бүренеке.
Теле телгә йокмый.
Теленә шайтан төкергән.
Телең булмаса, күптән карга күтәреп алып китәр иде.
Телең чыптадан булса, әллә кайчан тузып бетәр иде.

**Сүз, аның төрләре. Сүзне үтәү. Чын һәм ялган. Сөйләм культурасы**

- Авыздагы сүзгә син ия, авыздан чыккач сүз ия.
Авызың кыек булса да, сүзең туры булсын.
Авызыңнан тозсыз сүзең чыкканчы, каерылып тезең чыксын.
Агач башын җил бутый, адәм башын сүз бутый.
Адәм сөйләшеп, хайван иснәшеп таныша.
Адәмне әләк белән органчы, башына бәләк белән ор.
Аз сөйләгән аз ялгышыр.
Аз сүз — алтын, күп сүз — бакыр.
Аз сүз — үз сүз, күп сүз — чүп сүз.
Аз сүзле — алтын, күп сүзле — болтун*.
Акыллы сүз алтыннан кыйбат.
Акыллы сүз тимер капканы да ачтыра ала.
Алдау бакыр акча кебек: бик кечкенә эшләргә генә ярый.
Асылынган кеше өендә бау турында сөйләшмиләр.
Ат кешнәшеп белешә, адәм сөйләшеп таныша.
Ат ычкынса тотылыр, сүз ычкынса тотылмас.
Ашның мае бар, сүзнең җае бар.
Аяк астыннан чыккан еланнан саклан, аяк астыннан чыккан яладан саклан.
Аңламаганга туры сүз дә кыйшык булып күренә.
Аңламый сөйләшкән авырмый үләр.
- Әйткән бер сүзгә ышансаң, төпсез коега төшәрсең.
Әйткән сүз — каккан кадак.
Әйтсәң — сүз чыга, төртсәң — күз чыга.
Әләк төбе — һәлак.
Әләкче, кеше өстеннән әләклим дип, үзен әләкләгән.
- Бакма кешенең йөзенә, бак син әйткән сүзенә.
Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы.
Бер сүз күтәрә алмаган кеше күп сүз күтәрергә мәҗбүр булыр.
Бер ялган сөйләсәң, тугыз дөресеңә дә ышанмаслар.
Бер яхшы сүз мең күңелнең җәрәхәтен төзәтә.
Бәлачегә бер таяк, әләкчегә мең таяк.
Бөтенләй сөйләшмәсәң, телсез булырсың.
- Гайбәт күмер кебек: көйдермәсә дә буйый.
Гайбәт чәйнәгәнче сагыз чәйнә.
Гайбәтне әйт колакка, ишетелер еракка.
Гайбәтченең теле мең колач.
- «Дыр»белән «ди»не иккәннәр дә, чыкмаган, ди.
«Дыр»га чыпчык та кунмый, дырылтый да очып төшә.
Дәлиле азның сүзе озын.
Дәшми торганда җүләр дә акыллы.
Дәшми торсаң, котырган аю да юашлана.
Дөньяны җил боза, адәмне сүз боза.
Дөресен әйткән котылыр, ялган әйткән тотылыр.
- Елан — аяксыз, ялган — тамырсыз.
Еланның агуы тешендә, ялачының — телендә.
- Җылы-җылы сөйләсәң, елан да өненнән чыга.
- «Имеш»нең җимеше юк.

Ип белән сөйләгәннең ирене авыртмый.
Йомшак сүз садакадан артык.
Йөз кат әйткәнче, бер кат эшләп күрсәт.
Йөри белмәгән юл бозар, сөйли белмәгән сүз бозар.

 Каргыш ике башлы, юан башы үзеңә төшә.
Каргыш төбе кан белән, теләк төбе бал белән.
Каты сүзгә тал сына, йомшак сүзгә таш эри.
Кеше сөйләгәнне сөйләмә, үзең күреп сөйлә.
Кеше ышанмастай сүзне дөрес булса да сөйләмә.
Кешегә артык сүз әйткәнче, артык телем ипи аша.
Кешенең, акылы камилләнгәч, сүзе азая.
Колактан кергән салкын сүз йөрәккә барып боз була.
Коры сүздән пылау булмас, дөгесе-мае булмаса.
Көлке сүз сөйләшү ашка тоз салу кебек.
Көндез сөйләшсәң — эшең кала, кич сөйләшсәң — йокың кала.
Күп йөргән азар, күп сөйләшкән язар.
Күп сөйләгән кешенең хатасы да күп була.
Күп сүзнең азы яхшы, аз сүзнең үзе яхшы.

 Нык сүзне тимер дә җиңә алмый.

 Озын сүздән кыска җеп яхшы.
Оста ялганчы дөрес сүз эченә генә ялган кушар.

 Сине тыңламаган җирдә дәшми утыр.
Сиңа каты сүз әйтсәләр дә, син йомшак сүз белән җавап бир.
Сөйләгән кеше ахмак булса, тыңлаган кеше акыллы булсын.
Сөйләгән сүзең татлы булса да, кайта-кайта сөйләмә.
Сөйләр сүзең алтын булса да, күп сөйләгәч бакырга калыр.
Сөйләшә белмәгән кешедән өрә белгән эт артык.
Сүз иясе белән йөрми.
Сүз куган бәлагә юлыгыр, юл куган казнага юлыгыр.
Сүз сөйләргә яратсаң, кешене дә тыңлый бел.
Сүз сөйләсәң, уйлап сөйлә.
Сүз сөйләү — һөнәр, сөйли белмәгән үләр.
Сүз сөяктән үтәр, таяк иттән үтәр.
Сүз чыпчык түгел, очырсаң тота алмассың.
Сүзең булсын аңларлык, өзелсә дә ялгарлык.
Сүзең көмеш булса, тик торуың — алтын.
Сүзең үлгәнче үзең үл.
Сүзне әйтмә, әйтсәң — кайтма.
Сүзнең башы каты булса, соңы татлы була.

 Талаш — майлы аш түгел.
Талашсаң килешергә юл калдыр.
Татлы сүз әйтеп телең сынмас.
Татлы сүз — җан азыгы, ачы сүз — баш казыгы.
Тиешсезгә сөйләү — ташка тары чәчү.
Тиргәшчегә тиңләшмә, талашчыга таңланма.
Тозсыз сүздән тозлы ботка тәмлерәк.
Туры сүз башта зәһәр булса да, соңы шикәр; ялган сүз башта шикәр булса да, соңы зәһәр.
Туры сүз таш яра, ялган сүз баш яра.
Туры сүзгә ант кирәкми.
Туры әйткән котылыр, ялганлаган тотылыр.
Туры әйткән туганына ярамаган.
Тыныч күлгә таш атма, тиешсез җиргә сүз катма.
Төче сүз — агу, ачы сүз — дару.
Төче ялганнан ачы хакыйкать яхшы.

 Уен сүзне һәркем белмәс, кешесенә карап сөйлә.
Уйламый сөйләсәң, башыңа тукмак алырсың.
Ук берне үтерсә, сүз меңне үтерә.

 Үзең алтын булмасаң да, сүзең алтын булсын.
Үтерек* кешенең дөрес сүзенә дә ышанма.

Үтерек сүз җанга үч, үткен пычак кынга үч.

- Хикмәтле сүзне чүплектә күрсәң дә ал.
- Чабатаны катласаң ныгыр, сүзне катласаң сүтелер.
- Ягымлы сүзгә берәү дә ачуланмый, ачулы сүзгә берәү дә куанмый.

Ялган белән дөнья гизәрсең, кире кайта алмассың.
Яла теле еланнан яман.
Ялган белән яла бер арбада йөриләр.
Ялган озын аяклы, гайбәт озын колаклы.
Ялган сүзне дөресләү таш ватудан авыррак.
Ялган әйтеп файда тапсаң, соңыннан зарар табарсың.
Ялганчы төшендә дә ялганлый.
Ялганчының бер исеме ялачы.
Ялганчының өе янган, берәү дә ышанмаган*.
Яман сүз йөрәккә таш булып утырыр.
Яман сүз уттан каты пешерер.
Яман хәбәр алтмыш аяклы була, имеш.
Яхшы сүз ара төзер, яман сүз ара бозар.
Яхшы сүз балдан татлы.
Яхшы сүз — җан азыгы, усал сүз — баш казыгы.
Яхшы сүз — җанга рәхәт, яман сүз — җанга җәрәхәт.

* * *

- Авызым иләк булса, сүзем сирәк.

Аның әйтере бар, кайтыры бар.
Аулакта авыз япмас, җыенда сүз тапмас.

- Әйткән сүзен эт җыймас.

Әйткәнгә күнеп, төрткәнгә түнеп.

- Бер тиен биреп сөйләтеп булмас, ике тиен биреп туктатып булмас.

Берсе тугай дип сөйли, берсе бугай дип сөйли.

- Гайбәте түгел, гадәте.
- Иске авыздан яңа сүз.
- Кеше сөйли ялганны, мин сөйлим аннан калганны.

Кеше сүзе бер колагымнан керер, бер колагымнан чыгар.
Кеше туй сөйләгәндә, ул җеназа сөйләгән.

- Мин аз әйтсәм, син күбен аңла.
- Орыр сүзем күңелемдә, орыр ташым куенымда.
- Син әйтмәдең, мин ишетмәдем.

Сиңа ялган, миңа чын.
Сөйләргә үзен җиде кала җиңмәс.
Сүздә — болан, эштә — елан.
Сүзе балдай, күңеле боздай.
Сүзе белән көлдерә, күзе белән көйдерә.
Сүзе сүзгә ошамый, авызы сүздән бушамый.
Сүзләр хуш, кесә буш.

- Тавышы бөереннән чыга.

Тәмле бәлештән калыр идем, шыпырт сүздән калмас идем.
Төтен түгел, сүзләре күзгә кермәс.

- Үзсүзле, үгез күзле.

Үз төнлегеннән генә карап сөйли.
Үзе алтын булмаса да, сүзе алтын.
Үзе тавышчан да, изгелеккә авышучан.
Үзем түрдә, сүзем үрдә.
Үзең бакыр булсаң да, сүзең алтын.

**Әдәбият, фольклор әсәрләре, көй, бию. Музыка кораллары**

- Авызыңны борсаң җыру була, аягыңны атсаң бию була.

Ай белән көн уртак, җыр белән көй уртак.
Амбар төбендә икмәк бар, картлар сүзендә хикмәт бар.

- Белгәнгә җыр, белмәгәнгә «дыр».
  Белмәгәнгә әкият, белгәнгә чын.
  Бер биюче белән туй булмый.
  Бер йөрәктә туган җыр мең йөрәкне кузгата.
  Бии белгәнгә бер идән тактасы да җитә, бии белмәгәнгә бөтен идән дә аз.
  Биисе килмәгәнгә көй килешмәс.
  Борынгылар сүзен тыңламасаң, борының белән капланырсың.
  Борынгыларның әйткәне кыеш китмәс.

- Гармунчы назлы булыр.

- Думбыра туй төшкән өйгә килешер.

- Елап яшәгәнче, җырлап үл.
  Ерактан җырлаган җыр матур ишетелә.

- Җыр белгәнгә җыр һөнәр, җыр белү дә зур һөнәр.
  Җыр, кайгыны басмаса да, күңелне ача.
  Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч.
  Җырлый белмәгән кеше сызгырып йөри, ди.
  Җырны берәү шатлыктан, берәү кайгыдан җырлый.
  Җырның ертыгы юк, ертылса ямавы юк.
  Җырның ертыгы юк, көйнең китеге юк.

- Ике биюче бер арканда биемәс.
  Иң яхшы көйне дә рәттән өч кат җырламыйлар.
  Ияк күрке — сакал, сүз күрке — мәкаль.

- Камчат күрсәң атып ал, мәкаль сүзне отып ал.
  Карама агач еш булмый, картлар сүзе буш булмый.
  Картлар сүзен кар басмас.
  Кемнең җырын җырласаң, шуның көен көйләрсең.
  Кеше җырын җырлыйм дип, үз җырыңны онытма.
  Кубыз биетми, моңы биетә.
  Курайдан килгән сорнайга* китәр.
  Көй — күңелнең моңы.
  Көйне уйнап кына түгел, уйлап чыгар.
  Көндез әкият сөйләгән кешене ак бүре ашар*.

- Музыканы хайваннар да яраталар.
  Мәзәк — күңел ачкычы, табышмак — зиһен ачкычы.
  Мәкаль сакалдан олырак.
  Мәкаль җыймыйм — акыл җыям.
  Мәкальдә ялган юк, яхшыда яман юк.
  Мәкальне адәм чыгармый, заман чыгара.
  Мәкальсез сүз — тозсыз аш.

- Скрипка искергән саен яхшырыр.
  Сылтаусыз мәкаль дә әйтелми.
  Сүз — чәчәк, мәкаль — букет.

- Табылган табышмак бик җиңел күренер.
  Тамчы төшми чәчәк ачылмый, җырламыйча йөрәк басылмый.
  Тел әйтә алмаганны җыр әйтер.

- Уенчы назланып мазаңны алыр.
  Уенчыга ялынсаң, өч көнгәчә назланыр.

- Шатлыгың ашса да — җыр, кайгы басса да — җыр.
  Шигырь гомере шагыйрь гомереннән озын.

- Эчкә сыймаган җырга чыга.

- Яучы телен саклый, думбырачы кылын саклый.
  Яхшы җырның даны үзеннән алда йөри.

* * *

- Алдан ук барабан кагып кычкыру.

Аңа җырларга кушалар, ул: «Аягым авырта»,— ди.

- Болай чакта авыз япмас, туй дигәндә җыр тапмас.
  Бу әле әкиятнең баласы, мичтә ята аның анасы.
- Ерактан тыңлаганда матур җырлый.
- Иске көйләр белмим, яңаларын оталмыйм.
- Коры куык, ярык барабан.
- Ни думбыра белмәгән, ни сызгыра белмәгән.
- Ярма тарттырганда җырлый, ут сүнгәч бии.

**Фән-гыйлем, уку-язу, галим-надан, белү-белмәү**

- Аз белмәгән күп тә белмәс.
  Акча, мал — бер көнлек, гыйлем, һөнәр — гомерлек.
  Алтын җирдән табыла, белем — китаптан.
  Арпа-көрпә аш булмый, надан кеше баш булмый.
  Аю беләгенә, адәм белегенә* — ышана.
- Бай булмасаң бай булма, гыйлем-һөнәргә сай булма.
  Байлык бозга язган, белем ташка язган.
  Белгән белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр.
  Белгәнгә — белек, белмәгәнгә кул селек.
  Белгәнең — тугыз, белмәгәнең — утыз.
  Белем — белгечлек патшалыктан югары.
  Белем белгән филгә менәр, белем белмәгән гүргә иңәр.
  Белем — бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы.
  Белемдә — бәхет, белемсезгә дөнья ләхет.
  Белемне алу суганнан ачы, азагы балдан татлы.
  Белемсез эшләүче юлсыз җирдән баручы белән бер.
  Белмәгәнен сорап өйрәнгән — галим, гарьләнеп сорамаган —үзенә залим.
  Белмәгәнне сорауның ояты юк.
  Белмәү бер гаеп, белергә тырышмау ун гаеп.
  Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар.
  Болыт астындагы кояшның җылысы юк, халыкка төшмәгән гыйлемнең файдасы юк.
  Бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә.
- Галим белсә дә сорый, надан белмәсә дә сорамый.
  Галим белән надан арасы былбыл белән карга аермасы.
  Галим кадерен галим белер, надан кадерен беркем бел- мәс.
  Галим үләр — сүзе калыр, йөргән җирендә эзе калыр.
  Галимнең бер көне наданның бөтен гомеренә тора.
  Гамәлсез гыйлем — яңгырсыз болыт.
  Гыйлем белән аз гамәл дә файдалы.
  Гыйлем кояштан яктырак.
  Гыйлем үз иясенә — дус, мал үз иясенә — дошман.
  Гыйлемлекнең тамыры ачы булса да, җимеше татлы.
- Дөнья — йозак, ачкычы — белем.
  Дөнья тора ун тәңкә, гыйлем тора мең тәңкә.
- Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел.
- Каләм тоткан әрәм булмас.
  Кешенең очар канаты белем була.
  Кием — тәннең, гыйлем — күңелнең зиннәте.
  Китап — бер нәселнең икенче нәселгә калдырган мирасы.
  Комсызлык һәр җирдә гаеп, белемгә комсызлык гаеп түгел.
  Кылыч көченә караганда каләм очы әсәрлерәк.
  Күп яшәгән ни белер, күп укыган шул белер.
  Күп беләсе килгән кеше күп йокламый.
- Мал бае бөләр, гыйлем бае бөлмәс.
  Мәктәп юлы — җәннәт юлы.
- Наданлык — бәхет юлында киртә.

Наданлык — дәвасыз авырудыр.
Наданның белгәне — «белмим».
Наданның сүзе ишектән чыкканчы гына ярый.

- Тирәнлек — диңгездә, зирәклек — гыйлемдә.
- Уку — белем болагы*, белем — гомер чырагы*.
Укыдым димә, белдем диген.
Укымаган күзлене укыган сукыр җиңгән.
- Эшнең иң ләззәтлесе — гыйлем эстәү.
- Үзең бел, кешедән сора.

* * *

- «А»ны «б»гә куша белмәү.
«Әлиф»кә* бар, «би»гә* юк.
«Әлиф»тән «би»гә кадәр, йөгердем өйгә кадәр.
«Әлиф»не таяк дип белми*.
- Бар да яхшы, без яман, бар да галим, без надан.
- Ике аягыннан тотып селексәң, «әлиф» төшмәс.
- Үзе белми, кешедән сорамый.
Үзе белмәс, белгәннең телен алмас.
- Хәрефкә хәрефне ялгый белү.
Хәрефкә ябышып ятучы.
- Яза-яза сандыгын тутырган, укый белмичә авызын ачып утырган.

***Мәҗүсилек. Ислам дине***

**Мифик затлар**

- Аждаһа, азса, күлгә сыймас.
Аждаһаның эчкән саен сусыны кабарыр, ди.
Алла шайтаныннан адәм шайтаны яман.
Алтын күрсә, фәрештә юлдан язар.
Ашыккан эшкә шайтан катышыр.
- Багучылык — ялган эш, күңел алдап юаныч.
Бичура белән пәри дус.
- Дары исеннән шайтан кача, имеш*.
Диюгә тәмуг юлын күрсәтмәсәң, оҗмах юлын белмәс.
- Җен дигәнең саңгырау сазлыкта оялый ул.
Җенгә җен тими.
Җенне күреп шаккатмасаң, шундук күздән юк булыр.
- Ил кайда, иблис анда.
Ишәк ише белән, шайтан шае* белән.
- Кыз, кымыз, кубыз — шайтанга өч кулавыз*.
Күперне чыкканчы шайтанга да ялыналар.
- Мал малга җиткәнче газраил җанга җитәр.
Мәчкәй* — тәңренең убыры*.
Мәчкәйнең эчендә еланы бар.
Мунча пирсез* булмый, күл балыксыз булмый.
- Очалмаган убыр өендәген убар.
- Пәри баккан, җен тапкан.
Пәри башка, җен башка.
- Сылтау өчен дөньяда шайтан бар.
Сөләйман үлде, диюләр котылды*.
- Убыр китте, урыны калды*.
Убыр симермәс, угры баемас.
Убыр упкан табылмас, пәри суккан сау булмас.
Убырның күзе күрмәсә дә күңеле тоя.

- Хәерле эшне ашыктырмасаң, шайтан катыша.
- Чурт* белән шайтан икесе дә бер.
- Шайтан белән юлга чыксаң, койрыгын ычкындырма.
  Шайтан ризыгына бисмилла кирәк түгел.
  Шайтан таягы белән йөрер.
  Шайтанга кирәк булса, Коръәннән дәлил китерә.
  Шайтаннан иман алып булмый.
  Шайтаннан үлмәс туар, чукрактан көлмәс туар, сукырдан күрмәс туар.
  Шайтанны җен нишләтсен?
  Шайтанның дуслыгы дар агачына хәтле.
  Шайтанның үз күлендә үз ирке.
  Шүрәле судан шүрли*.
- Юханың теленә алданма.
- Ялмавыз җиде чакрымнан теле белән ялмап йотар.
  Яман — яшькә туймас, мечкәй ашка туймас.
- Өметсез — шайтан*.

* * *

- Бер карасаң — үрәле*, икенче карасаң — шүрәле.
- Иблисне иманга өндәү.
- Судан шайтаныңны чыгарыр.
- Шайтан ярлы, без бай.
- Әвен әүлиясе, мунча фәрештәсе.
- Җеннән куркып албастыга очраган.

## Ислам дине, шәригать

- Дин кардәш булса да, мал кардәш түгел.
- Ике кыйблага оеганның иманы булмас.
  Икмәксезнең иманы юк.
- Кяфернең ялкавы — монах, мөселманның ялкавы суфи булыр.
- Кул кулны белә, шәригать юлны белә.
- Мөселманлык — туклыкта, инсаф китәр юклыкта.
  Мөселманның нияте кылган гамәленнән изге, имеш.
- Эш кулны көтә, шәригать юлны көтә.

* * *

- Динем өчен түгел, көнем өчен.
- Кырыгына бер иман, утызына бер комган.
- Үзем күптән иманлы, күршеләрем өчен кайгырам.

## Алла (Ходай, Тәңре)

- Алла бирмәгәнне мулла бирмәс.
  Алла бирсә колына, чыгарып куяр юлына.
  Алла бүрегә азык бирсә, тешен сындырып бирә, имеш.
  Алла ташламаса, бүре ашамас.
  Аллага сыенсаң сыен, ишегеңне каты бикләә.
  Аллага ышан, үзең кымшан.
  Аллага ышанып суга төшмә, йөзә белсәң төш.
  Алладан сыер сорасаң да, кәҗә генә бирә, ди.
  Алланың ирке бар, мулланың бүрке бар.
  Алланың кеме юк, арбаның төбе юк.
  Атыңны Аллага тапшырсаң да, дилбегәсен үзең тот.
- Игенче яңгыр тели, чүлмәкче аяз тели, бер Алла кайсына ярасын.
- Качкан да: «Алла!», куган да: «Алла!» — ди.

- Моңсыз* бер Ходай.
- Танык өчен Ходай бар, сылтау өчен шайтан бар.
  Тәңре көне тарыдан да күп.
  Тәңре малын шайтан кызганыр.
  Тәңре тәкә түгел, хәзер китереп сөзми.
  Тәңре эше фәрман белән, бәндәнеке дәрман белән.
- Уңса — Алладан, уңмаса — бәндәдән күрәләр.
- Ходай органны пәйгамбәр таягы белән төртә, ди.
  Ходайдан узып патшага барып булмый.

* * *

- Аллага да юк, муллага да юк.
- И Ходаем, тәүфыйк бир, чәй эчәргә конфет бир.
  И Ходаем, үзең китер уңаен.
- Күктән илла Алла белән, кырык-илле мулла белән.
- Тәңрегә әйткән, кирәмәткә биргән*.

### Ахирәт*, оҗмах, тәмуг

- Бар да оҗмахка керсә, җәһәннәм буш калыр иде.
  Бар да тигез — җәннәттә.
  Бер өйрәнгәч, тәмугка да күнегәләр, ди.
- Мин дә языклы, син дә языклы: ул оҗмахка кем лаеклы?
- Сабыр төбе саф алтын, тәмуг төбе сап-салкын.
- Теге дөньяга соңга калам дип берәү дә курыкмый.
  Тәмугка өйрәнгән оҗмахка кермәс.
  Тәмугны да яхшы нияттән корганнар, ди.

* * *

- Алдым — җәннәт, артым — тәмуг.
- Мин үлгәч, теләсә кыямәт купсын.
- Җиде җәннәт ишеген ачу.

### Дини йолалар

- Аллага — шөкер, муллага фытыр*.
- Бер намазга ике азан әйтелми.
- Елына килгән ике гает*, аның да берсен укымасаң гаеп.
- Ике гает, бер җомга, ул да җитә бер елга.
- Кабул булмас догага амин тотма.
  Коры җәймәгә дога булмас.
- Намазга азан ярашыр, сүзгә казан ярашыр.
- Руза*, намаз туклыкта, иман качар кытлыкта.

* * *

- Салават*, тәкбир* әйтеп ишанны* да алдап була.
  Сорау күктән, җавап тегермәннән.
  Сәдакасына күрә савабы, соравына күрә җавабы.
- Телең белән дога кыл, кулың белән эшлә.
  Төрле авылда төрле эттәхият*.
- Ураза керде — намаз, ураза чыкты — шабаз*.
  Утыз көн уразаның бер көн бәйрәме була.
- Хаҗи дигәнебезнең куенынннан хачы* чыкты.
  Хәленнән килгән хаҗ кылган, хәленнән килмәгән ач торган.

* * *

- Ике дога, бер җыр*.
- Мәчеткә баргач, мулланы күрмәгән.
- Уразаны мин тотам, бәйрәмен бай итә.
- Әлхәм* белән Әбҗәткә* без кермибез әҗәткә.

Руханилар

- Абыстай бизәнгәнче туй узган.
  «Алла» дисәң, мулла кызын бирә, ди.
  Ашлы өйне мулла мактый.
- Байга бармак янама — ишсез калырсың, муллага бармак янама — гүрсез калырсың.
  Бер авылда мөәзин күп — иртә намазын көн чыккач укыганнар.
  Бүзче белгәнен тукый, мулла белгәнен укый.
- Дәрвиш — ашавыннан, бай — яшәвеннән билгеле.
- Ике дәрвиш бер паласка сыяр, ике патша җир йөзенә сыймас.
  Имамның да имансызы була.
  Ишан очмас, мөрите очырыр*.
- Карак — каргана, мулла — зарлана.
- Мужик бил сындырып, мулла бит сыпырып көн итә.
  Мулла азса, мәхәлләгә* ни сан.
  Мулла акчаны дус тотмый, кулына керсә, буш тотмый.
  Мулла эше өстендә, ризыгы кеше өстендә.
  Муллага — мазар*, сәүдәгәргә базар кирәк.
  Муллага мәчет юлын өйрәтергә кирәкми.
  Мулладан — дога, мужиктан — дуга.
  Мулладан: «Шаһитең кем?» дип сорагач, мәзингә күрсәт- кән, ди.
  Мулланың аты чибәр капкага туктый.
  Мулланың сөйләгәнен тыңла, кылганын кылма.
  Мулласы нинди, мәхәлләсе шундый.
  Мөритләр булса, мөршитләр* табыла.
- Суфи* күп жирдә шайтан күп.
  Суфи суган ашамас, кабыгын җиргә ташламас.
- Тавык күргәнен чукыр, мулла белгәнен укыр.
  Түрә — приказ белән, мулла — указ белән.
- Ярлы — беләгенә, мулла теләгенә ышаныр.

* * *

- Аның күк кенә мулла кызында да була.
- Бәлеш ашаганда син дә мулла, мин дә мулла.
- Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала.
- Әлеге дә баягы, сукыр суфи таягы.

**Искәрмәләр һәм сүзлек**

11 биткә

**Көн** — кайбер мәкальләрдә «кояш» мәгънәсендә кулланыла.

**Тимерказык** — Котып йолдызы. Ул хәрәкәт итми һәм һәрвакыт төньяк Котып ягын күрсәтә. Шуңа күрә дә бик борынгы заманнардан бирле юл-сәфәр йөрүчеләр өчен ышанычлы табигый ориентир булып хезмәт иткән.

**Акбүзат, Күкбүзат** — Тимерказык (Котып) йолдызы тирәли әйләнүче ике йолдыз. Беренчесе шактый якты, икенчесе аңа караганда тоныграк күренә.

13 биткә

**Кайгаклы** — аю сыман табанлы-тырнаклы.

14 биткә

**Бриллиант кара таштан чыгар** — асыл кеше булу нәсел-чыгышка карамый.

**Күк тимер кайрау белән алмаз булмас** — XIX йөз шагыйре М. Акмулланың «Һәр заман сүз башланыр» шигыреннән таралган канатлы сүз.

15 биткә

**Монтар** — киртә, каршылык.

**Сусын кану** — сусау басылу.

16 биткә

**Нократ** — Вятка елгасы. Болгар ханлыгы чорында аның буенда көмеш, бакыр рудниклары булган.

**Ут** — биредә: үлән.

**Чулман** — Кама елгасы.

18 биткә

**Тәгам** — ризык.

19 биткә

**Алыс** — ерак.

**Чап** — яхшы исем, дан

20 биткә

**Аяк** — савыт (биредә: «сый» мәгънәсендә).

21 биткә

**Тазы** — ау эте.

**Кавәс** — шул ук календарьда якынча ноябрьгә туры килүче ай: Укчы (Стрелец).

**Җәүза** — Зодиак йолдызлыклары исемнәренә корылган кояш календаренда якынча майга туры килә торган айның гарәпчә исеме. Татарча— Игезәкләр (Близнецы).

**Кантар** — кышкы вакыт (ноябрь-декабрь тирәсе).

**Коралай** — кышкы иң салкын вакыт (коралай суыгы да диләр).

22 биткә

**Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы** — «Яз яхшымы, көз яхшымы?» дигән сорауга бер авыл карты шулай җавап биргән, имеш.

**Хут** — кояш (Зодиак) календаренда якынча февральгә туры килүче ай: Балык (Рыбы).

**Микула** — иске стиль буенча 9 май һәм 6 декабрь.

Питрау (Петров день) — иске стиль буенча 29 июнь.

**Покрау (Покров)** — иске стиль буенча 1 октябрь.

**Сәвер** — кояш (Зодиак) календаренда якынча апрельгә туры килүче ай: Үгезбозау (Телец).

**Сөмбелә** — шул ук календарьда якынча августка туры килүче ай: Кыз (Дева).

23 биткә

**Урак ае** — августның җирле халык календарендагы исеме.

**Хәмәл** — кояш (Зодиак) календаренда якынча мартка туры килә торган ай: Кучкар (Овен).

**Элҗен (Ильин день)** — иске стиль буенча 20 август.

**Энем кырлач, Агам кырлач** — җирле халык календаренда якынча декабрь һәм гыйнварга туры килүче айлар.

**Чиллә** — җәйге чиллә: 25 июньнән 5 августка кадәр дәвам итә торган бик эссе вакыт; кышкы чиллә: 25 декабрьдән 5 февральгә кадәр дәвам итә торган бик салкын вакыт.

**Чуак** — аяз, кояшлы көн.

24 биткә

**Нух пәйгамбәр заманыннан** — «бик күптәннән, бик борынгы заманнан» мәгънәсендә. Нух пәйгамбәр турындагы дини мифка бәйле.

**Раштуа (Рождество)** — христиан бәйрәме: Иисус Христос туган көн дип санала (иске стиль буенча 25 декабрь).

**Яренгә** — иртәгә (яки киләсе елга).

25 биткә

**Лэйсэн** — яз көне беренче тапкыр вак кына сибәләп яуган яңгыр.

26 биткә

**Сафура бураннары** — гаиләдә (яки башка бер коллектив эчендә) гадәттә хатын-кыз чыгара торган тавыш-гауга, ызгыш-җәнҗал турында.

27 биткә

**Аксыргак** — юан тамырлы, эре яфраклы, себерке сыман чәчәкле кыр үсемлеге.

**Актамыр** — сарут.

**Камышны үз күлеңнән ал** — үз авылыңнан өйлән.

28 биткә

**Чыкан** — кычыткан.

**Умырзая, яфрагыннан алда, чәчәген күрсәтер** — кунак алдына сый-нигъмәт куйганчы ук аңа якты йөз күрсәтү кирәклеге турында.

**Таптау** — такыр басу.

**Эргәзембай** — умырзая.

**Абага чәчәк атканда** — «һичкайчан булмаячак» мәгънәсендә әйтелә. Чөнки абага чәчәк атмый. Әмма халык ышанулары буенча, ул, имеш, чәчәк ата икән, тик аны бик бәхетле кешеләр генә күрә икән. Шул чәчәкне авызыңа капсаң, кеше күзенә күренмисең икән.

**Бетү** — биредә: үсү.

**Ку** — коры, кипкән

**Үрт** — ут.

29 биткә

**Ашак** — түбән, тәбәнәк.

**Тиген** — бушлай.

30 биткә

**Өсәк** — келәттә такта белән бүленгән урын яки зур әрҗә.

**Тарлан җир** — сөрелгән, эшкәртелгән җир.

**Кырлык** — чүп үләне.

**Әтәмби** — коелган орлыклар, шул орлыклардан үскән иген.

**Вырых (ворох)** — көшел.

31 биткә

**Бакыра** — бакра (чүп үләне).

**Грәз (грязь)** — сулы-дымлы жир мәгънәсендә.

**Пәҗи** — киндер, киндер орлыгы.

**Тарма** — кыргый киндер.

32 биткә

**Башын карабодай саламы белән япкан** — «сакланып сөйлә, ул безнең телне белә» дип кисәтү өчен әйтелә.

**Гидайлык** — ярлылык, фәкыйрьлек.

**Җир алмасы** — бәрәңге.

**Җилектерү** — туйдыру, күңел кайтару (ашамлык турында).

34 биткә

**Курган** — ныгытма (крепость) стенасы.

**Яфрак астына керү** — банкротлыкка чыгу.

**Бәрмәчлек** — тал песие.

35 биткә

**Йөгенү** — иелеп, бөгелеп алу.

**Сөян** — кайрысы, кабыгы төшерелгән юкә бүрәнәсе.

37 биткә

**Кискә** — юан агач кисентесе, түмәр, бүкән.

38 биткә

**Кас** — үч, каршы, дошман.

40 биткә

**Җию** — ашау.

**Аю хезмәте күрсәтү** — белмичә, урынсыз ярдәм күрсәтеп, нәтиҗәдә күңелсезлек, зыян китерү мәгънәсендә кулланыла. Килеп чыгуы бер әкият белән бәйле. Имештер, кеше белән аю дуслашканнар. Кеше йоклаганда моның маңгаена чебен килеп кунган. Аю, чебенне кумакчы булып, аңа таш белән бәргән. Чебен очып киткән, ә кеше маңгае яньчелеп үлгән.

41 биткә

**Аның бүресе улый** —бәхете алга барган кеше турында. Татарларда бүре улавын яхшыга юрау гадәте булган.

42 биткә

**Коралай** — кыр кәҗәсе.

**Чарчау** — ару,талчыгу.

43 биткә

**Кара төлке булу** — бик сирәк күренүче кешегә әйтәләр. Кара төлке — төлкенең аз очрый торган кыйммәтле төре.

**Төлкене көлкегә калдырырлык** — бик хәйләкәр, алдакчы кеше турында.

**Җор** — далаларда яшәүче мөгезле кыргый хайван, антилопаның бер төре.

44 биткә

**Кассап** — терлек суючы.

**Качаган** — көтүдән йә йорттан качып китүчән терлек.

**Кашкыр** —дала бүресе; гомумән бүре.

**Хаҗтархан** — Әстерхан.

45 биткә

**Чаман** — ялкау, иренчәк.

47 биткә

**Асау** — җигәргә өйрәтелмәгән.

48 биткә

**Азнау** — көчле тавыш белән кешнәү.

**Толпар (тулпар)** — 1) Әкияттәге канатлы ат; 2) Бик шәп чап- кын ат.

49 биткә

**Кысрак** — кысыр калдырылган йә колынламый торган бия.

50 биткә

**Нар** — бер өркәчле дөя.

51 биткә

**Тәвә, төя** — дөя.

53 биткә

**Ул гына алланың кашка тәкәсе** — борынгы заманнарда маңгаенда кашкасы (ак йон үскән төше) булган тәкә изге саналган, аңа аерым хөрмәт күрсәтелгән. Хәзер бу гыйбарә башкалар алдында үзен эре, һавалы тотучы, үзенә аерым игътибар көтүче кешегә карата кулланыла.

54 биткә

**Инәк** — савым сыер.

55 биткә

**Боендырык** — үгез камыты.

56 биткә

**Лашман** — элек крестьяннарны корабльләр төзү өчен урман әзерләү эшенә мәҗбүр иткәннәр. Шул «лашман» дип аталган.

57 биткә

**Тычкан таяк белән йөргән чак** — бик сак булуны таләп итә торган заман турында.

62 биткә

**Өстеннән кош та очырмау** — бик нык саклау, кадерләү.

**Сәмруг** — әкиятләрдәге бик эре һәм көчле, гадәттән тыш тиз оча торган кош.

**Батман** — элекке авырлык үлчәве (4 пот).

**Үз йоны** — үз каурые. Ук туры очсын өчен аның очына кош каурые куя торган булганнар.

64 биткә

**Күгәрчен сөте генә юк** — калган бөтен нәрсә дә бар. Җитешлекне, муллыкны аңлата.

65 биткә

**Йокым** — сандугач йокысы — аз, начар йоклау.

66 биткә

**Торна тәпи алып килү** — бала йөри башлаганда әйтәләр.

**Рашкы** — боз.

67 биткә

**Ябалак кыйнаган нәрсә** — тиле.

**Ябалак шулпасы** — исерткеч эчемлек.

**Әтәлге** — зур бөркетнең бер төре.
**Дөя кошы** — тәвә кошы.

68 биткә
**Сиртмә койрык** — чәперчек.
**Торымтай** — лачыннар семьялыгыннан кечкенә ерткыч кош.
**Чупай** — ябалак төре.
**Купай** — мактанчык, эреләнергә яратучы.
**Көелте** — шөлди, саз кошы (русча кулик).
**Һөдһөд** — җилпәзә сыман бүрекле, чуар төстәге кош. Кечкенә, ләкин асыл нәрсә символы.

69 биткә
**Там** — биредә: балчык яки таш дивар, койма.

72 биткә
**Чыракчы** — төнлә көймәдә басып торып, чыра (ут) яктысында балык аулаучы (чәнчеп алучы).
**Чуртан кушуы буенча** — көч куймыйча, үзеннән-үзе генә зур уңышка ирешү. Әкияттән таралган канатлы сүз.
**Комырык, томырык** — агымсыз, хәрәкәтсез сулык.

73 биткә
**Кәсәртке** — кәлтә.
**Еланны аждаһага әйләнгәнче үтереп кал** — явызлыкны кечкенә чагында бетереп кал. «Елан йөз ел яшәсә аждаһага, мең ел яшәсә юхага әйләнә» дигән ышанудан.
**Ташбака Куянны узган** — Куян белән ташбаканың узышуы турындагы әкият һәм мәсәл сюжетларыннан. Бер очракта мактанчык Куян, үз җитезлегенә артык ышанып, ятып йоклый һәм шул арада Ташбака бөтен юлны узып өлгерә. Икенче очракта Ташбака Куянны хәйлә белән җиңә: билгеләнгән пунктларга алдан ук үзенең туганнарын урнаштырып чыга. Куян никадәр тиз чабып килсә дә, аны һәр пунктта: «Мин инде күптән монда»,— дип, Ташбака каршы ала.

74 биткә
**Елан кабыгын салу** — явызлыкны яшерү, икейөзлелек турында.
**Назы бар** — биредә: мәшәкате, хезмәте бар.

75 биткә
**Аерылып чыккан корт кебек** — «бернәрсәсез» мәгънәсендә.
**Карышлавык** — киң канатлы күбәләкләрнең бик нык дугаланып, карыш белән үлчәгән шикелле хәрәкәтләнә торган корты.
**Копшангы** — ат тизәге белән туена торган коңгыз.
**Сагызак** — шөпшә.

76 биткә
**Сөләйман** — легендар Сөләйман патша (пәйгамбәр), чиксез зур властька ия булган итеп сурәтләнә.
**Үрмәкче** — үрмәкүч.

77 биткә
**Күсә** — сакалсыз, сакал үсми торган кеше.
**Түнелү** — читләшү, ераклашу.

80 биткә
**Ырай** — уй, фикер, күңел.

81 биткә
**Ите сиңа, сөяге миңа** — элек ата-ананың баланы укырга яки остага эшкә өйрәнергә биргәндә әйткән сүзләре. Коры сөяккә калса да, белем алсын, һөнәр үзләштерсен.

83 биткә
**Куласа (колесо)** — тәгәрмәч.

85 биткә
**Кыйгырыш** — бәхет кошы.
**Ырыскал (рыскал)** — бәхет.

91 биткә
**Иләмән йомыркасы** — «илнең кадерлесе» мәгънәсендә.

92 биткә
**Савыл (чавыл)** — яшь каен агачы, каенлык.

**Түбән авыл этләре өрү** — ашыйсы килү.

94 биткә
**Аманлык (иминлек)** — тынычлык.

95 биткә
**Алафа** — биредә: сугышта батырлык күрсәткән кешегә бирелә торган бүләк.
**Сөңгеле Сөләйман** — һәркемгә төрттереп, чәнчеп сөйләшүче кешегә әйтелә.
**Аксөяк** — затлы, югары нәселдән булган кеше.

98 биткә
**Чаман** — ялкау, иренчәк.

99 биткә
**Фартавый (фартовый)** — һәр эштә җай, уңыш килеп тору.

102 биткә
**Шир** — арыслан.

106 биткә
**Илегү** — ияләшү.
**Инә** — әни, ана.
**Мәнди анасы да белә** — ягъни һәркем белә. Мәнди — беркатлы, тилемсә фольклор герое, анасы да мәзәкләрдә шул чамадагы бер тип булып гәүдәләнә.

107 биткә
**Бата** — бәрәкәт, кот, уңыш.

109 биткә
**Җиде баҗаны бер бүре ашаган** — үзара татулык, бердәмлек булмаса, күп кешеләрнең дә аз санлы дошманыннан җиңелүе турында. Имештер, бер кешенең җиде кияве бар икән. Бер көнне ул кияүләренең барысын да кунакка чакырып, тигез сый-хөрмәт күрсәткән. Берничә көн сыйлангач, җиде баҗа, һәркайсы үз атын җигеп, өйләренә кайтып киткәннәр. Юлда боларга ач бүре очраган да, арттагы чанада кайтучы баҗага ташланып, аны ашый башлаган. Калган баҗалар, җыелып аны коткарасы урынга, «әйдә, ашый бирсен, ул булмаса, кайнатага мин кадерлерәк булырмын» дип, урыннарыннан кузгалмаганнар. Аннан бүре икенче, өченче баҗага һөҗүм иткән һәм берәм-берәм җидесен дә ашап бетергән, ди.

110 биткә
**Кыргын** — үләт, кешеләрнең күпләп кырылуы.

114 биткә
**Кеше алдында мин оста, икәү калсак, ул оста** — агалы-энеле ике балта остасыннан: «Сезнең кайсыгыз оста?» — дип сорагач, агасы шулай дип җавап биргән, имеш.

115 биткә
**Былазау** — ялкау, эшләмичә тик ятучы.
**Этләч** — әрсез.
**Ирмәк** — күңел ачу, кызык эзләү.

116 биткә
**Эш беткәч уйнарга ярый** — Г. Тукайдан халыклашкан канатлы әйтелмә.
**Дуен** — эшнең иң хәтәр, иң авыр өлеше.

119 биткә
**Каргалы** — авыл исеме.

129 биткә
**Ай-һай минем үз өем, киң сараем, бүз өем** — легендар халык шагыйре Җирән чичәннән калган гыйбарә дип санала. Имештер, хан аны үз сараена яшәргә чакырган. Сарайда бераз яшәгәч, чичән үз өенә җибәрүне сорый башлаган. Хан аптыраган: «Моның өе минем сараемнан да яхшырак микәнни?» — дип, Җирән чичән артыннан күзәтчеләр җибәргән. Чичән шәһәр читендәге кечкенә генә алачыкта яши икән. Үз өенә кергәч, ул, бик кәефләнеп, әлеге сүзләрне әйткән, ди.

132 биткә
**Карама көленә утыру** — бик нык алдану.

134 биткә

**Йөзеге барда Сөләйман, йөзеге юкта сөмәйгән** — дини мифология буенча, Сөләйман пәйгамбәрнең бөтен көче, кодрәте анын тылсымлы йөзегендә булган. Ул йөзеккә Аллаhы Тәгаләнең 99 исеме арасыннан иң бөеге язылган булган, ди.

**Йөзек үтә тарткан** — сылу, зифа.

135 биткә

**Чаба** — эчлеге булмаган кием, җилән.

**Кыптыр тун** — тупас иләнгән тиредән тегелгән тун.

136 биткә

**Күлмәк эчендә туган** — ягъни карындыгы белән туган бала. Андый бала бәхетле була дип ышанганнар. Мәхмүд Кашгари 1072—1074 елларда төзегән төрки телләр сүзлегендә — каплыг угыл. Шулай ук «бәхетле» дигән мәгънәдә.

**Түбәтәй җыеп калу** — артта калу, соңару.

**Иске чабатага яңа киндерә үргән** — дөнья көтәргә оста кеше.

137 биткә

**«Аш» дигәндә аттан төш** — аштан олы булма.

139 биткә

**Ярма суда** — алтыга, сөттә уникегә ярыла — күчерелмә мәгънәдә мактанчык кешегә карата әйтелә.

**Чәлпәк** — камырдан ясалган вак-вак җәймәләрне кайнап торган сары майда пешереп хәзерләгән ашамлык, юка.

140 биткә

**Җот** — ашауга комсыз кеше.

**Казы (казылык)** — атның түш ите; өйдә хәзерләнгән колбаса.

**Комагай** — комсыз, ашап туймый торган.

**Талма** — йөрәк авыруы.

**Түтәнә** — аш-су аермаучы кеше, талымсыз.

141 биткә

**Йөзем суы** — йөзем җимешеннән төнәтелгән исерткеч эчемлек.

142 биткә

**Чулпы** — биредә: тал чыбыгыннан яки камыштан челтәрләп үреп ясалган бәрәңге чүмече.

**Савыт-саба шалтырау** — тавыш-гауга чыгу.

143 биткә

**Капчык төбен селкү** — берсен дә калдырмый әйтеп бетерү.

**Кашың булсын** — кунакка ачык йөз күрсәтү кирәклеге турында.

146 биткә

**Кадирун**— олылар, өлкәннәр.

147 биткә

**Коны** — күрке, яме.

151 биткә

**Тәмгы** — комсызлык, ач күзлелек.

**Үктәм** — тәкәббер.

**Киберлек** — эрелек, тәкәбберлек.

**Купай** — мактанчык, эреләнергә яратучы.

152 биткә

**Зәнки** — тупас, усал.

**Халик** — яратучы, бар кылучы (Алла).

153 биткә

**Арбау** — тылсымлау, йомшарту, буйсындыру.

154 биткә

**Хали** — азат, буш.

155 биткә

**Юлтый** — авантюрист, карак.

**Аскак** — дар агачы.

**Кискәк** — кискә, түнәр.

156 биткә

**Түн** — арт, кире як.

159 биткә

**Болтун** — күп сөйләүче, такылдык.

161 биткә

**Үтерек** — ялган.

**Ялганчының өе янган, берәү дә ышанмаган** — имештер, бер ялганчы төн уртасында: «Өем яна! Ярдәм итегез!» дип кычкырып, кешеләрне алдап җыйган да, үзе шырык-шырык көлеп тора икән. Тагын бер мәртәбә шулай эшләгән бу. Өченче кат моның өендә чыннан да янгын чыккан. Әмма ул ярдәм сорап күпме генә кычкырса да, «бу тагын алдыйдыр» дип, берәү дә килмәгән. Ялганчының өе янып беткән.

163 биткә

**Сорнай** — өреп уйнала торган борынгы музыка коралы.

**Көндез әкият сөйләгән кешене ак бүре ашар** — моңа охшаш тыю (табу салу) табышмак әйтүгә карата да булган. Монда борынгы ышану эзе сизелеп тора. Соңрак исә мондый тыю көндез эш вакытында әкият сөйләшеп утыруны хупламау белән аңлатылган булырга мөмкин.

164 биткә

**Белек** — белем, гыйлем.

165 биткә

**Болак** — инеш.

**Чыраг** — чыра, шәм. Биредә: «яктырткыч» мәгънәсендә.

166 биткә

**Әлиф** — гарәп алфавитындагы беренче хәреф.

**Би (ба)** — шул алфавиттагы икенче хәреф.

**«Әлиф»не таяк дип белми** — ягъни укымышсыз, надан. Әлиф язуда вертикаль таякчык белән белдерелә. Инде шуны да белмәү чыннан да чеп-чи наданлык булып чыга.

167 биткә

**Дары исеннән шайтан кача, имеш** — яңа өйгә күчкәндә, килен төшергәндә һ.б. йолалар вакытында мылтык ату шушы ышану белән бәйләнгән.

**Шай** — тиң, бердәй.

**Кулавыз** — юл күрсәтүче, арадашчы.

**Мечкәй (мәчкәй)** — убырлы карчык.

**Убыр** — халык ышанулары буенча, ут рәвешендә йөри торган рух — җан. Күчерелмә мәгънәсе — күп ашаучы, туймас тамак.

**Пир** — пәри.

168 биткә

**Сөләйман үлде диюләр котылды** — имештер, Сөләйман пәйгамбәр җен-пәриләр, диюләр өстеннән хакимлек кылган, аларны үзенә хезмәт иттергән.

**Убыр китте, урыны калды** — кеше җыелган җирдә берәрсе торып китсә, аның урынына килеп утыручы шушы сүзләрне әйтә. Киңрәк мәгънәдә берәүнең урыны бушау икенче кешегә файда булуын аңлата.

**Чурт (черт)** — шайтан.

**Шүрәле судан шүрли** —шуңа күрә, имештер, шүрәле куа башласа, берәр суның икенче ярына чыгып качарга кирәк икән. Шүрәле суны кичәргә курка икән.

**Өметсез** — шайтан — чөнки ул тәмугка хөкем ителгән. Ә кеше өметсезләнмәскә тиеш.

**Үрә** — өйрә.

169 биткә

**Моңсыз** — мохтаҗсыз.

170 биткә

**Тәңрегә әйткән, кирәмәткә биргән. Тәңре** — борынгы төркиләрдә баш Мәҗүси алла (Күк алласы). Ислам кабул ителгәннән соң Аллаһы Тәгаләне дә «Тәңре» дип атый башлаганнар. Кирәмәт — карама төреннән булган агач. Мәҗүсилек заманында бу агачны изгеләштерү, аңа табыну йоласы булган. Гыйбарәдә, ислам кабул итеп тә, мәҗүсилек йолаларын да саклаучылар хакында сүз бара. Күчерелмә мәгънәсе — үз карашларында тотрыксыз, вәгъдәсез кеше.

**Ахирәт** — ислам диненчә: үлгәннән соң булачак теге дөнья.

**Фытыр** — ураза үткәч, гаиләдәге җан башыннан бирелә торган сәдака.

**Гает** — дини бәйрәм (ураза, ягъни рамазан гаете, корбан гаете).

**Руза** — ураза.

**Салават** — мактап-хуплап яки уңыш теләп укыла торган дога.
**Тәкбир** — «Аллаһ әкбар» (Алла иң бөек) дигән сүзләрне әйтеп Алланы олылау.
**Ишан** — үз тирәсенә мөритләр (иярченнәр) җыеп, алар белән рухани җитәкчелек итүче.

171 биткә
**Әттәхият** — намазда тезләнеп утырып укый торган дога.
**Шабаз (Шаһбаз)** — лачын.
**Хач** — тәре.
**Ике дога, бер җыр** — ваемсыз кеше турында.
**Әлхәм, Әбҗәд** — Коръәндәге сүрә (бүлек) исемнәре.
**Ишан очмас, мөрите очырыр** — мөритләрнең ишанны культ итеп, аның төрле «могҗизалары» турында хәбәрләр таратуына киная.
**Мәхәллә** — авылның яки шәһәрнең бер мәчеткә караган өлеше.
**Мазар** — кабер, зират.

172 биткә
**Мөршит** — мөритнең табынган кешесе (мәсәлән, ишан).
**Суфи** — тормыштан, дөньядан ваз кичеп, гомерен Аллага, дингә хезмәт итәргә багышлаган мөселман.

## Файдаланылган чыганаклар исемлеге

*Ахунҗанов Г. Х.* Татар теленең идиомалары.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.
*Әхәтов Г. Х.* Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.
*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989; II том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.
*Мәхмүтов Х. Ш.* Канатлы сүз — хикмәтле сүз.— Казан: Мәгариф, 1999.
*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 2 т. Т. 1.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1974; II том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.
*Сафиуллина Ф. С.* Татарча-русча фразеологик сүзлек.— Казан: Мәгариф, 2001.
Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 т. Т. 1.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1977; Т. 2.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1979; Т. 3.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.
Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре / Төзүчеләр Л. Җәләй, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1957.
Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр / Төзүче, кереш мәкалә, искәрмәләр язучы Х. Мәхмүтов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.
Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре / Төзүче Х. Ярми.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.
Татар халык мәкальләре / Җыючысы, төзүчесе һәм кереш мәкалә язучы Н. Исәнбәт: 3 т. Т. 1.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1959; Т. 2.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1963; Т. 3.— Казан: Татар. китр. нәшр., 1967.
Татарча-русча сүзлек. / Ред. Ф. А. Ганиев.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.
*Юсупов Р. А.* Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков.— Казань: Татар. кн. изд-во, 1980.

## Эчтәлек

Кереш ..............................................................................

### Мәкальләр, канатлы сүзләр, җор сүзләр, әйтемнәр

Күк һәм җир

Күк йөзе, кояш, ай, йолдызлар
Җир өсте: ком, балчык, таш, тау, дала һ.б.
Казылма байлыклар, аларны үзләштерү
Сулар: чишмә, кое, елга, күл диңгез һ.б. ...............................

Табигатьнең сыйфатламалары

Әйбер (нәрсә), аның асылы, төсе, формасы, микъдары һ.б. билгеләре
Урын, ара, якын-ерак, ал-арт, ас-өс, уң-сул һ.б.
Вакыт, заман, ел һәм ел фасыллары. Ай, атна, көн-төн, иртә-кич һ.б.
Һава торышы: җылы-суык, җил-давыл, явым-төшем һ.б.

## Үсемлекләр

Үлән, гөмбә, гөл, чәчәк һ.б. Печән эше ................................
Игенчелек ........................................................................
Иген төрләре ....................................................................
Яшелчәләр ........................................................................
Агач ..................................................................................
Агач төрләре ....................................................................
Җиләк-җимеш агачлары ..................................................
Урман .............................................................................
Урман эше, агач эшкәртү ..................................................

## Хайваннар

Аучылык, ерткычлар, киекләр ..........................................
Йорт хайваннары, терлекчелек ..........................................

## Кошлар

Кош аулау, кыргый кошлар ................................................
Кошчылык, йорт кошлары ...............................................

## Җир-су хайваннары, бөҗәк-коңгызлар

Балыклар, балык тоту .......................................................
Бака, кысла, сөлек, кәлтә, еланнар ......................................
Бал корты, умартачылык ...................................................
Чебен-черки, кырмыска. Башка бөҗәкләр һәм кортлар ............

## Кеше һәм аның тән төзелеше

Баш, маңгай, муен, чәч, сакал-мыек ....................................
Күз, колак, күрү, ишетү ....................................................
Борын, авыз, ирен, тешләр .................................................
Төс-бит, йөз-чырай, матур-ямьсез .......................................
Буй-сын, тән-гәүдә, эчке әгъзалар, юан-нечкә, симез-ябык, көчле-көчсез
Кул, аяк, бармак, тырнак ......................................................

## Дөнья көтү, гомер, яшәү-үлем

Дөнья, гомер, тормыш .......................................................
Рәхәт-михнәт, шатлык-кайгы, бәхет, язмыш. Бәла-каза, елау-көлү
Яшьлек-картлык, олы-кече, әби-бабай ...................................
Саулык, авыру,гариплек, дәвалану .....................................
Әҗәл-үлем, җеназа, гүр .....................................................

## Җәмгыять

Ил, Ватан, халык, күмәк-ялгыз, киңәшләшү .........................
Күрше-күлән, авыл-шәһәр .................................................
Таныш-белеш, дус-иш, дошман ..........................................
Яу, сугыш-кыйнаш, тынычлык, гаскәр, яу батырлары, кораллар
Сыйныфлар һәм социаль катламнар. Хөкем-идарә ................

## Гаилә һәм туганлык

Гыйшык, мәхәббәт, сөйгән яр ............................................
Егет, егетлек сыйфатлары .................................................
Кыз ..................................................................................
Гаилә кору, яучы-димче, буйдак йөрү .................................
Туй-төшем, бирнә, калым .................................................
Килен (һәм башкалар) .....................................................
Кияү (һәм башкалар) ........................................................
Ир, ир-ат, ир-егет .............................................................
Хатын, хатын-кыз ...........................................................
Ир һәм хатын ..................................................................

Бала .................................................................................
Ир бала һәм кыз бала, ул һәм кыз .......................................
Үги бала, кеше баласы, үксез-ятим ....................................
Ана. Үги ана ......................................................................
Ана һәм бала ....................................................................
Ата ......................................................................................
Ата һәм бала .....................................................................
Ата-ана һәм балалар ........................................................
Нәсел-нәсәп, туганнар .......................................................
Абый-эне, апа-сеңел ...........................................................
Ир ягы һәм хатын ягы карендәшләре .................................
Туган һәм чит-ят ..............................................................

Хезмәт һәм ял

Эш-хезмәт. Аның вакыты, сыйфаты һәм нәтиҗәсе. Күмәк эш, өмә
Эшкә өйрәнү, һөнәр, осталык, эш җае, корал ........................
Тырышлык-ялкаулык, уңганлык-юньсезлек ..........................
Эш һәм ял, йокы. Бәйрәм һәм уеннар ...............................

Юл-сәфәр, транспорт

Юл-күпер, юлчы, йөрү-хәрәкәт, абыну-егылу .........................
Юл күрсәтүче, юлдаш ......................................................
Транспорт чаралары, ат жигү дирбияләре ...........................

Мал-мөлкәт, алыш-биреш

Байлык, мал, ярлылык. Бай һәм ярлы ................................
Бар-юк, барлык-юклык .......................................................
Акча, алтын, көмеш, бакыр акчалар. Сум, тәңкә, тиен .............
Базар, товар, бәя, санау. Исәп-хисап, үлчәү ...........................
Алу-бирү, әҗәт, бурыч, бүлү-өләшү, бүләк ...........................

Өй-йорт, каралты

Өй һәм аның кисәкләре ...................................................
Өй җиһазлары. Урын-җир. Чүп-себерке ...............................
Мич-учак, ут-төтен, утын яну ............................................
Каралты-кура ....................................................................

Кием-салым

Эрләү, тукымалар, тегү-чигү, энә-җеп ................................
Кием, киенү-бизәнү, көязләнү, пакьләнү ................................
Яңа һәм иске кием. Ертык-тишек, ямау ............................
Өске киемнәр ...................................................................
Баш киемнәре ....................................................................
Аяк киемнәре. Оек-бияләй ................................................

Азык-төлек, аш-су, савыт-саба. Кунак-сый

Азык, ризык, аш-су төрләре ...............................................
Ашау-эчү, ачлык-туклык ...................................................
Аракы эчү, тәмәке тарту ..................................................
Савыт-саба .......................................................................
Кунак-сый .........................................................................

Рухи сыйфатлар, холык-гадәт,әдәп-әхлак

Чын кеше булу, әдәп, оят, намус, дәрәҗә, җан, йөрәк, күңел, дәрт-дәрман, батырлык-куркаклык
Акыл, аң, акыллылык һәм акылсызлык .............................
Юмарт-саран, канәгать-комсыз. Җитез-акрын, тискәре, ваемсыз, астыртын, ялагай
Тыйнаклык, мактану, мин-минлек, үзеңнеке һәм кешенеке ....
Яхшылык һәм яманлык. Яхшы, рәхимле, юаш, усал, яман кешеләр
Турылык-хыянәт, хәләл-хәрәм, сер, вәгъдә, ачу, үпкә, көнчелек, хата. Караклык, җинаять-җәза

Тел-сүз. Әдәбият-сәнгать. Фән-белем

Телнеӊ роле, телгә осталык, туган тел һәм чит телләр ..........
Сүз аныӊ төрләре. Сүзне үтәү. Чын һәм ялган. Сөйләм культурасы
Әдәбият, фольклор әсәрләре, көй, бию. Музыка кораллары .....
Фән-гыйлем, уку-язу, галим-надан, белү-белмәү ...................

Мәҗүсилек. Ислам дине

Мифик затлар .................................................................
Ислам дине, шәригать .......................................................
Алла (Ходай, Тәӊре) ........................................................
Ахирәт, оҗмах, тәмуг ......................................................
Дини йолалар, намаз, дога ....................................................
Руханилар .........................................................................

Искәрмәләр һәм сүзлек .....................................................
Файдаланылган чыганаклар исемлеге .............................

Учебное издание

**Народные жемчужины**

Афористические жанры

*книга вторая*

Составитель
*Махмутов Хузиахмет Шагиахметович*

Редакторы *Л. Г. Шәрифуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда
биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректорлары *Г. Г. Шәрифуллина, А. М. Закирова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елныӊ 7 апрелендә бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 08.10.02. Форматы 60x90$^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе.
«Школьная» гарнитурасы. Офсет-басма. Басма табагы 12,0 + форз. 0,25.
Нәшер-хисап табагы 10,11 + форз. 0,39. Тиражы 4 000 д. Заказ Б-580.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
**Http: //magarif. Kazan. ru/   E-mail: magarif@mail.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.